Ризаэддин Фәхреддин

# Әхлак гыйлеме

# Балалар өчен

*Әхлак гыйлеменнән*

**I**

**китап**

## БИСМИЛЛӘҺИР-РАХМӘНИР-РАХИМ

## 1. АТА ВӘ АНА

1. Әй хөрмәтле балалар! Хезмәт күрсәткән кешеләр, яхшы күңелле кешеләр, һәрвакыт хөрмәттә булырлар вә якын күрелерләр, моны исә үзегез дә беләсездер. Хәлбуки сезнең ата-аналарыгыз сезгә иң авыр вә мәшәкатьле хезмәтләрен иттеләр вә һаман да итәләр. Һәрвакыт сезне кайгыртып, сезнең бәхетегез өчен тырышалар вә һәрвакыт сезнең өчен Аллаһы Тәгаәгә ялваралар вә дога кылалар. Моның өчен һәрникадәр аларның хезмәтләренә карышмавыгыз вә мәшәкатьләренең хакын үтәвегез мөкин булмаса да – һаман аларга ихлас белән хезмәт итүче вә аларга хөрмәт күрсәтүче булыгыз!..

Хосусан Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре, аларга гүзәл мөгамәлә күрсәтүне васыять иткән вә иң изге Рәсүл әфәндебез (Аңа Аллаы Тәгаләнең хәер догасы вә сәламе булсын!) хәзрәтләре: “Ата-аналарны риза итүче балалардан Аллаһы Тәгалә дә риза булыр”, - дигән мәгънәдә сүз сөйләгән.

2. Киләчәк көндә, хөрмәтле вә файдалы кешеләр булуыгызны ата вә анагыз һәрвакыт өмет итеп торалар вә Аллаһы Тәгалә хәзрәтеннән сорыйлар. Инде сез дә мондый изгелекләргә каршы явызлык итүчеләрдән булмагыз! Һәм дә аларның нәсыйхәтләрен куркып вә өркеп түгел, бәлки мәхәббәт вә ихлас белән тотыгыз, чөнки алар бу дөнья хәлен озын тәҗрибәләре белән бик яхшы таныйлар вә сез белмәгән күп серләрне беләләр.

3. Кешенең итагатьле (буйсынучы) булуы – күңеле яхшы булу галәмәтедер (билгеседер). Инде сезгә иң якын кешеләр дә, әлбәттә, ата вә аналарыгыздыр. Шуның өчен аларга һәрвакытта итагатьле булыгыз, гамәл вә сүздә аларга каршы килмәгез, бу сәбәптән аларның күңелләре дә рәхәтләнер, үз күңелләрегез дә вә дөньяда торуыгыз да гүзәл булыр.

4. Ата вә аналарыгыз хозурында бик әдәпле булыгыз, аларның сүзләрен яхшы тыңлагыз, ишарәләрен аңлагыз, алар белән артык кычкырмыйча, әдәпле итеп, ачык сөйләшегез. Алар аягүрә торганда, сез утырып тормагыз!..

5. Баһадирлык – адәм балаларында хөрмәтле бер сыйфаттыр. Олылар мәҗлесендә булып, алардан хикмәтле сүзләр ишетү гакылны артттыра вә гыйлемлекне күбәйтәдер. Хәтта кечкенә балаларны, бөек адәмнәр мәртәбәсенә якын китерәдер. Шуның өчен, йөрәксез балалар кебек, аталарыгыз сөйләшеп утыруында катнашудан курыкмагыз вә белмәгән, һәм аңламаган нәрсәләрегезне алардан сорагыз вә һәрнәрсәнең асылын белергә тырышыгыз!..

6. Урамда йөргән вакытларыгызда атагыз очраса, аңа һәм аның белән берлектә булганнарга сәлам биреп әмерләрен көтеп торыгыз! Әгәр дә утырып торган вакытыгызда килсә – ачык йөз белән аягүрә торыгыз!..

7. Атагыз һәрнәрсә бирер булса – үзенең мәрхәмәте белән бирер, шуның өчен нәрсә дә булса сораган вакытта, янында чит адәмнәр булмаган вакытта сорагыз, әгәр дә теләгән нәрсәләрегезне бирмәсәләр – күп борчымагыз, чөнки сезгә нәрсә кирәк вә нәрсә кирәк түгел икәнлеген вә сезгә нинди әйберләр яраклы булып, ниндиләре яраклы булмавын алар тагын бик яхшы белерләр.

8. Атагызның иң якын дусты булса да, атагыздан башка кешедән кирәк әйберегезне сорау гаеп эш вә гаилә хөрмәтен җибәрүдер. Шуның өчен барлык теләгән әйберләрегезне атагыздан сорагыз!

9. Бала чагында акча тотарга өйрәнмәгән кеше – олыгайгач та акча тота белмәс, дөньяда гүзәл көн кичерә алмас, бәлки бар байлыгын исраф итеп бәхетсез булып калыр. Шуның өчен атагыз тарафыннан бирелгән акчаларны тота белергә өйрәнегез. Са булыгыз, “бу – аз акча гына” дия күрмәгез, чөнки бүген сезнең кирәкләрегез дә бирелгән акча кебек аздыр.

10. Кайбер балалар булыр ки: аталарының малларына ышанып, һичбер кәсеп вә эш юлына кермәсләр, бәлки ялкаулыкка гадәтләнерләр. Ахырда бер көн килер, акчалары да бетәр. Тереклек итәр өчен кулда һөнәр дә булмас. Шуның өчен ата малына ышанып тормыйча, бәлки никадәр бай баласы булсагыз да булыгыз үзегезне кеше баласы санап, һөнәр өйрәнергә тырышыгыз!

11. Дөньяда торган вакытта, шатлыкларны сөйләр, кайгыларны чишеп эчне бушатыр өчен иң якын, иң ышанычлы бер кешегә мохтаҗ булынадыр. Ләкин бу эшләр тугрысында ата белән анадан артык һичкем булмас, чөнки болар баланың шатлыгы өчен хәтта үзеннән артык сөенәдер вә хәсрәтләре өчен кулдан килгән барлык чараларны күрүдә кимчелек итмәсләр. Шуның өчен серләрегезне боларга сөйләгез, серләрегезнең хәзинәләре һәрвакытта ата вә аналарыгызның күңелләрен булдырсын!

12. Күзгә күренгән бернәрсәгә кызыгучы булмагыз, аналарыгызның җыеп куйган нәрсәләре вә кунаклар өчен дип хәзерләнгән әйберләре янында йөрмәгез вә зарар итмәгез! Чөнки аналарыннан рөхсәтсез мондый эшләр эшләүче балалар моның кебек эшләргә гадәтләнерләр вә, көннән көн арттырып, ахырында (Аллаһы Тәгалә сакласын!) угры булырлар.

13. Бәдәнегез үсеп көч кергәч тә, кулларыгыздан килгән эшләрдә ата вә аналарыгызга ярдәм итүче булыгыз, бәлки шәфкать вә хөрмәтләрегезне тагын да арттырыгыз, алар исә сезнең яшь вакытларыгызда вә иң зәгыйфь булган көнегездә тәрбияләп сезне үстергәннәр. Бер көн җитәр сез дә ата булырсыз, исәпләп карагыз, шул көндә балаларыгыз хөрмәтегезне сакламасалар, риза була белерсезме? Иң изге Рәсүл (Аңа Аллаһы Тәгаләнең хәер догасы һәм сәламе булсын) әфәндебез хәзрәтләре: “Аталарыгызга изгелек итегез, сезгә балаларыгыз изгелек итәр” – дигән мәгънәдә бер сүз сөйләгән.

14. Кайбер балалар булыр ки: аталарының тәрбияләрендә вә мәрхәмәтләре күләгәсендә рәхәтләнеп үсәрләр дә, үскәннән соң аталарының фикерләренә каршы килерләр, сүзләрен ишетмәсләр, аларның гамәлләрен аз күреп көләрләр. Сез шулай инсафсыз булмагыз! Аталарыгыз исә сезнең тугрыда җаваплы булмый, бәлки алар турысында сез җаваплы булачаксыз. Замана көннән-көн алга барып вә гыйлемнәр артып торганлыктан, бу көндәге бөек бер галимнең иртәге көнә бер шәкерт дәрәҗәсендә калачагы табигыйдер. Өч катлы бина салу тугрысында булган мактау өченче катны бина кылучыларга булган кебек, нигезне салучылар да гаепләнергә тиеш түгелләр.

15. Тиешсез бер эшкә кушкан вакытларында һич тыгызланмыйча вә күңелләрне җәрәхәтләндермичә, бәлки әдәп вә инсаф белән эшнең турысын белдерергә тырышыгыз!

## 2. ТУГАННАР

16. Туганнарыгыз – ата вә аналарыгыз соңында иң якын кешеләрегездер. Шуның өчен алар белән һәрвакыт әдәпле вә мәрхәмәтле булыгыз! Боларның олыларын ата вә ана урынында санап, итагатьле булыгыз вә сүзләрен тыңлап гамәл итегез! Кечеләренә шәфкатьле булып, аларны бер дә рәнҗетмәгез вә каты күңелле булмагыз. Оятсызлык вә тәрбиясезлектә күчергеч булып күренмәгез, аларны сүкмәгез, кулларында булган нәрсәләрне тартып алмагыз. Чөнки болай итү аларның каннары бозылуга вә ата-ананы ачыландыруга сәбәп булыр.

17. Туганнарыгызда ярамаган бер эш күренер булса – яхшы сүз белән: “Болай булмагыз, гаеп эш бит!” – дип тыегыз вә әлеге эшнең килешмәгәнен аңлатып күрсәтегез, гүзәл юлга күндерегез!

18. Туганнарыгыз өстеннән ата вә аналарыгызга сүз әйтмәгез, чөнки болай булган балалар, мондый эшләргә гадәтләнеп, олыгайгач та сүз йөртүче булырлар. Бәлки булса – гүзәл эшләрне сөйләгез!

19. Туганнарыгызның әйтүләрен көтеп тормыйча, һәр эшләрендә ярдәмче булыгыз, кулыгыздан килгән изгелекләрне бер дә алардан кызганмагыз!

20. Туганнарыгызның серләрен гүзәл саклагыз, аларга шатлыклы хәбәрләр сөйләп (әгәр дә аларга зарар китерәчәк булмаса), яманнарын сөйләмәгез! Сүз вә гамәлләрегез белән аларга ихласлы булыгыз, гаепләрен яшерегез, һәрвакытта ачык йөз вә киң күкрәк белән каршы алыгыз!

21. Кайбер балалар булыр ки: аталары вафат булгач, мал бүлү хакында туган вә кардәшләр белән бозылышырлар, бер-берсе хакында әдәпсез мөгамәләдә булырлар, кыйммәтле вакытларын вә газиз малларын әрәм итәрләр, үзләренең кан вә җан кардәшләрен рәнҗетеп, читләрнең корсакларын туйдырырлар, бу юлда үзләре дә бәхетсез булырлар, ата вә аналарының да исемнәрен хөрмәтсез итәрләр, гаилә вә кабиләләрне мәсхәрәлектә калдырырлар. Сез үскәч, мондый балалар кебек булмагыз, гаеп эштер! Бәлки, туганнарыгыз белән һәрвакытта берлектә булыгыз! Нәҗесне (бозык холык вә ачу сәбәпләрен) һәрвакыт туфрак астына күмегез, болай булганда аз мал да күп күренер, кыска гомер дә бәрәкәтле булыр

## 3. ЯКЫН КАРДӘШЛӘР

22. Ата-ана вә туганнарыгыздан соң сезгә якын кешеләр – үзегезнең кардәшләрегездер. Болар да сезнең сәгадәтегезне вә бәхетегезне теләрләр. Шуның өчен боларга да ата-ана вә туганнарга буган мөгамәлә кебек мөгамәләдә булыгыз. Шатлык вә кайгы вакытларны уртаклашыгыз, хаҗәтләрне гүзәл сурәттә үтәгез!

23. Ялкау вә бозык холыклы затларга изгелек итү – ялкаулыкларны артырырга вә бозыклыкларны көчәйтергә сәбәп булганы өчен, якын кардәшләрегезгә изгелек иткән вакытыгызда, кәсеп сәбәпләреннән мәхрүм калганнарны вә саф күңелләрне аерым карагыз! Ягъни изгелекне тиешле урынарга сарыф итәргә тырышыгыз!

## 4. КҮРШЕЛӘР

24. Кардәшләрдән соң иң якын кешеләр – күршеләрегездер. Шуның өчен күршеләр белән гүзәл мөгамәләдә булыгыз, алар белән дус торыгыз, шатлык вә хәсрәт вакытларында уртаклашып, хәстә вә чирле вакытларында хәлләрен сорагыз, хезмәтләре булса күрегез, алар өчен даими догачы булыгыз!

25. Күршеләрнең нәмәхрәм, ягъни ерак кардәш һәм бөтенләй кардәш булмаган кеше булганнарына күз салмагыз! Коймак ярыкларыннан карамагыз! Һичбер эштә аларның хәтерләрен калдырмагыз! Хөрмәтле вә гыйффәтле, ягъни намуслы кешеләр шулай булырлар.

## 5. ӨЙ ЭЧЕНДӘ

26. Өй эчендә булганнар белән гүзәл мөгамәләдә булу – шәригать каршында иң сөекле эштер. Вә шуның өчен өй эчендә булагннар хакында әдәпле вә миһербанлы булыгыз. Өй эчендә булганнар рәхәт вә шат булсалар, сезгә дә рәхәтлек вә шатлык булыр.

27. Өй эчендә хезмәт итүчеләр булса, аларны хурламагыз, күңелләрен боектырмагыз, йомыш кушсагыз, “Шулай ит, болай ит!” димичә, бәлки “Шулай итә күрегез, мәрхәмәт итеп болай эшләгез лә! Шулай итсәгез – гүзәл булыр иде!” – дип әйтегез: хезмәтчеләр белән болай булу – күркәм холыклыктыр. Тәрбияле адәмнәр гадәте шулай булыр. Йомшак сүзле булу – адәм баласы өчен бөек бер байлыктыр.

28. Хезмәтчеләргә мәрхәмәтле булыгыз, алар каршында үз-үзегезне тота белегез. Хаталыклары булганда гафу итегез, алар белән уйнамагыз, көлке сөйләшмәгез, кирәк булмаганда, аларның сүзенә катышмагыз, чөнки бу нәрсәләр, беренчедән, тәрбиясезлек билгеседер вә, икенчедән, алардан яман сүз ишетергә вә холык бозылырга сәбәп булыр.

29. Хезмәтчеләр – өй эчендә булган серләрнең ачкычларыдыр, һәр күргәннәрен сөйләрләр вә ишеткәннәрен фаш итәрләр. Шуның өчен сак булыгыз: читләрдән яшереләчәк сүзләрне алар каршында сөйләмәгез, акча вә байлыгыгызны аларга белдермәгез, һәр эшләгәннәрен күзәтеп торыгыз, моның сәбпле аларның мәкереннән имин булырсыз!

30. Өй эчендә булган серләрне чит кешеләргә сөйләмәгез!

31. Йокыдан иртә торыгыз вә торганнар соң, сәламәтлегегез өчен Аллаһы Тәгаләгә шөкер итегез, соңынан тәһарәтәнеп намаз укыгыз!

## 6. МӘКТӘП

32. Чәй эчкәннән соң, киемнәрегезне киеп укырга барыгыз, чыгып китәр алдыннан ата вә аналарагызының кулларын үбеп, ризалыкларын алыгыз, туганнарыгыз белән күрешеп: “Аллаһы Тәгалә юлына чыктым, Аллаһы Тәгалә миңа тәүфикъ бирсә иде”, - дип, нечкә күңел вә ихлас белән мәктәп юлына чыгыгыз.

33. Мәктәп юлында уйнамагыз, гаҗәеп нәрсәләргә тамаша итеп тормагыз, очраган балалар белән сөйләшеп юанмагыз, тәрбиясез балалар вә бозык адәмнәр белән бергә йөрмәгез, урамда уйнамагыз. Чөнки бу нәрсәләр сәбәбеннән вакытыгыз әрәм булыр.

Үзегез дә сизмичә холкыгыз бозылыр, бәлки олы адәмнәр кебек үзегезне тота белеп йөрегез. Мәктәптән кайтканда да вә башка җирләргә йөргән вакытыгызда да шулай уйлагыз!

34. Мәктәпкә кергәч, аяк киемнәрегезне, бүрек, тун кебек өс киемнәрегезне билгеле җиргә куеп, укытучы вә башка иптәшләрегезгә ачык йөз белән сәлам бирегез вә алар белән дәрес укырга башлагыз!

35. Дәрес башланыр вакыт җитсә, һичкемне тыгызламыйча вә рәнҗетмичә, әдәп белән генә урыннарыгызга урнашыгыз, әгәр дә урыннарыгыз тыгыз булса, көчләмичә-төртешмичә, бәлки: "Шулай итә күрсәгез лә!" - дип, иптәшләрегездән иркенлек сорагыз!

36. Үзегез дә, һичбер тарафка авышмыйча, бәлки туп-туры вә укытучыга карап, иптәшләрегез белән бер тигез булып, як-якка карамыйча, борылмыйча, шатланып утырыгыз, мәктәпкә кереп-чыгып йөргәндә дә инсафлы булыгыз!

37. Мәктәп эчендә булган тавышларга катнашмагыз, уйнаучы вә тәрбиясез балалар белән иптәш булмагыз, алар белән бер җирдә утырмагыз, үзегезгә билгеләнгән урыннан рөхсәтсез күчмәгез!

38. Бертөрле дәрес бирелгәндә, сез икенче дәресләргә карамагыз, бәлки укытучы тарафыннан бирелгән дәрескә тәмам күңелләрегезне салыгыз, һәрбер нәсыйхәтләрне зиһенегезгә урнаштырыгыз, дәрес вакытында сөйләшмәгез вә башка әйберләргә күңелләрегезне җибәрмәгез, бу сәбәптән осталарыгыздан ризалык алырсыз, гомерегездә файда күрерсез.

39. Укытучы сүз сораган вакытта аяк өстенә торып, кулларыгызны күкрәкләрегезгә куеп, хөрмәт белән укытучыга карап торыгыз, соравын яхшы аңлагыз, соңыннан белгәнегез белән ачык вә яхшы тавыш белән җавап бирегез, иптәшләрегездән сораган сүзләргә катышмагыз!

40. Сүзегездә яки язуларыгызда булган ялгышларыгызны укытучылар төзәтсәләр, моның өчен күңелсезләнмәгез, чөнки укытучылар сезне яраталар вә сездә булган ялгышларны бетерергә тырышалар.

41. Укытучыларыгыз укырга, язарга, ятларга кушкан эшләрнең барысын да яратып җиренә җиткерегеә.

42. Кечкенә вакытта чисталык вә тәртипкә хөрмәт белән карый торган булу – баланың гакыллы вә алдан күрүчән булачагына олуг бер билгедер. Шуның өчен киемнәрегез чиста һәм билгеле бер урында, китап вә язу әйберләрегез тәртипле булсын. Бармакларыгыз вә дәрес әсбапларыгыз карага буялып йөрмәсен!

43. Каләмнәрегезне киемнәрегезгә яки чәчләрегезгә сөртмәгез, авызыгызга кабып йөрмәгез, бу нәрсәләр авыруга вә пычрак йөрүгә сәбәп булыр. Бәлки каләм сөртер өчен, яныгызда аерым бер киндер чүпрәк кисәге булсын!

44. Кулыгыз карага яки башка нәрсәгә буялса, тиз генә юып чистартыгыз, киемнәрегез исә һәрвакыт чиста булсын!

45. Мәктәп вә башка җирләрнең бүрәнә вә стеналарына, асып куелган хариталарга (карталарга) яки китапларга, урамда йөргәндә койма вә капкаларга, бакчаларда булган эскәмияләргә язмагыз. Бу нәрсәләр исә – тәрбиясез балалар эшедер.

46. Туп вә даганда атыну кебек уеннар сеңерләрне куәтләндерер, тырышлыкны уяндырыр, тәнне сәламәтләндерер. Шуның өчен моның кебек уеннардан мәхрүм булмагыз!

47. Уеннарыгыз буш вакытта, дәресләрегезгә вә башка эшләрегезгә кимчелек китермәслек итеп һәм чиста урыннарда, яхшы һавалы җирләрдә, бик әдәпле булсын!

48. Мәктәптән кайткач, ата вә аналарыгызга сәлам биреп, китапларыгызны вә дәрес әйберләрен билгеле урынга куегыз! Уйныйсыгыз килсә, әдәп белән генә уйнагыз, дәресләрегезне әзерләмичә йокламагыз!

49. Кирәк – мәктәп эчендә, кирәк – башка җирдә, әдәпсез сүз сөйләшмәгез, тиешсез ишарәләрдә булмагыз, чөнки мондый әйберләрдән тәрбияле адәмнәр нәфрәт итәр.

50. Дәресләрне калдырып яки билгеле сәгатьләреннән кичегеп йөргән шәкертләр өчен сабаклары кыен булыр. Иптәшәлреннән түбән дәрәҗәдә калыр, шуның өчен дәресләрегезне дәвам итегез, сәгатьләренән соңга калмагыз!

51. Мәктәпкә йөрүдән вә сабак укудан максат – Иман белү, тәрбияле вә камил адәм булу кирәклеген хәтерегездән чыгармагыз һәм шушы максатка ихлас белән йөрегез. “Ни өчен мәктәпкә барасыз вә ни өчен укыйсыз?” - дип сораучы булса, сез дә: "Аллаһы Тәгаләнең боерыгын җиренә җиткерү өчен, атам-анама догачы булу вә туган һәм кардәшләремә, кабиләдәшләремә вә диндәшләремә бер файдалы кеше булуны өмет итәм”, - дип җавап бирегез. Бу рәвештә җавап бирү баланың гакыллы булачагына дәлил булыр.

52. Мәктәпләрдә дәресләрнең тәмамлануы соңында “Инде уку вакыты үтте, гыйлемем да җитәрлек булды” дип, гыйлемнән вә китаплардан аерылмагыз, бәлки буш вакытларыгызда һаман китапларыгызны укыгыз вә һәрбер яңа китапларны, әдәби китапларны укыгыз. Бу сәбәпле зиһенегез ачылыр, гакылыгыз артыр, фикерегез тугры булыр.

## 7. ГЫЙЛЕМ

53. Гыйлем күңел күзен ачар, наданлык-караңгылыкны бетерер. Олы дәрәҗәлӘргә тоташтырыр, дошмнарга каршы корал булыр. Тереклекне саклар. Дөнья көтү сәбәпләрен белдерер, йорт эчендә вә гомумхалыклар белән ни рәвештә булырга кирәклекне өйрәтер. Гыйлем – галимнәрнең зиннәте, адәмнәрнең хөрмәте булып, караклардан куркусыз дәүләт вә һич бетми торган байлыктыр.

54. Галимнәр (гыйлемле кешеләр) – пәйгамбәрләрнең варислары, дөньяның нурлары булып, наданнар да дөньяда торганнары хәлдә – үлекләр хөкемендәдер. Чөнки алар Аллаһы Тәгаләнең гаҗәеп нәрсәләренә кирәк вакытта гына күз салырлар, ләкин гыйбрәт ала белмәсләр. Кирәк вакытта су эчәрләр, әмма суның нидән хасил булганын вә чишмәләрнең нинди җиргә китүләреннән хәбәрләре булмас.

55. Гыйлеме күп кешеләргә караганда аз гыйлемле булудан оялмагыз, бәлки белергә кулыгыздан киләчәк әйберләрне белми калуыгыздан оялыгыз, чөнки монысы – гаеп эштер.

56. Гыйлем әһелләренә нәфес артыннан йөрү һич килешми. Шуның өчен шәригать үлчәвеннән тыш мал сөймәгез, теләкләрегезгә әсир булмагыз.

57. Һәрвакыт гыйлемгә мәхәббәт итегез, өйрәтелә торган әйберләрне ихлас белән тыңлагыз, соңыннан кирәкләрен өйрәнегез вә һәрбер гыйлемнең күркәм булганын белегез, һичбер вакыт гыйлемгә тәкәбберлек күрсәтмәгез!

58. Гыйлем өйрәнү – һәрникадәр гүзәл эш булса да, бозык ният белән укылганында гүзәллеге кимер. Шуның өчен "Бездән Аллаһы Тәгалә риза булсын һәм яхшы эшләргә сәбәп булсын иде", - дип ният итегез. Бу исә – яхшы нияттер. "Имам, мөәзин, ахун, казый яки мөгаллимә (укытучы), мөдәррис (дәрес бирүче) вә ни булса да бер дәрәҗәгә – мәртәбәгә ирешсәң иде", - дип ният итмәгез, күңелегездә моның кебек нәрсәләр булса чыгарыгыз. Чөнки болар яхшы ният түгелдер. Чөнки гыйлемнән максат дәрәҗә генә түгел, бәлки файдалы адәм булудыр.

59. Хәзинәгездә булган гыйлемнән артыкны дәгъва итмәгез; үз-үзегезне олы санап хөкем итмәгез! Күрмисезме? Бөртекләре күп вә эре булган башаклар, һәрвакытта башларын түбән салып торырлар. Бөртексез яки аз бөртекле башаклар башларын югары күтәрерләр, аз гына һава селкенер булса, селкенергә керешерләр. Хәлбуки үзләренең утка яндырудан башка файдалары булмас.

## 8. КИТАП ВӘ УКУ

60. Гүзәл китаплар –гаҗәеп әйберләр күренәчәк күзгә, аулакта сердәш, ялгызлыкта иптәш, гаҗизлек вакытларда ярдәмче, хәсрәтләрдә шатлык китерүче, фикерләрне нурландыручы, үткән заманнар хәлләрен сөйләп торучы, өметләр, вакыйгаларны хикәят итүче, гакыллы кешеләрнең гакылларын күзләргә күрсәтүче аз хаклы, күп файдалы нәрсәләрдер. Шуның өчен китап алуда саранлык итмәгез, китаплардан аерылмагыз!

61. Ләкин китаплар арасында юк нәрсәләр язылган, мәгънәсез нәрсәләр белән тулганнары да бардыр. Боларны уку – кыйммәтле гомерне әрәм итү булыр. Шуның өчен фикерләрне нурландырачак, холыкны пакьләргә ярдәм бирәчәк, гакылны арттырачак китапларны ихтыяр итеп, башкаларыннан ерак булыгыз! Файдалы китапларны уку күңелгә шатлык китерер, фикергә азык булыр, зиһенгә куәт бирер.

62. Кайбер кешеләр булыр ки "Китабы күп" дип, халык арасында исем чыгарыр өчен генә китап җыеп, үзләре дә файда алмаслар, башкаларга да файда алдырмаслар, хәтта өйләрендә ниләр бар икәнен дә белмәсләр. Болар – йөк ташучылар мисалындадыр. Шуның өчен сез үзегез алачак китапларны үзегез файда алу өчен ихтыяр итегез!

63. Уку (китап уку) кешеләрнең йөзенә нур, күңелләренә шатлык китерер. Шул сәбәпле зиһен хезмәте белән шөгыльләнүчеләр һәрникадәр арык (ябык) булсалар да, гакыллар симез вә йөзләре мәхәббәтле булырлар.

## 9. ОСТАЗ ВӘ МӨГАЛЛИМ (УКЫТУЧЫ)

64. Остаз вә мәктәп җитәкчеләре сезнеә эшегезне юлына куючылар вә сезнең өчен хәсрәт чигүчеләр булып, аларның сезнеә өстегездә олы хаклары бардыр. Шуның өчен аларның кушканнарын җиренә җиткерүдә кимчелек эшләмәгез вә тыйган эшләрендә әвәләнмәгез!

65. Сөйләшкән вакытыгызда алар белән әдәпле сөйләшегез, артык кычкырмагыз, аларны алдап вә бер кешене гайбәт итеп бер дә сөйләмәгез!

66. Аталарыгыз тәннәрегезне тәрбияләп үстергән хәлдә, остазларыгыз җаннарыгызны тәрбия итеп үстерәләр. Бу сәбәпле остазларыгыз — бөек аталарыгыздыр. Сез дә боларны чын күңел белән сөегез, нәсыйхәтләрен тыңлагыз, авыруларның табибларга тапшырылуы кебек барлык ихтыярыгызны аларга тапшырыгыз, аларның теләкләренә каршы килмәгез!

67. Мөгаллимнәрегезгә түбәнчелекле булыгыз, каршыларында әдәпле утырыгыз, нәсыйхәтләре белән гамәл кылыгыз, саваплы булыр өчен хезмәтләрен җиренә җиткерегез, аларга ялыныгыз, башка урында ялыну — мөэмин-мөселманга хас булмаган хәлдә, гыйлем өйрәнү тугрысында ялыну — мөэмин- мөселман сыйфатыдыр.

68. Мөгаллимнәргә каршы килмәгез, алар белән кычкырышмагыз, һәрбер гүзәл эшләрдә аларның сүзләренә җан вә тән белән иярегез. Ләкин аңламаган урыныгыз булса, шул хәленчә калдырып китмичә, бәлки әдәп вә сабырлык белән: “Әфәндем, бу җирне аңламадым вә бу сүзне белмәдем»— дип кайтарып сорагыз!

69. Мөгаллимнәрегез яки мәктәп җитәкчеләре яныгызга килгәндә, әдәп вә хөрмәт белән каршы алыгыз, әгәр дә берәр төрле сүз сорасалар, сүзегезне үлчәп кенә, яхшы җавап бирегез!

70. Дәресләрне бертөрле тәмамлагач, мәктәптән аерылганыгыздан соң, мөгаллимнәр вә мәктәп җитәкчеләренең вә мәктәпне тәрбия итүчеләрнең хезмәтләрен хәтерегездән чыгармагыз, очраган вакытларында хөрмәт күрсәтүдә кимчелек җибәрмәгез. Һәр намаз соңында алар өчен хәер догада булыгыз!

## 10. ШӘКЕРТЛӘР

71. Һәрбер шәкерт, хосусан үз мәктәбегез шәкертләре белән гүзәл яшәгез, аларны туганнарыгыз кебек санагыз, алар белән йомшак сөйләшегез, очраган вакытларында шатлык белән каршылагыз. Шатлыкларын вә кайгыларын уртаклашыгыз!

72. Яман холыклар йогышлы булганлыктан, бер шәкертнең яман холкы барлыгын белсәгез, һичкемгә сиздермичә генә аннан аерылыгыз!

73. Аталарыгызның байлыгы яки һөнәре белән, шулай ук киемнәрегез белән, әсбапларыгыз белән башка шәкертләргә үзегезне күтәрмәгез, бәлки һәрвакыт аларга хөрмәт вә кечелек күрсәтегез!

74. Шәкертләр белән булган мәҗлесегез мәхәббәт вә гыйлем мәҗлесе булсын. Шуның өчен аларга күңел каралтачак хикәяләр, әдәпсез сүзләр сөйләмәгез. Файдасыз

җирдә кычкырышмагыз, сүз көрәштермәгез, хәтерләрне калдырачак эшләрдә катнашмагыз, хосусан кул күтәрүдән сакланыгыз!

75. Мәктәп тәртипләренә каршы булачак рәвештә җыелышып сөйләшмәгез, файдасыз эшләр белән дәресләрегездән мәрхүм калмагыз!

76. Иптәш шәкертләрегездә күргән әйберләргә кызыкмагыз, алардан сорамагыз! Белегез ки, бөеклек алуда түгел, ә бирүдәдер.

77. Мәктәптән аерылгач, бер мәктәптә көн кичергән иптәш-ләрегезне онытмагыз, аларның хакларын үтәүдә кимчелек итмәгез, иң олы мәртәбәләргә ирешкәнегез хәлдә, иң түбәннәренә дә олыланмагыз. Болай эшләү әшәкелек галәмәте икәнлеген Кояш кебек күреп торыгыз!

## 11. ДУС

78. Адәм баласының шатлык вә кайгы вакытларында таяначак җире, файда күрсәтеп, файда күрәчәк урыны, дуслары булачактыр. Моның өчен дусларыгызны яшь вә башка җәһәтләрдә үзегезгә яраклы булачак кешеләр арасыннан ихтыярр итегез, ягъни сайлап алыгыз!

79. Дуслыкта күңелләр арасында йөргән илче, катылык вакытларда бер-беренең ярдәменә җитешергә сәбәп булган нәрсә – арада булган дуслытыр. Әгәр дә дуслык ике тарафның ихлас вә мәхәббәтләрендә бер-беренә иш булганнарыннан барлыкка килсә— даими булыр, вакытлы бер файда күрү өчен генә булса — алдау булыр, моның өчен мәхәббәтегезнең чын булуы өчен тырышыгыз һәм дә дусларны камил вә яхшы адәмнәр арасыннан сайлагыз. Дине бөтен, гакылы камил, нәсел-нәсәбе асыл, фикере тугры, әдәбе җирендә булган кешеләрне табыгыз! Мойдый кешеләр авыруыгызда— дәва, сәламәтлегегездә — зиннәт, мәшәкатьләрегездә — таяныч, боек сәгатьләрегездә рәхәтләндерүче булырлар. Мондый кешеләр еракка китүегездә — хәлегезне кайгыртучы, якын торганда сезнең хакыгызда догачы булырлар, байлыкка ирешү белән араны өзмәсләр, тарлыкка төшү белән аерылмаслар, дуслары — сүзләреннән артык фигыль вә гомерләрендә күрелер, олы изгелекләрне — кече дип санарлар, аз изгелекләрне олы күрерләр.

80. Әгәр дә дөрес дусларыгыз булса, аларга нығытып ябы¬шыгыз, үзегездә шикаять итәрлек кимчелек булдырмагыз, аларны чын күңел белән сөегез, ахирәттә җыелу шарты белән, арагызны үлемнән башка нәрсә аермасын!

81. Дуслык күрсәтүчеләрнең барчасы белән дә дус булмагыз, дошманлыгы бардыр дип уйлаган кешеләрегезнең барчасын да дошман санамагыз! Мәхәббәте саф булмаган затлар белән аркадаш булмагыз, дуслыгының дөреслегендә шөбһә булган кеше белән дус булудан, һич дуссыз тору яхшы икәнлекне онытмагыз!

82. Кирәкле кешеләргә, телләре дөрес вәгъдәле, ихлас күңелле дәгъвасында булганнарга, сынап карамыйча ышанып, дус булмагыз, тел күп вакытта күңелгә каршы сөйләр, ихтимал ки, мондый кешеләр бер максатларын табар өчен мондый дәгъваларда булырлар да максатлары җиренә җитү белән эшләре дә тәмам булыр.

83.Дусларыгызны шелтәләргә ашыкмагыз, туганнарыгыз вә кардәшләрегез белән бозылышуны җиңел күрмәгез; бәлки бу эшләрдә беркадәр сабыр булыгыз, чөнки ачуланышырга ният иткән кешеләрегез белән ачуланышмыйча вә бозылышмыйча, бер-ике көн кадәр сабыр итеп торсагыз — күп вакыт булыр, мондый ниятнең хата икәне ачылыр да, сабыр итүегез өчен үзегез дә шатланырсыз.

84. Бик олы сәбәпләр булмаганда дуслар белән бозылышу — әдәпсезлектер. Шуның өчен аз гына нәрсәләр хакында дусларыгыздан аерылмагыз!

85. Һәрвакыт хөрмәт күрсәтеп тору вә дөреслекне олылау сәбәпле дуслык көчәер. Шуның өчен дусларыгызга һәрвакыт ярдәмче вә аларга таяныч булыгыз! Кеше — бер ялгызы аз булса да, дуслары белән күп булыр. Дуслар — авырлык вә мәшәкать көннәрендә ярдәмче булсыннар өчендер.

86. Бозык кешеләргә катышмагыз, алар юлына кермәгез, алардан бигрәк сак булыгыз, чөнки аларның иң ләззәтле эшләре бозыклык итү вә адәм балаларын һәлакәткә төшерү булыр. Адәм баласы ашамыйча вә эчмичә тора алмаган кебек, күңеле бозык булганнар да усаллык итмичә тора алмаслар. Вә зарар китермәсәләр — рәхәтләнеп йокламаслар. Әмма яхшы бәндәләр, тәмам боларның киресенчә булыр. Шуның өчен яхшы бәндәләр юлларына керегез вә алар белән дус булыгыз!

87. Бозык кешеләргә катышу бик зарарлы булса да, алар белән дошман да булмагыз, бәлки вакыты җиткәнче йомшак мөгамәләдә булыгыз, бу сәбәпле аларның зарарыннан имин булырсыз!

## 12. ЙӨЗ ӘДӘПЛӘРЕ

88. Йөз — күңелнең йомшак вә яки каты икәнлеген күрсәтә торган көзгедер. Шул сәбәпле йөзегез хакында игътибарлы булыгыз вә шушы әдәпләрне олылагыз.

89. Сөйләшкән вакытыгызда читкә карап сөйләшмәгез вә күз очы белән карамагыз!

90. Чытык йөзле вә караңгы булудан яки җиңеллек вә мәсхәрәлек билгеләре күрсәтүдән сакланыгыз, бәлки дус вә иптәшләрегез тартынмыйча вә иркенләп һәм рәхәт сөйләшсеннәр өчен һәрвакыт ачык йөзле булыгыз!

## 13. КҮЗ ӘДӘПЛӘРЕ

91. Һәрнәрсәне канәгать күзе белән күрегез, бер кешедә Аллаһы Тәгалә хәзрәтенең олы нигъмәтләрен күрер булсагыз – көнчелек итмәгез. Бәлки тагын да артуын теләгез. Үзегезгә дә шундый нигъмәтләр булуын теләп дога кылыгыз!

92. Фәкыйрь һәм авыру кешеләргә мәсхәрәлек күзе белән карамагыз, гөнаһ вә гаеп эшләргә тамаша итеп тормагыз!

93. Койма ярыкларыннан, пәрдә араларыннан, тәрәзәләр вә башка урыннардан чит кешеләрнең өйләренә вә карарга ярамаган нәрсәләргә вә кешеләрнең язуларына, хатларына рөхсәтсез карамагыз!

94. Китап язган вә укыган вакытта күзегезне бер карыш¬тан, ягъни бер сөямнән ким тотмагыз, шәм вә лампаларны сул ягыгызга куегыз, зәгыйфь яктылыкларда, икенде вә ахшам араларында карамагыз!

95. Күзләрегезне мөмкин булганда һәркөнне иртән сабын белән юыгыз, һәрвакыт саф тотыгыз, ерак вә бик нечкә яки Кояш, Ай, лампа кебек артык нурлы нәрсәләргә карап тормагыз, ак вә кызыл төсләргә озак карамагыз, күз өчен зарарсыз төсләр — яшел, күк төсләрдер.

## 14. АВЫЗ ӘДӘПЛӘРЕ

96. Мәҗлесләрдә, хосусан туй вә шатлык мәҗлесләрендә булган вакытыгызда көлүдән вә гадәттән тыш уен-көлке сөй¬ләүдән сакланыгыз. Бәлки үзегезне тота белеп вә сабыр гына, ачык йөз белән булыгыз!

97. Хәсрәтле вә ачулы кеше йөзенә көлмәгез һәм хәсрәтле бәндәләргә күңелләрен бастырырлык нәрсәләрдән башка сүз сөйләмәгез!

98. Мөмкин булганда адәмнәр алдында кикермәгез, кулы¬гыз яки яулыгыгыз белән пәрдәләнмичә торып авыз ачып иснәмәгез. (Авызга зарарлы микроблар кермәсен өчен, шулай каплау тиештер.) Авызыгызны ачып тешләрегезне казымагыз, авыз ачып иснәгәндә вә ютәллләгәндә дә сөйләшмәгез, бәлки бу вакытларда йөзегезне бер тарафка юнәлдерегез!

99. Әгәр дә авыз ачып иснәү вә ютәлләү кат-кат булса, баш¬каларга рәхәтсезлек итмәс өчен, мәҗлестән чыгып торыгыз!

100. Сөйләшкән вакытыгызда авызыгыздан төкерек чәчмә¬гез, кулларыгызны һавада йөртмәгез, берәүнең сүзе тәмам булмастай элек сүзгә керешмәгез!

101. Җиргә вә кешеләргә төкерүдән, какырудан саклавы¬гыз, бәлки моның өчен яныгызда кульяулык булдырыгыз!

102. Суган, сарымсак ашап вә яки башка нәрсәләр белән авызыгызны исләндермәгез!

103. Һәркөнне иртән, хосусан тәһарәт алган вакытыгызда һәм ашаганнан соң, авызыгызны яхшы чайкагыз. Теш арагызда ризык калдырмагыз, теш щеткасы белән камил чистартыгыз!

## 15. БОРЫН ӘДӘПЛӘРЕ

104. Кулларыгыз белән борыныгызны тотып утырмагыз, бармакларыгыз белән казынмагыз, ялангач кулларыгыз белән сеңгереп тә соңыннан башка нәрсәләргә кулыгызны сөртмәгез, киемнәрегезгә сеңгермәгез, бәлки борын сеңгерер өчен яныгызда кечкенә вә чиста яулык булдырыгыз!

105. Ашаган вакытыгызда борын сеңгерү кирәк булса — бер якка борылып, тавышсыз гына яулыгыгызга сеңгерегез, сөйләшер яки сәлам кайтарыр өчен, тәмам булганга кадәр сабыр итегез!

106. Төчкергән вакытыгызда йөзегезне бер тарафка борыгыз һәм яулыгыгызны йөзегезгә тотыгыз!

107. Борыныгызны һәм авызыгызны тәһарәт алган вакытларыгызда су белән юыгыз! Вә башка вакытларда борын яулыклары белән пакьләп, саф йөртегез!

## 16. КОЛАК ӘДӘПЛӘРЕ

108. Җәнабе Аллаһы колакларны файдалы нәрсәләр ишетү өчен яраткандыр. Шуның өчен алар белән Коръәни Шәриф вә мөбарәк хәдисләр, гыйбрәтле сүзләр ишетеп гамәл кылыгыз: ата-ана вә остазларыгызның нәсыйхәтләрен тыңлагыз!

109. Бозык сүзләр ишетү гакылларга бозыклык китерер. Шуның өчен яман сүзләр ишетмәгез: яшеренеп сөйләнә торган сүзләрне тыңлап йөрмәгез! Һичкемнең күңеле исә моңа риза булмас.

110. Сүз йөртүчеләр вә гайбәт сөйләүчеләрне тыңламагыз, күзегезне түбән салып тик торыгыз, үзегез белән бертигез булсалар — мондый эшләрнең яраклы түгеллеген әдәп белән аңлатыгыз, үзегездән кечкенәләр булганда, мәрхәмәт белән генә тыегыз.

111. Ишеткән сүзләрдән фетнәгә сәбәп булачакларын һичкемгә сөйләмәгез!

112. Әдәпсез урыннарга барып гөнаһка төшәчәк рәвештә уен тавышларын тыңламагыз!

113. Колакларыгызны һәрвакыт, хосусан йокыдан торгач пакьләп, мөмкин булганда моны пакьләр өчен фил сөягеннән ясалган колак казыгычны яныгызда булдырыгыз!

114. Йөзегезне юганда колакларыгмзның эчләрен вө тышларын юыгыз һәм тастымал белән корытыгыз!

115. Каты тавышлар колак өчен зарарлы булганга алардан мөмкин кадәр ерак булыгыз!

## 17. КУЛ ӘДӘПЛӘРЕ

116. Күрешү өчен кулны биргән кешегә уң кулыгызны сузыгыз!

117. Хакыгыз булмаган әйберләргә һичвакыт кул сузмагыз вә адәмнәргә зарар бирмәгез, ачык белегез ки: мөселман кешенең кулыннан, теленнән мөселманнар сәламәт булырлар.

118. Халык алдында кулларыгыз белән уйнамагыз, бармакларыгызны шартлатмагыз, аралаштырмагыз, тырнакларыгызны кисмәгез!

119. Читтән бер кешене чакырырга булсагыз, кулыгызны сузып чакырмагыз, бәлки халыкларга шикләндерү бирмәслек рәвеш белән, юаш тавыш белән белдерегез!

120. Пычрак нәрсә тотканыгыздан вә ашаганыгыздан соң, кулларыгызны игътибар белән юыгыз вә юынганда киемнәрегезне тотып юешләндермәгез, соңыннан яхшылап сөртегез!

121. Тырнакларыгызны озын йөртмәгез, астында булган керләрне чистартыгыз!

## 18. БАШ ӘДӘПЛӘРЕ

122. Башыгызны югары күтәрүдә, түбән салуда яки бер тарафка борып торуда гадәттән артык итмәгез. Укыган вә язган вакытыгызда кулыгыз белән таянмагыз; халык алдында башыгыз вә башка әгъзаларыгызны кашымагыз!

123. Халык алдында башыгыз ачык хәлдә булмагыз, аулакта ачык баш утырганда кеше килеп керсә, кәләпүшегезне киегез; башыгызны каплагыз!

124. Җәй көннәрендә чәчләрегезне мөмкин кадәр кыска йөртегез; вә һәрвакытта сабын вә мунчала белән юып пакьләгез, эссе көннәрдә кат-кат юыгыз!

125. Башыгызны юганнан яки коенганнан соң, ачык баш хәлегездә салкын һавага чыкмагыз!

## 19. ГОСЕЛ, ЯГЪНИ КОЕНУ ӘДӘПЛӘРЕ

126. Коенгач тәнегезне яхшы корытыгыз вә тизлек белән киемегезне киегез яки ятып тәнегезне кыздырыгыз, тәнегез салкын вакытыгызда вә өшеп торганда, вә яки тирләгән вакытыгыздан башка вакытларда салкынрак су белән коеныгыз!

127. Салкын су белән коенганда, бер минуттан артык юанмагыз һәм тәнегезне каты умагыз. Бәлки йомшаклык белән генә юыгыз һәм тәнегезне сөртмичә, бәлки кием белән бөркәнеп ятыгыз, соңыннан бераз вакыт йөрегез, яки тән кыздырырлык берәр төрле эш эшләгез вә хәрәкәтләнегез, болар булмаганда, тәнегез тәмам корыганга кадәр бернәрсә ябынып ятып торыгыз!

## 20. ЙӨРҮ ӘДӘПЛӘРЕ

128. Йөргән вакытыгызда гәүдәгезне туры вә төз йөртегез, кирәк булмаганда артык ашыгып вә яки акрын йөрмичә, бәлки гадәттәгечә генә йөрегез!

129. Шәһәрләрдә йөргәндә урам уртасыннан түгел, бәлки бер читтән йөрегез, каршы килүчеләр булганда, уң ягыгыздан китегез, артыгызга яки як-якларыгызга карап йөрмәгез, чөнки бу нәрсәләр — ахмаклык галәмәтедер. Бәлки күзегез алдыгызда булсын!

130. Кирәк булмаганда туктап тормагыз, каршы килгәннәргә йөзләренә күз тутырып карамагыз, ал арга кагылмагыз, көтмәгәндә тыгызлык булса, уң якта туктап урын бушаганын көтегез!

131. Нинди җирдә булса да, зәгыйфь вә гаҗизләр очраганда, кулыгыздан килгән ярдәмнән мәхрүм итмәгез, хосусан авыр нәрсәләр күтәреп килгәннәргә юлны иркен итегез!

132. Кычкырышучылар вә дәгъвалашучыларга очраган вакытыгызда, араларына кермәгез, бәлки бер яктан качып китегез!

133. Турылыгына кызыгып карлы вә пычрак юлларга кермәгез, юлларның турысы туры түгел, бәлки яхшы вә саф һавалы булганы турыдыр. Моны исә һичвакытта онытмагыз!

134. Тыгызлык вакытларда кесәләрегезне вә сәгатьләрегезне вә башка нәрсәләрне яхшы саклагыз!

135. Кирәк булмаганда кояш зонтикларыгызны күтәрмәгез, күтәргәч күзегезне капламагыз!

136. Дус вә белешләр очраганда хөрмәт белән сәлам бирегез! Әгәр дә алар элек бирсәләр — хөрмәт белән кайтарыгыз, бөек затлар булганда кечелек күрсәтегез, әгәр дә риза булсалар — кулларын үбегез (ләкин шәһәрләрдә, базарларда вә төрле мәзһәбләр күп булган җирләрдә кул үбү яраклы түгелдер).

137. Урамда йөргәндә ашамагыз, хаҗәтегезне үтәр өчен утырмагыз, бу нәрсәләр — тәрбиясезлек билгеседер.

138. Бөек затлар сезнең белән сөйләшеп йөрсәләр, аларның сул ягында вә бертигез булып йөрегез!

139. Олы кешеләр белән ханәләргә, пароход вә вагоннарга кергән вә чыккан вакытларыгызда, юл күрсәтү өчен аларның алларыннан йөрегез!

140. Бер кешегә зарар китерү, шәригатькә вә әдәпкә каршы эшләрне эшләү өчен бер адым булсын — йөрмәгез!

## 21. ТИМЕР ЮЛ ВӘ ПАРОХОД ӘДӘПЛӘРЕ

141. Пароход вә тимер юл белән сәфәр итәр булганда, сәфәр вакытларын белегез. Вә вакыты килмәстән ярты сәгать элек әзер булыгыз, халыклар белән тыгызлашмагыз, әйберләрегезне тәртип белән урнаштырыгыз. Юлдашлар белән мөлаем утырыгыз вә алар белән әдәпле булыгыз! Һичкемгә яман сүз сөйләмәгез, һичкемне мәсхәрә итмәгез вә һичкемгә илтифатсызлык итмәгез, сезнең белән сөйләшү теләгендә булучы кеше белән әдәпләрне олылаганыгыз хәлдә сөйләшегез, ләкин дин вә мәзһәб низаглары чыгару теләгендә булганнарга гозер аңлатыгыз. Чөнки моның кебек низаглардан һичвакыт файда чыкмас.

142. Пароходка утырган вакытыгызда пароходның исемен вә кайсы ширкәткә яки кемгә караганлыгын, вә тимер юл арбасына утырган вакытыгызда арбаның номерын белегез! Әйберләрегез онытылып калса вә яки берәр сәбәп белән үзегез калсагыз, телеграм бирү вә әйберләрегезне табу кулай булыр.

143. Соңгы тукталышны үткәч, әйберләрегезне җыеп бәйләгез вә ничә кисәк икәнен хәтерләгез! Арба вә пароход туктап җитмәстән элек чыкмагыз!

## 22. ЙОКЫ ӘДӘПЛӘРЕ

144. Йоклаган вакытыгызда табигать тәртибенә яраклы буларак кичен йоклагыз, йөзтүбән яки чалкан ятмыйча бер ягыгыз белән ятыгыз, чөнки алда әйтелгән ике төрле яту куркыныч төшләр күрергә сәбәп булыр.

145. Йокы вакытыгызны беркадәр гадәткә салыгыз, тугыз вә ахыр чиктә ун сәгатьтән калмыйча ятып, биш вә яки алты сәгатьтән калмыйча торыгыз! Йокыгыз камил булганнан сон ятмагыз вә тиешле булган йокыгызны да калдырмагыз, чөнки йокы калу ашау үтү зәгыйфьлеген вә гакыл хәстәлекләрен вә ахырда ярсучанлык барлыкка китерер.

146. Йокы вакыты картларга — биш вә утыз яшьтән югары булганнарга — алты сәгать билгеләнгән хәлдә, яшьләргә — сигез вә бик яшьләргә ун сәгать булып билгеләнер.

147. Йоклаган вакытыгызда өстегезгә бернәрсә ябып, салкыннан сакланыгыз! Вә һава йөри торган җирләрдә, вә юеш урыннарда ятмагыз! Тәрәзәләрне ачык калдырмагыз!

148. Кирәк булмаганда бер бүлмәдә бик күп йокламагыз вә йоклаган җирегездә чәчәкләр вә гөлләр булдырмагыз! Кайгы яки шат вакытларыгызда йокламагыз!

149. Йоклаган вакытыгызда тар киемнәрегезне салыгыз, кыскан җирләрне бушатып, кан йөрүне туктатмас рәвештә итегез!

150. Йокыгыздан элек вә соң, йокы бүлмәләренең тәрәзәләрен ачып, һавасын яңартыгыз!

## 23. МӘҖЛЕС ӘДӘПЛӘРЕ

151. Халык алдында әдәп белән һәм үзегезгә лаек булган урыннарга утырыгыз, хөрмәтле вә бөек затлар булганда, аларның урыннарына хөрмәт итеп бераз ерак утырыгыз, мәгәр дә яннарына җитеп утыруга мохтаҗ булынса яки үзләре боерыр булсалар, ул вакытта яннарына утырыгыз!

152. Урындыкларга утырганда ятмагыз, бер якка авышмагыз! Аякларыгыздан берсен икенчесе өстенә куймагыз, җиргә типмәгез, уйнамагыз!

153. Сөйләүче булганда, яхшы тыңлагыз! Кеше тавышыннан өстен тавыш күтәрмәгез, сөйләүченең сүзен өзмәгез, мәҗлестә булганнарның хәрәкәтләренә кимчелек итмәгез!

154. Халык каршында иң мәхәббәтсез кеше — мәҗлестә үз-үзен олы күрүчедер. Шуның өчен үз-үзегезне башкалардан олы санамагыз, үз дәрәҗәгезне белүдән абайламыйча тормагыз!

## 24. АШАУ ӘДӘПЛӘРЕ

155. Ашарга утырган вакытыгызда иң элек кулларыгызны юыгыз вә яхшы сөртегез!

156. Үзегездән олы кешеләр булганда, алардан элек утырмагыз!

157. Аш янында берни белән дә уйнамагыз, бәлки әдәпле генә булыгыз, тәмам туймастан элек туктагыз!

158. Тастымалны тезләрегезгә куегыз (кайберәүләр күкрәккә куюны дөрес күрәләр). Аштан бик ерак яки бик якын булмагыз, күршеләрегезгә тарлык итмәгез, бернәрсәгә дә таянмагыз, бәлки туры утырыгыз. Ашаган вакытыгызда бераз бөгелегез!

159. Ашый башлаганда «бисмилла» укып, уң кулыгыз белән авыз итегез, ашап бетергәч, Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт әйтегез!

160. Зур-зур алмагыз, ашыкмагыз, яхшы чәйнәгез, кул вә киемнәрегезне буямагыз, табактан үзегез өчен бернәрсә да сайламагыз, башкаларның ашавына карап тормагыз, комсыз булмагыз, күп ашарга гадәтләнмәгез, аштан күңелегез кайтканчы туктагыз, бу нәрсәләрнең сәламәтлек өчен файдасы күп икәнен үзегез дә белерсез.

161. Фикерегезне гел ашау өчен сарыф итмәгез, бәлки максатыгыз, тереклек итәр өчен ашау булып, ашау өчен тереклек итү булмасын!

162. Сөйләшеп ашалган аш җиңел сеңсен өчен, кычкырышу, сүз үлчәштерүдән башка, ягъни әдәп белән генә сөйләшегез!

163. Кулыгызны табакка батырмагыз һәм ашка буямагыз!

164. Тәмам пешмәгән җимешләрне ашамагыз, эссе вакытларда майлы ашаудан сакланыгыз!

165. Вакытлы ашарга өйрәнегез, вакыты җитеп тә ашарга теләгегез булмаса — көчләп ашамагыз, ашаган вакытыгызда киемнәрегез тар вә кысан булмасын, шулай ук олы кайгылы вә шат вакытыгызда бераз булса да сабыр итегез!

166. Авызыгызга алган нәрсәләрне тәмам чәйнәгез, ашыкмагыз, артык озакка сузмагыз, бәлки егерме вә утыз минут арасында тәмам итегез, ашавыгыздан ике сәгать үтми торып йокламагыз вә бик авыр эшләр эшләмәгез!

167. Никадәр олы ялгышы булса да, аш янында һичкемне шелтәләмәгез вә һичкемнең гайбәтен сөйләмәгез!

168. Аштан соң кул вә авызларыгызны сабын белән бик яхшы юыгыз, теш арасында бернәрсә калдырмагыз, мөмкин булганда йокламыйча бераз ятып торыгыз!

169. Кайбер хайваннарның итләре, адәм углының күңелен бозганы, дошманлык хисләренә тәэсир итүләре өчен, мөмкин кадәр булган ризыкларны сайлап алыгыз!

170. Ит ашамаган кавемнәр, башкаларга караганда сәламәт, куәтле, шат вә тырыш булганнары өчен вә яшь вакытта һәрнәрсәгә гадәтләнү мөмкин булып, яшьлектә гадәтләнмәгән нәрсәләрне файдаланырга нәфес һичбер заман мәҗбүр булмаган өчен, ит ашамаска яшьлегегездә гадәтләнегез. Суеласы җан иясенең куркып күзеннән яше аккан хәлдә, аны чалып һәм кайнар казанга салып, итен пешереп ашамый торуда — адәм углы өчен олуг гөнаһ булмаса кирәк.

## 25. ЭЧҮ ӘДӘПЛӘРЕ

171. Ашаган вакытыгызда эчәсе булсагыз, авызыгызда булганны йотып бетергәннән соң эчегез, эчкәннән соң киемегез яки кулыгыз белән түгел, бәлки авызыгызны тастымал белән сөртегез!

172. Сәламәтлек өчен (күп булмау шарты белән) саф су мәртәбәсендә һичнәрсә булмаганы өчен саф су эчәргә гадәтләнегез! Ләкин күл вә ислəнгән яки бозлы вә карлы сулар эчүдән сакланыгыз, ашагач ике сәгать үтми торып һәм йокыдан торуыгыз белән вә тирләгәннән соң, салкын су кулланмагыз!

173. Сөт, каһвә, чәй, лимон сулары — эчәргә яраклы нәрсәләрдер.

174. Әгәр дә яхшы булса— сөт олылар вә кечеләр өчен җиңел эшкәртелә торган эчемлектер.

175. Каһвә — әгәр дә сөт белән эчелсә, ашказанына файда вә азык эшкәртелүгә куәт бирер, ләкин эссе мәмләкәтләргә яраклы бер эчемлектер.

176. Чәй — күп булмау шарты белән, салкын мәмләкәтләрдә файдалы эчемлектер, ашказанына куәт бирер. Хәсрәт белән гәүдәләре зәгыйфьләнгән кешеләргә ярдәм бирер.

177. Лимон сулары — эссе көннәрдә файдалы эчемлектер.

178. Ишетү, иснәү, күрү куәтләрен зәгыйфьләндергәне вә сулышны тарайтканы, ашыйсы килүне бетергәне өчен һич тәмәке тартмагыз!

179. Малларны харап иткәне, үлемгә сәбәп булачак хәстәлекләрне китергәне өчен, исерткечләрнең һәртөрлесеннән бик сакланыгыз вә боларны файдаланган кешеләр белән хәтта дус вә белеш булмагыз!

## 26. КУНАК ИТҮ ӘДӘПЛӘРЕ

180. Кунак чакырасы булсагыз, гореф вә гадәт буенча беркадәр вакытлар иртәрәк хәбәр итегез!

181. Кунакларны ачык йөз вә хөрмәт белән каршы алыгыз вә һәркемне тиешле урынына утыртыгыз!

182. Никадәр ләззәтле булса да, ашларыгызны мактамагыз, кунакларны ашар өчен кыстамагыз (бер яки ике мәртәбә әдәп белән генә әйтелсә, бәлки зарар итмәс), кунак итүченең вазифасы исә, кунаклар хозурына аш китерү булып, ашау вә ашамау — кунаклар ихтыярындадыр.

183. Кунакларның һәрберсе белән аз булса да яннарында беркадәр утырып сөйләшегез, киткән вакытларында шатлык күрсәтеп, исәнләшеп вә рәхмәт әйтеп калыгыз!

184. Кунакка чакырылган вакытыгызда, билгеләнгән вакыттан бераз минутлар элегрәк барыгыз, йорт иясе белән шатлык белән күрешегез!

185. Мөмкин булганда үзегезгә яраклы кешеләр яннарына утырыгыз. Мәҗлес һәм ашау әдәпләрен камилләштерегез, һәрникадәр сөймәген ризыгыгыз килсә дә, сөймәгәнегезне белдермәгез, ашларның гүзәл булмаганлыгыннан бәхәсләшмәгез, ашыйсыгыз килгәнне ашагыз, ашыйсыгыз килмәгәннәрен әдәп белән кире кайтарыгыз, бүлеп алмагыз!

186. Аш тәмам булып, куллар юылганнан соң рәхмәт укып, исәнләшеп кайтып китегез!

187. Мәҗлескә баруга берәр комачаулык булганда, бара алмаганыгызны белдереп, хәбәр җибәрегез!

188. Бер кешегә барганда икенче берәүнең мәҗлесеннән вә ашларының ләззәтле булмавыннан вә яки башка гаепләреннән сүз сөйләмәгез!

189. Үзегез чакырылмаган кешеләрнең мәҗлесләренә бармагыз!

190. Аш вә туй мәҗлесләрендә башкалардан көнләшеп, хәлегездән артык мал исраф итмәгез!

191. Вакыт алтын булганы өчен, бер сәгатьтән артык вакыт исраф ителү тиеш булачак мәҗлесләргә бармагыз вә башкаларның гомерләрен исраф итәчәк мәҗлесләрне дә оештырмагыз!

## 27. ЗИЯРӘТ, ЯГЪНИ ХӘЛ БЕЛЕРГӘ БАРУ

192. Кардәш вә якын дусларыгыз килгәндә ачык йөз белән каршы алып күрешегез, лаек булган урыннарына утыртып, хәлләрен сорагыз, киткән вакытларында исәнләшеп калыгыз, әгәр дә килүчеләр олы кешеләр булса, хөрмәт белән рәхмәт әйтеп калыгыз!

193. Зиярәт өчен килгән кешеләргә йоклый яки өйдә юк дип хәбәр бирдермичә, ничек булса да үзегез каршы алырга тырышыгыз!

194. Зиярәт иткән кешеләргә зиярәтләрен кайтарыгыз!

195. Язу яки уку белән мәшгуль булган вакытыгызда, зиярәт иткән кешеләргә: “Сезгә авыр килмәсә шөгылемне тәмам итәр идем”, - дип, рөхсәт сорап, шөгылегезне бетерегез вә соңыннан алар белән мәшгуль булыгыз!

196. Бит, кулыгыз тузанлы вә киемнәрегез керле булган хәлдә яки яңгыр вә эш вакытларына махсус булган киемнәрегез белән һичкемне зиярәт итмәгез вә зиярәт өчен килгәннәргә каршы чыкмагыз!

197. Зиярәткә киткән вакытыгызда, өй хуҗасына ике-өч мәртәбә үзегезнең барлыгыгызны белдерегез, һаман да бер хәбәр булмаса кайтып китегез!

198. Шәһәрләрдә булган кешеләрне зиярәт иткән вакытыгызда: ишекләрендә бераз торып, өч мәртәбә хәбәр итегез. Әмма тәрәзә турысына килеп яки башка җирдә булса да, бер җирдә туктап тик тормагыз!

199. Барган кешенең өйдә юк икәнлеге хәбәр ителгәч, килгәнегезне белдерү өчен зиярәт кәгазегезне биреп калдырыгыз.

200. Барган җирегездә һәрникадәр ишек ачык булса да, хәбәр итми торып кермәгез!

201. Кабул иткән кешегә ачык йөз белән лаек рәвештә сәлам бирегез, әгәр дә бер кеше белән сөйләшүдә яки берәр шөгыльдә булса, эше тәмам булганын көтеп бер тарафта утырыгыз, соңыннан кыскалык белән йомышыгызны аңлатыгыз!

202. Зиярәт иткән кешегез укуда яки язуда булса, ни укыганын вә ни язганын сорамагыз!

203. Зиярәттән максат – бер кешенең өй эчендә булган хәлләрне белү булмыйча, бәлки фәкать бер дуслык күрсәтүдер. Шуның өчен барган кешегезнең әйберләрен тикшермәгез, китапларын, язуларын актармагыз, бер сүз белән әйткәндә, үз исемегездә булмаган хатларны кулыгызга алмагыз (арада камил дуслык булган кешеләр, бәлки бу хөкемнән чыгарма буларак белерләр)!

204. Зиярәт гүзәл бер гадәт булса да, гореф вә гадәт тышында күп булмагыз, шәһәрләрдә булган кешеләрнең иртән сәгать сигездән элек вә кич сәгать тугыздан соң һәм хосусый эш вә чәй вакытларында зиярәтләренә китмәгез!

205. Уку вә укыту белән мәшгуль булган шәкертләр вә мөгаллимнәр, шулай ук контора вә хөкем оешмаларында мәшгуль булган язучы вә хезмәт итүчеләрнең һәм сәүдә итүчеләрнең шөгыль вакытларында зиярәт итмәгез вә шөгыль вакытларыннан башка да һәм яннарында озак утырмагыз!

206. Вәгъдә иткән кешегезгә вакытында вә сәгатендә барыгыз, көттермәгез! Көтмәгәндә берәр комачаулык килеп чыкса, бу вакыйга турында хәбәр белдерегез!

207. Сәфәрдә булган дусларыгызга хат белен хәлләрне белгертегез, үзегезгә язсалар — җавапны бирегез! Хатларга җавап бирмәгән дусларны йомшак кына шелтә итәргә мөмкиндер.

## 28. ХӘСТӘЛӘРГӘ ЗИЯРӘТ

208. Кардәшләрегез вә дусларыгыз хәстәләнүләреннән хәбәр алуыгыз белән хәлләрен сорарга барыгыз. Көтмәгәндә хәстәлек авыр булганлыктан вә яки янына керү табиблар тарафыннан тыелганлыктан, күрү насыйп булмаса яки рәхәтсезләндерү тиеш килсә, ул вакыт хәлне өйдә булганнардан сорау белән канәгать итегез!

209. Авыру хәлен белергә барганда, хәстә янында озак вакыт утырмагыз, күңеленә авыр киләчәк вә яки кайгылы сүзләрне сөйләмәгез!

210. Хәстәлегенә сәбәп булачак нәрсәләрдән шелтәләмәгез, бәлки мөмкин кадәр зарлануларын тыңлагых, күңелен рәхәтләндерегез, батырландырыгыз, сабыр өндәгез, куркытмагыз, аз көннәрдән шифа табачагын өметләндерегез вә сәламәтлеге өчен дога кылыгыз!

## 29. ТӘГЪЗИЯ, ЯГЪНИ ҮЛГӘН КЕШЕНЕҢ ЯКЫННАРЫН ЮАТУ ӘДӘПЛӘРЕ

211. Кайгы килгән кешегә тәгъзия, ягъни кайгысын җиңеләйтергә тырышыгыз: мондый кайгыларга сабыр итәргә өндәгез, сабыр иткәннәргә вәгъдә ителгән савапларны китерегез, «иннә лилләһи...» изге аятен укыгыз!

212. Якыннарыгыздан берсе вафат булганда, гаилә әһелләренә тәгъзия итегез, хәсрәтләрен уртаклашыгыз, җеназасына барыгыз, эшләрен бергә башкарыгыз!

213. Тәгъзия вакытында кайгылы булып күренегез вә кайгыны белдерерлек киемнәрегезне киегез, көлмәгез, уйнамагыз, кайгыдан башка сүз сөйләмәгез, кайгы галәмәте булмаган эшләрне бөтенләй эшләмәгез!

## 30. КИЕМ ӘДӘПЛӘРЕ

214. Кием кию турысында камил игътибарда булыгыз! Кием киюдән максат — салкын вә кызулыктан саклану һәм халыкара күркәм күренүдер. Шуның өчен, шуңа яраклы булып, кием өчен артык байлык белән гомер исраф итмәгез!

215. Киемнәрегезне саклап вә пакь рәвештә киегез, тир исе килмәсен өчен, күлмәк вә ыштаннарыгызны алмаштырып торыгыз! Халыкка күркәм күренештә күренегез, чөнки өс-башыгыз тәрбиясез булса, халыклар сезне ялкау һам пычрак дип уйларлар, шулай ук гадәттә җибәрелә торган төкләрне тәндә йөртмәгез, ләкин чәчләрегезне вә мыекларыгыаиы зиннәтләп гомер уздырмагыз.

216. Киемнәрне бу кадәр бәһале, ягъни кыйммәт булса да карау өчен кыланусыз, әмма озак тузучан булган нәрсәләрдән сайлагыз! Төсе гүзәл, чыдавы аз булган киемнәрне сайлау — дөнья гыйлемен белмәү галәмәтедер.

217. Хәлегезгә лаек булмаган, дәрәҗәгезгә яраклы яки вакытына туры килмәгән киемнәрне кимәгез!

218. Мода сөйләмәгез, мода ишетмәгез, мода белән гамәл кылмагыз, мода белән белеш булмагыз! Мода исерткеч вә яки отыш уенының бер төре булып, аңа дучар булган кеше, үзе һәлак булмый торып, аннан аерыла алмас.

219. Киемлек алган вакытыгызда, әйберләрнең хаклары белән гомерләрне бәрабәр китереп хисап итегез вә кайсысы арзан булса — шуны ихтыяр итегез!

220. Һәрникадәр мөбах, ягъни ярый торган зиннәтләрдә зарар булмаса да, киемнәрегезгә хушбуй түгеп йөрмәгез, бәлки тәнегезне, киемегезне пакь йөртергә гадәтләнегез!

221. Кием кию турысында үзегезгә иш булмаган кешеләргә саескан кебек иярмәгез!

222. Киемнәрегез белән мактанмагыз! Киемнәрне камиллек санамагыз. Башкаларның киемнәренә мәсхәрә күзе белән карамагыз, халык алдында киемнәрегезгә карап тормагыз, күңеле кибәк белән тулы кешенең тышы ефәк булуында бер мәгънә дә юк икәнлеген һичбер вакыт онытмагыз!

223. Бик кыскан вә иркен киемнәрне кимичә, бәлки башны кызудан, аякларны салкыннан саклар рәвештә булган киемнәрне ихтыяр итегез!

## 31. СӨЙЛӘШҮ ӘДӘПЛӘРЕ

224. Сөйләшкән вакытыгызда артык кычкырмагыз, артык акрын да сөйләмәгез. Тешләрегезне кысмагыз, бәлки гүзәл вә кыска һәм ачык сөйләгез!

225. Телегез белән иренегезне яламагыз, тешләрегез белән тырнакларыгызны өзмәгез, болай итү — әдәпсезлектер.

226. Тел — адәм баласының күңелендә булган ачу, мәрхәмәт, йомшаклык, катылык кебек нәрсәләрне ачып бирүче; гыйлем вә әдәп һәм мәгърифәт кебек нәрсәләрне күрсәтүче булган әгъзасыдыр. Шуның өчен телегезне дөреслектән башка нәрсә өчен кузгатмагыз, тәрбиясез сүзләр сөйләмәгез. Кешенең сәламәтлеге телне саклауда икәнлекне онытмагыз!

227. Арттырып сөйләмәгез, әмма һич ялган сөйләмәгез, гайбәт сөйләмәгез, сүз йөртмәгез, белмәгән нәрсәләрне сөйләргә керешмәгез, бер кеше сүз башлагач, тәмамламастан элек, гәрчә ахыры сезгә мәгълүм булса да — калдырып китмәгез! Бу исә — адәмчелектән мәхрүм булу галәмәтедер.

228. Бер кешенең ялгыш сөйләгәнен белсәгез дә «ялгыш сөйлисең» яки «белмисең» димәгез. Бәлки дөреслеген, хәтеренә көч килмәс сурәттә, йомшаклык белән күрсәтегез!

229. Ялгыш сөйләвегез мәгълүм булганда, «хата әйттем» диюдән гарьләнмәгез. Сүзегезнең хата икәнлеге башкалар тарафыннан күрсәтелгәндә, хата түгеллеген яхшы белсәгез, каты сурәттә каршы тормыйча вә кычкырмыйча, әдәп белән җавап бирегез! Сүзегезнең дөрес икәнен, тавыш куәте вә ачу белән түгел, бәлки йомшаклык вә дәлил куәте белән исбат итегез!

230. Гомуми мәҗлесләрдә адәм тәнендә булган гаепләр хакында сөйләшмәгез, бер кеше хакында булган сүзне, башкалардан күчереп булса да, хикәят итмәгез сөйләмәгез!

231. Башкаларга форсат бирмичә, бөтен вакытны сез генә сөйләп кичермәгез, күңелегезне тел артыннан түгел, бәлки телегезне күңел артыннан йөртегез, адәмчелек сүздә түгел, бәлки гамәлдә икәнлеген белми тормагыз!

232. Бөек кешеләргә эндәшергә туры килгәндә «хәзрәтегез, җәнабегез, бөек затыгыз, сез» кебек хөрмәт сүзләре кулланыгыз!

233. Үзегезне вә балаларыгызны гына сөйләп гомер уздырмагыз, иярченнәрегезне мактамагыз, ата-баба, нәсел вә кабилә һәм остазларыгыз белән мактанмагыз, адәм баласы үзе камиллектән мәхрүм булганы соңында, һичбер тарафтан камиллек килмәячәгенә нык ышаныгыз!

234. Берәр нәрсә сорасалар, һәрникадәр буш вакытыгыз булмаса да, әдәпле җавап бирегез, сораган нәрсә кулыгызда яки күңелегездә булмаса — гозер күрсәтегез, ягъни үтенегез. Сүзегезне кайтаруны үтенүче булганда, кабатлап сөйләгез, үзегез, кабатлап

сөйләнергә мохтаҗ булган чагыгызда “Янәдән сөйлә” димичә, бәлки «Мәрхәмәт итеп, тагын сөйләсәгез, бәлки аңлар идем» рәвешендә йомшак сүзләр кулланыгыз!

235. Башкаларның сүзләренә яхшы аңламастан элек, “Дөрес, шулай!» яки «Юк, алай түгел!» дигән кебек сүзләр белән җавап бирергә ашыкмагыз!

236. Фикерегезне ачып бирмәкче булган бәхәсләрне иң элек гүзәл аңлагыз, соңыннан әдәп белән керешегез, үз фикерегезгә үзегез хәйран калмагыз, сүз сөйләгән вакытыгызда ант итмәгез! Үз фикеренә хәйран булу — наданнар гадәте, ант итү вә «Бу сүзне дөрес сөйлим» дип әйтү — ялганчылык галәмәтедер!

237. Бер кешегә каршы сөйләргә мәҗбүр булган вакытыгызда «Юк, алай түгел, бәлки болай!» дип әйтү кебек, җәмәгать сүзен кулланмыйча, «Сез сөйләгәнчә дә була, ләкин мин болай түгелме дип уйлар идем» яки «Минем фикеремә болай килер» кебек күңелле сүзләр кулланыгыз, тәмам белмәгән нәрсәләрегез хакында башкалар белән кычкырышмагыз!

238. Кирәк булмаганда, хәсрәтле хәбәрләр сөйләмәгез, әдәпсез сүзләрне — хикәяләү юлы белән булса да — авызыгызга алмагыз вә йөкләмәгезгә әманәт ителгән сүзләрне фаш итмәгез (сер саклау — гакыллы кешеләргә махсус булган камиллектер)!

239. Һичбер адәмгә ләгънәт итмәгез, каһәрле дога кылмагыз вә һичкемне сүкмәгез, вә һичкемне хурламагыз, яла якмагыз, хаҗәтегезне үтәгән вакытыгызда сөйләшмәгез, мөэмин вә башка кешеләрне куркытмагыз, өченче кеше бар икән, икегез яшерен сүз сөйләмәгез, усал эш артыннан йөрүчеләргә юл өйрәтмәгез, Аллаһы Тәгаләнең бер тел вә ике колак бирүдә, ишеткән нәрсәләрнең фәкать яртысын гына сөйләргә тиеш икәнлегенә ишарә барлыгын белми тормагыз!

## 32. АШАУ-ЭЧҮДӘ ЧИКЛӘНҮЧЕЛЕК ӘДӘПЛӘРЕ

240. Ашау-эчүдә чикләнүчелек, кагыйдәсе белән булганда, фикерне уяндырыр, кан йөрешенә ярдәм бирер, ашказанын яхшыландырыр, сеңерләрне куәтләндерер, ашыйсы килүне вә тән эсселеген арттырыр, зиһенен ачар, укуга вә аңлауга теләк уятыр, шуның өчен авылларда булган вакытыгызда йорт вә кырларда булган хезмәтләрне башкарыгыз, атларга менеп йөрегез, суга төшеп йөзегез, кош тавышларын тыңлагыз, кул-аяк, сеңер вә башка тамырларыгызны хәрәкәтсез тотмагыз, шәһәрләрдә булган вакытыгызда, кайбер вакытларда булса – бакчаларга барыгыз, тау өсләренә чыгыгыз! Су буйларында, яшел үлән өсләрендә, урман вә әрәмә буйларында йөрегез, гүзәл һавалар иснәгез, күк йөзендә булган зәңгәр түбә вә болытлардан гыйбрәт алыгыз!

241. Җәй көннәрендә иртә торыгыз, мөмкин булганда, таң атканда вә кояш чыккан вакытларда, өйләрнең тышында булыгыз, дөньяда яратылган гүзәл нәрсәләрдән, моңлы тавышлардан гыйбрәтләнегез, олуг вә бөек булган җаннар дөньясыннан бу тыгыз һәм дә бик тыгыз вә бик мәшәкатьле булган дөньяга бер-ике көнлек юлчы буларак килгәнегезне онытмагыз!

242. Физик күнегүләр белән шөгыльләнгәннән соң, су эчмәгез вә бер-ике сәгать вакыт үтмичә торып ашамагыз вә ашаганнан соң, ашказанында эшкәртелми торып, физик күнегүләр белән шөгыльләнмәгез, моның өчен гүзәл һавалы җирләрне сайлагыз!

## 33. ДИН ӘДӘПЛӘРЕ

243. Һәрнәрсәне бар иткән вә безне гүзәл сурәттә яратып, гакыл нигъмәте бүләк иткән мәрхәмәтле Аллаһы Тәгалә хәзрәтенә ихлас белән коллык итегез, ата-ана вә остазларыгыздан артык мәхәббәт белән боерыкларын җиренә җиткерергә тырышыгыз!

244. Коллык димәктән, көнозын намаз уку вә зикер әйтү, яки барлык эшләрне бер тарафка куеп, мәчет вә тәкияләрдә яту вә яки зиратларга йөрү, дип аңламыйча, бәлки Аллаһы Тәгаләнең боерган юлы белән өстендә булган бурычларны үтәү, халык белән гүзәл мөгамәләдә булу, рәхмәтле вә шәфкатьле булу һәм гөнаһлардан саклану, дип аңлагыз вә шулай гамәл итегез!

245. Хөрмәтле Рәсулулла китергән мөбарәк ислам шәригатенә үз башыгыз белән бер хәреф арттырмагыз вә бер хәреф киметмәгез; бер хәреф арттырган вә бер хәреф киметүдә булган затларга һич иярмәгез. Бәхет исә — саф шәригатьтәдер, моны һәрвакытта хәтерегездә тотыгыз!

246. Киемнәрегезне, тәннәрегезне кер вә пычраклардан пакьләгән кебек, күңелегезне дә икейөзлелек, алдау, үч тоту, көнчелек, ачу, золым кебек бозык холыклардан пакь итегез!

247. Аллаһы Тәгаләгә шөкер итү вә Аллаһы Тәгаләнең ихласлы бәндәләре белән бер җиргә җыелып, мәхәббәт вә бердәмлек барлыкка китерү нияте белән намазларны мөмкин кадәр җәмәгать белән үтәгез!

248. Ураза тоткан вакытыгызда, нәфесне тәрбияләү, сабыр итүгә гадәтләндерү, фәкыйрь вә мескеннәр хәлен сынап карауны ният итегез!

249. Малыгыздан зәкят биргән вакытыгызда, юмартлыкка гадәтләнү, саранлык кебек бозык холыктан нәфесне сафландыру, фәкыйрьләрне шатландыру кебек изге нияттә булыгыз!

250. Ислам кардәшләре белән танышу, мәшәкатьләргә гадәтләнү, сәяхәт итеп гыйбрәтләнү нияте белән — фарыз булган хаҗ сәфәренә барыгыз!

251. Пәйгамбәрләр (аларга Аллаһы Тәгаләнең хәерле догасы һәм сәламе булсын!) — бабаларыбызны хак юлга өндәр өчен Аллаһы Тәгалә хәзрәтеннән җибәрелгәннәр һәм барысы да Аллаһы Тәгаләнең хак илчеләре вә гөнаһтан пакь бәндәләре булганлыктан, барысын да чын күңелдән сөегез!

252. Мөбарәк динебез бу дөньядан ахирәткә барачак туры юлыбыз, хәсрәтле вакытларда астына кереп сыеначак җиребез, мәшәкатьләрдә рәхәт күрәчәк ярдәмчебез, барлык куркынычларда өмет итәчәк урыныбыз булганлыктан, һәрвакыт аңа ныгытып ябышыгыз!

253. Савап ва газаплар, файда вә зарарлар, барлык гамәлләреннән безгә һәрвакыт хәбәр биреп торуда булган туры юл күрсәтүчебез, Изге Коръәннең хак вә хөрмәтле китап икәнлегенә ныгытып ышаныгыз!

254. Дөньяның иң авыр сәгате булган үлем исереклеге хәлендә, әләмнәрне җиңел итүдә булган Изге ислам динебезгә азау тешләрегез белән ябышып, һәрбер сүз вә эшегездә Аллаһы Тәгаләгә диндарлыкта булыгыз!

255. Ахирәт өлешләреннән мәхрүм калуны теләмәсәгез, изге бәндәләр юлында йөрегез, шөбһәле вә шикле кешеләргә иптәш булмагыз, бу нәрсә җаныгызга авыр булмасын дип уйлагыз, алдыгызда үлем теләгән нәрсәнең көтеп торганын онытмагыз!

256. Халыклардан яшерен тотачак нәрсәләрне Аллаһы Тәгаләдән сорамагыз; вә Аллаһы Тәгалә риза булмаячак нәрсәләрне халык белән эшләмәгез!

257. Эшләрегезнең яхшы булуын Аллаһы Тәгаләдан сорагыз, күңелегез нечкәргән вә хөрмәтле вакытларда дин вә дөнья кирәкләре, аерым алганда, үзегез вә балагыз вә барлык нәсел-нәсәбегез, кардәшләрегез вә остазларыгыз вә сездән дога өмет итүче кешеләрегез өчен иман белән дөньядан кичү хакында дога кылыгыз!

258. Мәчет вә гыйбадәтханәләргә кергән вакытыгызда әдәп белән кереп, Аллаһы Тәгалә хәзрәтенә тәүбә вә тәүфикъ белән дога кылыгыз! Вә мәчет хөрмәтен җибәрәчәк нәрсәләрдә сакланыгыз!

259. Барлык кирәкләрегезне Аллаһы Тәгаләнең Үзеннән тугры сорагыз, дога кылыр өчен белмәгән телләрдә булган догаларны укымыйча, ихлас күңелегез белән, белгән телегез белән сорагыз вә Аллаһы Тәгалә белән ике арага үлек вә терекләрдән һичкемне арадашчы итеп куймагыз вә нәзер әйтмәгез, фәлән шәех хөрмәтенә дип сораудан зинһар сакланыгыз, ихтимал ки, халыкларның «вәли» («изге»), “тәкъдиргә ия булучы” дип уйланган затлары Аллаһы Тәгалә хозурында — рәхмәттән сөрелгән бер кеше дип беленә.

260. Хөрмәтле Рәсүлулла тарафыннан хәбәр бирелмәгән хәлдә һичкемнең бәхете һәм бәхетсезлеге белән шаһитлык бирмәгез!

261. Үз ышанычыгызны вә гамәлләрегезне хөрмәтле Рәсүлулла юлына яраклы итәргә тырышыгыз да башкалар белән мәшгуль булмагыз, һичкемне “бозык мәзһәб», «начар мәзһәб» вә «кяфер» дип сөйләмәгез, телегезне мондый нәрсәләргә гадәтләндермәгез!

262. Аллаһы Тәгаләнең боерган фарызларын калдырмагыз, тыелган нәрсәләре янында йөрмәгез, галимнәрне хөрмәтләгез, һәрвакыт күңелегезне төзек йөртегез, күңел төзек булса — бөтен гәүдә дә төзек булыр.

263. Изге Коръән укыганда, һәрникадәр мәгънәсен камил белмәсәгез дә, Аллаһы Тәгаләнең сүзләре дип хөрмәт итү вә олылау белән тыңлагыз, читләргә каранмагыз, кием чабуларыгыз белән уйнамагыз!

264. Картлыгыгыздан элек булган яшьлек көнегезнең, хәстәлектән элек сәламәтлегегезнең, фәкыйрьлектән элек байлыгызның, шөгыльдән-эпггән элек иркенлек сәгатьләренең, вафат булмастай элек тереклек көннәрегезнең кадерен белегез!

# ӨСТӘМӘ

Бу язмада язылган нәсыйхәтләрнең кайберләре олы кешеләргә тиешле булса да, сүз уңае килгәнгә күрә арада язылды. Кыз балаларның үзләренә хас булган нәсыйхәтләр икенче кисәктә язылыр.

# Кыз балалар өчен генә

*Әхлак гыйлеменнән*

**II**

**китап**

## БИСМИЛЛӘҺИР-РАХМӘНИР-РАХИМ

Әй хөрмәтле кызлар! Вә әй гыйззәтле карендәшләр! Сезгә мәгълүмдер ки: холкы гүзәл булган кыз бала — бөтен гаиләсе өчен олуг байлык вә бәхеттер. Карендәшләре өчен —кыйммәтле хәзинәдер. Үскәннең соңында бер иргә ихлас белән ярдәмче вә иптәштер. Моның кебек кыз балалар белән мактанырлар вә моның кебек кыз балаларны иң түбән халыклардан башлап, иң бөек адәмнәргә кадәр, барысы да мактарлар.

Укыган вә холкын тәрбияләгән кыз — алтыннан да кыйммәтле вә энҗедән дә кадерле байлыктыр ки: моның кебек кызларның куләгәләре иң ерак карендәш вә белешләргә кадәр ирешер. Карендәш-кабилә арасында гына түгел, холыклы вә гүзәл тәрбияле кешеләр белән бөтен милләт вә бөтен дөнья халкы мактаныр.

Әдәпле кешеләрне (хәдисләр хәбәренә күрә) Аллаһы Тәгалә сөяр, халык та сөяр, исеме — үзеннән соңнарга калыр, дөньяда могтәбәр вә ахирәттә дә бәхетле булыр. Һәркем моны мисал итәр, һәркем хәер-дога белән искә алыр, сагыныр.

Әдәпсез кешеләр исә, моның киресенчә, Аллаһы Тәгалә каршында хөрмәтсез вә халык күзендә дошман күрелер, исеме сөйләнелмәс, дөньядан үткәндә һәркем рәхәтләнер дә, бер-ике сәгатьтән соң тәмам онытылыр вә гүя дөньяга килмәгән кебек саналыр.

Әгәр дә әдәпле булырга теләсәгез (моны теләмәгән кем булыр?) — гүзәл холыкларны өйрәнегез, гүзәл холыклы булыгыз, гүзәл холыкларга гадәтләнегез. Кеше булуны теләгән кешеләр өчен гүзәл холыклы булу — җиңел бер эштер.

Безнең бу урында язачак нәсыйхәтләребездә гүзәл холыклардан иң кирәкле булганнарыдыр. Боерыгыз, ханым әфәнделәр, бер мәртәбә булса да укыгыз вә урыны булганда кулланыгыз да. Тырыш вә бәхетле кешеләр кем тарафыннан булса да булсын, нәсыйхәтләргә колак салырлар вә нәсыйхәт итүчеләрнең кимчелекләренә күз йомарлар.

## 1. АТА ВӘ АНА ӘДӘПЛӘРЕ

1. Хөрмәтле кызлар! Атагызны хөрмәт итегез, алдында вә артында камил ризалык белән аның әдәпләрен олылагыз, ата вә анагызны ихлас белән сөегез! Васыятьләрен җиренә җиткерегез, теләкләренә каршы килмәгез, каты күңелле булмагыз, аларны хәсрәтләндермәгез, бар тырышлыгыгыз белән аларны ризаландырыгыз. Ата вә анасына итагатьле вә гыйлем белән зиннәтләнгән кызларның гадәтләре көннән-көн гүзәлләнер, дус вә белешләре арасында исеме хөрмәт белән сөйләнер. Әмма ата вә анасын хөрмәтсез иткән вә аларның сүзләренә колак салмаган кызлар мәхәббәтсез булалар, ата вә аналары да үзләрен сөймәс, чит кешеләр күзендә дә хур-түбән күренерләр, дөньяда гүзәл тереклек тә итә алмаслар.

2. Атагыз алдында утырганда әдәпле булыгыз, күп көлмәгез, киемнәрегез белән уйнамагыз, аның тавышыннан артык тавыш белән сөйләмәгез!

3. Атагыздан башка кешедән, кирәк иң якын кешегездән булсын, һичбер әйбер сорамагыз, чөнки болай кем туры килсә аннан әйбер сорау кызларның күңеле бозылырга

сәбәп булыр. Атагыздан сораганда да, чит кешеләр юк вакытын күзәтеп, гаять әдәпле итеп сорагыз вә бирмәгәндә күп кабатламагыз!

4. Атагыз булмаганда вә яки вафат булганда, аның урынына калган туганнарыгызны атагыз хөкемендә белегез!

5. Акча вә яки башка кадерле әйберләрегезне аналарыгыз кулында саклагыз, анагыз рөхсәтеннән башка ашау вә эчү нәрсәләренә кул сузмагыз, көчегез җиткән кадәр йорт вә өй хезмәтләре тугрысында аналарыгызга ярдәмче булыгыз, аларның кул араларына керегез. Ул хезмәтләрне башкарырга өйрәнегез, тик тормагыз, сәбәпсез ятмагыз, өстегезне вә башыгызны пычрак йөртмәгез!

## 2. ТУГАННАР ӘДӘБЕ.

6. Бар туганнарыгызны хөрмәтле тотыгыз, алар белән әдәпле булыгыз, чөнки ата вә аналарыгыздан соң иң якын кешеләрегез — туганнарыгыздыр.

7. Үзегездән олы булган туганнарыгызны ата вә анагыз урынында санагыз, аларга тавыш күтәрмәгез, алар белән низаглашмагыз, алар сүзенә каршы әйтмәгез, аларны сөегез!

8. Кечкенә туганнарыгызга шәфкатьле булыгыз, аларны рәнҗетмәгез, алар кулында булган нәрсәләрне кычкыртып алмагыз, чөнки бу әйберләр аларның күңелләре боегуга вә ата-аналарыгызның ачулануларына сәбәп булыр. Кызларның әдәпсез булуларына да мисал булыр.

9. Кулыгызда бернәрсә булганда, кечкенә туганнарыгызны кызыктырып каратып тормагыз, бәлки аларга да өлеш чыгарыгыз, һәрнәрсә булса да, аларга шәфкатьле булыгыз!

10. Туганнарыгыздан көтмәгәндә әдәпсез эшләр күрелсә, йомшаклык белән генә: «Бу эш — гаеп эщ, эшләмәгез!» — дип хәтерләренә төшерегез. Хак юлны белгәнегез кебек күрсәтегез!

11. Туганнарыгызны ата вә аналарыгызга яманлап сөйләмәгез, телләрегезне кеше яманларга гадәтләндермәгез!

## 3. КАРДӘШЛӘР ӘДӘБЕ

12. Аталарыгыз вә аналарыгыз белән бер туганнарны вә аларның балаларын вә башка кардәшләрегезне хөрмәт итегез, аларны якын күрегез, гаепләрен сөйләмәгез, аларның хөрмәтле кешеләр икәнлеген һич онытмагыз!

13. Ата вә аналарыгыз рөхсәт иткән вакытта кардәшләре-гезнең хәлен белегез, хәстәләнсәләр хәлләрен сорап барыгыз, читтә булганнарны белешеп торыгыз, аларның шатлыкларына шатланыгыз, кайгылары булганда, кайгыларын уртаклашыгыз. Аларның хезмәтләрен башкарыгыз!

14. Кардәшләрнең олыларына аталарга булган хөрмәт мисалында хөрмәт күрсәтегез, кечеләренә туганнарга булган шәфкать мисалында шәфкать күрсәтегез!

## 4. КҮРШЕЛӘР ӘДӘБЕ

15. Якын күршеләрегезнең хакларын ригая итегез, олылагыз, аларны кардәшләрегез кебек күрегез, аларның хәлләреннән хәбәрсез тормагыз, хаҗәтләрен үтәгез, хәстәләренең хәлен сорагыз, кайгы вә шатлыкларын уртаклашыгыз, читләргә китсәләр — хәлләрен белешеп вә сорап торыгыз! Хаҗәт вакытларында ярдәм итегез, аларга изгелек теләгез, мөмкин кадәр яхшылык эшләгез!

## 5. ӨЙ ӘДӘПЛӘРЕ

16. Өй эчендә булганнар белән гүзәл торыгыз, аларга ачык йөзле вә әдәпле булыгыз, өй эчендә булганнарны, хәтта хезмәт итеп йөрүчеләрне дә рәнҗетмәгез, хәтерләрен калдырырлык сүз әйтмәгез, чөнки бу нәрсәләр гакылсызлык билгесе булыр.

17. Хезмәтчеләр белән уйнамагыз, аталарыгыз рөхсәтеннән башка аларга йомыш кушмагыз вә аларга күп катышмагыз, алар белән озак сөйләшмәгез, чөнки болай итү хезмәтчеләр күзендә хөрмәтсез булуга вә ярамаган сүзләр ишетүгә вә ахыры хәерсез эшләргә төшүгә сәбәп булыр.

18. Берәр нәрсә сораганыгыз вә яки ярдәм теләгәнегез вакытларда кирәк — хезмәтчеләрдән булсын «шулай ит, болай ит!» димичә, бәлки «шулай итә күрегез лә, болай итсәгез лә!» кебек йомшак сүзләр кулланыгыз!

19. Ишек, тәрәзә кебек нәрсәләр белән уйнамагыз, югары урыннарга чыкмагыз, биек җирдән сикереп төшмәгез, кояшта бер тоташтан озак вакыт эшсез йөрмәгез: урам вә юлларга пыяла вә чынаяк ватыклары, бәрәңге вә кыяр кабыклары ташламагыз. Бер сүз белән әйткәндә, йөрүчеләрнең аякларын җәрәхәтләндерәчәк яки аяклары таеп егылуларына сәбәп булачак һәм пакьлек вә тәһарәткә хилаф булачак нәрсәләрне эшләмәгез!

20. Хаҗәт үтәргә чыккан вакытыгызда киемнәрегезне яхшы киегез, читек вә оек кебек нәрсәләр белән генә (кәвеш вә башмактан башка) хаҗәтханәгә кермәгез, кергән вакытта сул аяк белән кереп, чыкканда уң аягыгыз белән чыгыгыз. Бу урында кирәк булмаганда һич сөйләшмәгез, догалык вә язулы кәгазьләрне яныгызда булдырмагыз, кәгазь кулланмагыз (кәгазь белән сөртү сәбәпле мәгълүм урынга авыру пәйда булачагы табиблар тарафыннан сөйләнәдер).

21. Һәрбер эшнең бер вакыты вә һәр вакытның бер эше булып, вакыт үткәннән соң, адәм баласы иң кирәкле һөнәрләрне өйрәнүдән мәхрүм калачагы өчен, өй эчендә булачак вә эшләнәчәк эшләрнең барчасын ошбу яшь чагыгызда өйрәнегез.

22. Өй эчендә оста аш пешерүче булганда, яныннан аерылмыйча, аның һөнәрләреннән дәрес алыгыз, аның кебек пешерә белергә өйрәнегез, иң ясалма булмаган, ләкин ләззәтле ашлар хәзерли белегез!

23. Утыннарның нинди гүзәл вә нинди начар икәнен, утыннарны ничек киптерергә вә ничек хәзерләргә тиеш икәнен; сөт вә каймакларны ачудан; ит вә җимеш төрләрен бозылудан; шырпы, пычак, балта, без, урак, чалгы, кайнар аш вә самовар кебек

куркыныч нәрсәләрне, спирт, йода, мышьяк кебек агу вә зәһәрле суларны балалардан вә балаларны болардан ничек сакларга кирәк икәнен сынагыз вә гүзәл аңлагыз!

24. Хаталык белән кулланылмасын вә яки кирәк вакытында табылмыйча тормасын өчен, он, су, борчак рәвешемдә булган дәва вә зәһәрләрнең кәгазьләренә вә шешәләренә исемнәрен язып куярга гадәтләнегез!

25. Башка ис тигәндә яки һава бозылып тын беткәндә, агу белән зәһәрләнгәндә, тән пешкәндә вә җәрәхәттән артык кан акканда, борын канаганда, әгъзалар өшегәндә, һуш киткән вакытта иң беренче зарарсыз ярдәм нәрсә икәнен күңелегезгә алыгыз вә белегез!

26. Киемнәрегездә булган ертыкларны, сүтекләрне күренү белән үзегез ямагыз, үзегез тегегез, керләрегезне юыгыз. Керләрне ничек киптерергә вә ничек үтүкләргә, сабынны ни рәвешле вә никадәр кулланырга кирәк икәнлеген энәсеннән җебенә кадәр ваклап белегез!

27. Киемнәрегезне үзегез кисеп, үзегез тегегез, идәннәрне себерегез, юыгыз, бакыр вә җиз савыт һәм самоварларны агартыгыз. Һәр чәй эчкәннән соң чынаякларны юып куегыз, шкаф, өстәл вә башка җирләрдә булган тузаннарны сөртегез, үрмәкүч ояларын бетерегез, өйнең һавасын саф тотарга өйрәнегез!

28. Өй эчендә булган әйберләрнең иң бөекләреннән иң кечкенә вә иң вак-төякләренә барганча дөньяда булган бөтен тереклек нигезедер, боларны исә урынлы куллану — бөтен ханәләрне (өйләрне) төзәтер вә әгәр дә моның киресенчә буларак, урынлы кулланылмаса — бөтен ханәләрне харап итәләр. Шуның өчен өй эчендә булган әйберләрнең хәтта иң кечкенәләренә барганча, белеп, ни рәвешле тәртип ясарга вә ни рәвешле кулланырга тиеш икәнлекне аңлатыгыз!

29. Бөек галимнәр: «Адәм балалары арасында йөргән яхшы вә яман эшләрнең һәммәсенең баш сәбәбе — хатыннар булачактыр, байлык ягыннан харап булган өйләрнең сәбәбен дә өйдә булган хатыннардан сорагыз!..» — дигәннәр. Киләчәк көннәр бөтенләе белән сезнең кулыгызда вә нинди бөек хезмәтләр булса да булсын, сезгә бүләк ителәчәктер. Шуңа нигезләнеп, бу көннәрегездә гүзәл идарә вә гүзәл тәрбия итә белү өчен хәзерләнегез. Юл башы булып алып барган кәрваннарны чүлләрдә адаштырмас вә өстегезгә алып чыккан көймәләрне комлыкка утыртмас кадәр гыйлемнәрне бу көндә хәзерләгез!

## 6. МӘКТӘП ӘДӘПЛӘРЕ

30. Иртәнге йокыгыздан тору белән тәһарәт алыгыз, яхшы сөртегез, чәчләрегезне тарагыз, көндезге киемнәрегезне киегез чәй эчкәннән соң, сабакларыгызны алып кабатлагыз!

31. Мәктәпкә мөмкин кадәр иртә йөрегез, билгеле вакыты җиткәч, башкаларның әйткәннәрен көтмичә, үзегез белеп хәзерләнегез вә кеше әйтмәстән элек чыгып китегез!

32. Мәктәпкә баргач әдәпле генә үз урыныгызга утырыгыз, дәрес вакытында сөйләшмәгез, гыйлем өйрәнү өчен ихлас тырышыгыз, әдәп өйрәнегез, күркәм холыклы булуны олы бәхет дип белегез, яшь вакытлар гомердә бер генә мәртәбә килүен, бу вакыт

бер үтеп киткәннән соң кире кайтып килмәвен, яшь вакытта тәрбия алмаган кеше — соңыннан һич тәрбия алмаячагын, гыйлем вә тәрбия юлында һичнәрсәне кызганырга ярамаганын онытмагыз!

33. Китап, кәгазь вә башка язу әсбапларыгызны чиста тотыгыз, каләмегезне киемегезгә вә чәчләрегезгә сөртмәгез вә авызыгызга капмагыз, бу нәрсәләр исә — бердән әдәпкә хилаф, икенчедән хәстәлеккә сәбәптер. Бармакларыгызны да пычратмагыз, ялгыш пычранса — су вә сабын белән яхшы юыгыз!

34. Мәктәптә уйнарга рөхсәт бирелгәч, әдәп белән генә уйнагыз, уйнар өчен яхшы һавалы урыннарны эзләгез, пычрак урыннарда, тузан вә балчык арасында һәм кояшта уйнамагыз, чөнки бу нәрсәләрдән адәм баласына хәстәлек пәйда булыр.

35. Мәктәпкә барганда вә кайтканда тәрбиясез кызлар белән берлектә йөрмәгез. Кибет каршы ларын да вә башка кызык урыннарда тамаша итеп туктап тормагыз, бәлки олы кешеләр кебек туп-туры, төп-төз булып, әдәпле генә йөрегез!

36. Өйгә кайтып кергәч, ата вә аналарыгыз белән исәнләшегез, кулларын үбегез, моннан соң китапларыгыз вә язу нәрсәләрегезне билгеле урыннарына куегыз, киемнәрегезне дә урыннарына урнаштырыгыз!

37. Аталарыгыз вә яки башка бөек затлар вә хөрмәтле кунаклар әгәр дә сабакларыгызны укытып карарга теләсәләр, һич назланмагыз, карышмагыз, бәлки фәрман вә максатларын камил рәхәтлек белән җиренә җиткерегез!

## 7. МӨГАЛЛИМНӘР ӘДӘБЕ

38. Сезне гүзәл вә гакыллы кешеләр булсыннар дип тәрбияләүдә булган мөгаллимнәрегезне олылагыз, нәсыйхәтләрне җиренә җиткерергә тырышыгыз, сүзләренә каршы килмәгез, боларны аналарыгыз кебек күрегез, остазларыгыз дәрәҗәсендә сөегез, алар хозурында әдәпле булыгыз, һәр сүзләрен ихлас белән ишетегез!

39. Дәрес вакытында кул-аякларыгыз белән уйнамагыз, чит тарафларга караштырып утырмагыз, яныгызда булганнар белән сөйләшмәгез, дәресегезгә карамаган китапларны актармагыз!

40. Мөгаллимәгез сүз сораганда туры карап торыгыз, кулларыгызны күкрәгегезгә куегыз, ни сораганын яхшы аңлагыз вә белгән җавапны ачык тавыш белән бирегез, игътибар белән сөйләгез!

41. Белмәгән сүзләр вә аңлашылмый калган дәресләр булса, мөгаллимәдән әдәпле генә сорагыз, дәрес вакытында башка нәрсәләргә зиһен җибәрмәгез!

42. Мөгаллимәләр белән кычкырышмагыз, бәлки аларның файдалы нәсыйхәтләре белән гамәл кылыгыз, тәрбия байлык дип белегез, тәрбияле вә гүзәл холыклы адәмнәр булырга тырышыгыз!

## 8. ИПТӘШЛӘР ӘДӘБЕ

43. Мәктәп иптәшләре белән инсафлы булыгыз, ал арны туганнарыгыз кебек күрегез, әдәпле генә сөйләшегез, ачык йөз белән каршы алыгыз, хәсрәтләрне вә шатлыкларны уртаклашыгыз, кимчелекләренә күз йомыгыз!

44. Әдәпсез эшләре вә бозык холыклары күренә башлаган иптәшләрегездән саклык белән, сиздермичә, аз-аз ерагаеп, соңыннан тәмам аерылыгыз вә тагын килеп кушылмагыз!

45. Иптәшләрегезгә үзегезне мактамагыз, аларга тәкәбберләнмәгез, аларны мәсхәрә итмәгез, алардан көлмәгез, тел вә кул белән аларны куркытмагыз, аларга хәсрәтле хәбәрләр сөйләмәгез, алар белән гадәттән тыш уйнамагыз, әдәпкә хилаф эшләрдә булмагыз!

46. Тәрбиясез кызлар белән сөйләшеп утырмагыз, алар белән дус булмагыз, болар белән дус булу вә катышып йөрү — холык бозар өчен иң көчле сәбәп икәнен онытмагыз.

47. Иптәшләрегезгә хөрмәтле булыгыз, тәрбияле кызларның сөйләшеп утыруларын байлык дип белегез, аларның холык вә фигыльләреннән үрнәк алыгыз. Арагызны заман аерганда, бер-берегезне онытмыйча хәлләрегезне белеп, мөмкин булганда хат язышып торыгыз!

48. Адәм баласының дәрәҗәсен белдереп торучы нәрсә — бер-ике генә юл булса да язган хатыдыр. Ике-өч юллык хат белән дә халык аны язучының мәртәбәсен ачык белер. Шуның өчен хатларыгызны гаять дикъкать вә фикер белән языгыз!

49. Үз исемегезгә булмаган хатларны ачмагыз, имзасыз буларак яки вак-төяк кәгазьләргә китап вә дәфтәрләрдән ертып алынган кәгазь кисәкләренә һичвакыт хат язмагыз, хатларыгызны конвертсыз җибәрмәгез, маркасыз булганда почтага бирмәгез!

## 9. ЙӨЗ ӘДӘПЛӘРЕ

50. Йөз — күңелнең көзгесе, адәмнәрнең шәфкатьле вә каты булуларының билгесе булганлыктан, һәрвакыт йөзегез турында игътибарлы булыгыз, бер кеше белән сөйләшкәндә икенче тарафка карап тормагыз, үзегезгә карамаган кеше белән сөйләшмәгез, хәсрәтле кешенең йөзенә көлмәгез, шат кеше йөзенә хәсрәт белән карамагыз, бәлки хәсрәтл ел әрнең хәсрәтләрен җиңеләйтерер рәвештә булыгыз!

51. Иптәшләрегез белән берлектә булганда, аларга яхшы йөзле булыгыз, аларның рәхәтләрен җибәрер рәвештә караң, гы чырайлы булып тормагыз, мәҗлес вә туйларда булганда, һәркемгә ачык йөз күрсәтегез, ләкин артык көлмәгез, вәкарьле вә сабыр булыгыз!

52. Күзегезгә зарар булмасын өчен, бик якты һәм нечкә нәрсәләргә, ак вә кызыл төсләргә озак вакыт карап тормагыз, күз өчен зарарсыз төсләр — яшел вә күк төсләрдер.

53. Йөзегезне саф вә сабынлы һәм салкын су белән һәрвакыт юыгыз, ләкин бизәнүзиннәтләнү нияте белән йөзегезгә кершән вә иннек, иреннәрегезгә кызыл, кашларыгызга

кара буяулар сөртмәгез, Аллаһы Тәгалә яраткан әгъзаларыгызны шәригать боермаган рәвешчә бозмагыз, бу әйберләр исә — тәрбиясез вә түбән холыклар билгеседер.

54. Кайбер вакыт акробат кебек, битләрен вә кулларын буяган хатыннар күрсәгез, һәрникадәр кызыклы вә көлке булсалар да сабыр итегез, көлмәгез, бәлки тәрбиясезлекләренә ачыныгыз, кайгырыгыз.

## 10. АВЫЗ ӘДӘПЛӘРЕ

55. Тешләрегез белән тырнакларыгызны өзмәгез, телегез белән иреннәрегезне яламагыз, иреннәрегезне кысмагыз, сөйләшкән вакытыгызда авызыгыздан төкерек чәчмәгез, халык алдында авыз ачып иснәмәгез, киерелмәгез, төчкермәгез, иснәгән вакытыгызда һәм ютәлләгәндә сөйләшмәгез, бәлки яулык белән авызыгызны каплагыз һәм читкә башыгызны борыгыз, ютәл вә иснәү кат-кат булса, халыкның рәхәтен бозмас өчен, мәҗлестән чыгып торыгыз!

56. Бөекләр сөйләшкәндә сүзгә катышмагыз вә үзегезгә әйдәшмәгәндә алар хозурында сөйләмәгез, сөйләшкән вакытыгызда артык акрын вә бик кычкырып сөйләшмәгез, бер сүзне күп мәртәбә кабатламагыз!

57. Сөйләшкәндә, гакыллы кешеләр кебек аз вә акрынлык белән сөйләгез, сөйләшер өчен иптәшләрегезгә вә мәҗлестә булганнарга вакыт калдырыгыз, сөйләүче булганда тыңлагыз, тыңлаучы булганда яхшы сөйләгез, кеше сүзен ахырына кадәр сабыр итеп тыңлагыз!

58. Бер кеше сүз башлаганда, кирәге булмаса — шул хәлеңчә калдырып китмәгез, олы кешеләр сүзенә каршы сөйләячәк сүзегез булганда, тиешле вакытны көтеп, әдәп белән сөйләшегез!

59. Аңларга тиешле булган бер сүзне тәмам аңламаган хәлдә «Аңламадым, тагын сөйлә!» рәвешендә тәрбиясезлек күрсәтмичә, «Аңлап җитә алмадым, тагын сөйләргә мөмкин булмасмы? Рәхим итеп сөйләгез бәлки аңлар идем!» дигән кебек инсаф белән үтенегез!

60. Сөйләшкәндә кычкырмагыз, җиңелләнеп вә кызып китмәгез, тавышыгызны бозмагыз, үзегез аңламаслык сүзләрне катыштырып сөйләмәгез, һичкемгә яман сүз әйтмәгез, хосусан «Белмисең, ялган сөйлисең, аңламыйсың» димәгез, мондый сүзләр — иң тәрбиясез адәмнәргә хас сүзләрдер.

61. Сүзегезгә каршы килүче булганда ачуланмагыз, бәлки «Ихтимал, сезнең сүзегез дә дөрес булыр, ләкин мин болай дип белә идем!» дип әйтү кебек әдәпле вә мөлаем җаваплар кайтарыгыз!

62. «Белмисең, ялган сөйлисең!» диюче кешегә каршы каныгызны һич бозмагыз, ахмаклар кебек кызмагыз, бәлки үз сүзегезнең дөрес икәнлегенә гүзәл сурәттә дәлил күрсәтегез. Ләкин ахмак адәмнәргә һичбер җавап итеп шөгыльләнмәгез, бәлки дәшмәгез вә яннарыннан бер читкә китегез, ал арга исә дәшмәү кадәр шифалы җавап булмас.

63. Гүзәл сөйләгән вакытыгызда сүзегезне әйтмәстән элек көлмәгез, сүзегезне әйткәннән соң да көлмәскә тырышыгыз!

64. Сөйләшкән вакытыгызда ялган сөйләмәгез, гайбәт әйтмәгез, сүз йөртмәгез, кеше сүзен арттырып күчермәгез, үлемне ялган сөйләүдән артык күрегез, дөрес сүзле хатыннар — иң хөрмәтле хатыннар, бәлки иң хөрмәтле кешеләр икәнен онытмагыз, ялгыш сөйләвегезне белдерегез дә хатагызны таныгыз!

65. Сөйләгән вакытыгызда ант итмәгез, «дөрес сөйлим» димәгез, бәлки боларга гөнаһ кылучы булмаганыгыз хәлдә үз инсафыгыз белән дөрес сөйләгез, ант итү вә «чын дөрес сөйлим» дип әйтү — ялганчылар билгеседер.

66. Һәр ишеткәнегезне сөйләмәгез, сүзегезне артык озын итмәгез, кирәге булмаганда кайгылы сүзләрне күчереп сөйләмәгез вә һичкемгә урынсыз каршы сөйләмәгез, үзегездән вә башкалардан шикаять итеп, бер тоташтан мөгрәп утырмагыз, ашыгып ачуланмагыз!

67. Үз-үзегезне мактамагыз, үзегезгә кирәк булмаган сүзләргә катышмагыз, чит кешеләр серләрен тикшереп йөрмәгез, ике кеше сөйләшкәндә араларына барып кермәгез, үзегезгә әманәт ителгән серләрне шәригать рөхсәтеннән башка җирдә һич фаш итмәгез!

68. Җиргә вә стеналарга төкермәгез, бәлки моның өчен яныгызда ак вә кечкенә һәм гаять пакь булган борын яулыгы йөртегез, язган, тегү теккән яки кайчы белән берәр нәрсә кискән вакытыгызда телегезне тибрәтмәгез, иреннәрегезне боргаламагыз, башыгызны бер якка авыштыручан булмагыз!

69. Тәһарәт алганда вә ашаганнан соң, һәрбер мәртәбәсендә авызларыгызны тәмам пакьләгез, теш казыгычы белән чистартыгыз, эчендә вә теш араларында бернәрсә калдырмагыз!

## 11. БОРЫН ӘДӘПЛӘРЕ

70. Кулларыгыз белән борыныгызны тотып утырмагыз, бармакларыгыз белән казынмагыз. Ялангач кулыгыз белән яки киемнәрегезнең берәр җире белән борын сеңгермәгез, бәлки борын сеңгерер өчен яныгызда борын яулыгы булдырыгыз, кеше яулыгы тотмагыз!

71. Ашаган вакытыгызда борын сеңгерү кирәк булса, башыгызны бер тарафка борыгыз, тавышсыз гына сеңгерегез, яулыкларны кешеләр күз алдында тотмагыз, төчкергәндә дә шулай эшләгез!

72. Һавада очып йөргән микроблар кереп урнашмасын өчен, тәһарәт алганда вә хосусан госел коенганда борыннарыгызны яхшы юыгыз вә һич ялкауланмыйча пакьләгез.

## 12. КОЛАК ӘДӘПЛӘРЕ

73. Колакларыгызны яман сүзләр ишетүдән саклагыз, гайбәт вә яла кебек шәригатьтә хәрәм булган сүзләрне тыңламагыз, әгәр дә боларны сөйләүче бөек кешеләр булса, риза түгеллегегезне йөзегез белән белдереп тик утырыгыз. Зарар булмаслыгын белсәгез — бер читкә китеп вә мәҗлестән чыгып утырыгыз, әгәр дә иптәшләрегез булса, әдәпле генә үгетләгез, «Һәркемдә бер төрле кимчелек булыр, безнең кимчелегебез, бәлки тагын да артыктыр» дигән кебек сүзләр әйтегез, әгәр дә кечеләр булса, шәфкатьле генә тыегыз!

74. Колакларыгызны хосусан йокыдан торган вакытыгызда саф су белән юып пакьләгез, тузан оялатып вә каралтып йөртүдән әлбәттә сакланыгыз!

75. Олуг вә авыр алкалар асып, колакларыгызны бозмагыз яки бөтенләй кимәгез. Кирәк булмаганда, һава керүдән туктатыр дәрәҗәдә калын шәлләр урап утырмагыз!

76. Каты тавышлар колакка зарарлы булганы өчен мөмкин кадәр ерак торыгыз, кирәк булмаганда вә яки табиб кушмаганда колакларыгызга мамык тутырып йөрмәгез!

## 13. КУЛ ӘДӘПЛӘРЕ

77. Халык күз алдында кулларыгызны чапмагыз, авыштырмагыз, сөйләгән вакытыгызда бутамагыз, шартлатмагыз, йөзегезгә куймагыз, чәчегез вә башка җирләрегез белән уйнап утырмагыз!

78. Һәрбер пычрак вә майлы нәрсәләр тоткан вакытыгызда кулларыгызны юыгыз, сөлге белән яхшы сөртегез, юеш килеш кием, китап яки башка нәрсәләр тотмагыз!

79. Тырнакларыгызны кеше күзе алдында кисмәгез, тырнакларыгыз астына җыелган керләрне пакьләгез, тырнакларыгызны үстереп йөртмәгез, кискәннән соң һәм туры килгән бер җирдә ташламагыз, бәлки тәннән аерылган вә алынган тырнак вә төкләрне бер җиргә җыеп, соңра туфрак астына күмегез!

80. Бармакларыгызны йөзек вә балдак белән тутырмагыз, бер вә ниһаять ике данә белән канәгатьләнегез, шулай ук беләкләрегезгә кат-кат беләзекләр кимәгез!

## 14. ЧӘЧ ӘДӘПЛӘРЕ

81. Чәчләрегезне кер вә тузан вә башка нәрсәләрдән саф вә пакь йөртегез. Һәркөнне тарагыз, көйдермәгез, бөтермәгез, табигый хәлен бозмагыз!

82. Чәчегезне тәрбияләп, авырмаган хәлдә һичкемнең хәлен белергә китмәгез, кунаклар хозурына чыкмагыз. Һәрхәлдә шәригать дөрес күрмәячәк кешеләргә күрсәтмәгез!

83. Авырган вакытыгызда артык тыгызламагыз, башкаларның чәчләрен кушып асмагыз, чәч очына олы тәңкә вә яки авыр нәрсәләр такмагыз.

## 15. БАШ ӘДӘПЛӘРЕ

84. Башыгызны гадәттән тыш түбән вә яки бер якка салмагыз, кулыгыз белән башыгызга таянмагыз, халык күз алдында кашымагыз!

85. Кыш көнендә беркадәр эссе вә яки җәй көнендә бераз салкын булган су белән һич булмаганда атнага бер тапкыр сабынлап юыгыз, юганнан соң, берникадәр тормыйча салкын һавага чыкмагыз!

86. Юыныр вакытыгызда — ашаганнан соң өч сәгать кадәр сабыр итегез, юынганнан соң яхшы корытыгыз һәм тизлек белән киемнәрегезне киегез, кызу көннәрдә йөз, кул, аякларыгызны күп мәртәбә юыгыз!

## 16. УТЫРУ ӘДӘПЛӘРЕ

87. Утырган вакытыгызда, кирәк булмаса таянмагыз, бөгелмәгез, ятмагыз, бәлки төп-төз буларак утырыгыз!

88. Сөйләшкән кешегә кулыгызны куймагыз, бер аягыгызны икенчесе өстенә салмагыз, аяк-кулыгыз белән уйнамагыз!

89. Укыган вә язган вакытыгызда күзегез белән китап вә кәгазь арасын бер карыштан аз куймагыз. Күкрәгегез белән өстәлгә тәмам таянмагыз, әгъзаларыгызга зарар китермәс рәвештә утырырга гадәтләнегез!

## 17. ЙӨРҮ ӘДӘПЛӘРЕ

90. Йөргән вакытыгызда бик ашыкмагыз, йөгермәгез яки бик акрын йөрмәгез, юлда булган кешеләрне этеп төртмәгез, тәннәрегезне селкетмәгез, кулларыгызны бутамагыз, гадәттән тыш кычкырып сөйләшмәгез, «kah! kah! kah! keh! keh! keh!» итеп көлешмәгез, кулларыгызны кесәләрегезгә тыкмагыз!

91. Аякларыгызны сөйрәмәгез, өстерәмәгез, як-ягыгызга каранмагыз, кешеләрдән көлеп калмагыз, бер кешене мәсхәрә итеп, аның кебек булып күрсәтмәгез!

## 18. ЙОКЫ ӘДӘПЛӘРЕ

92. Ятачак урыныгызны үзегез җәегез, тузан вө юешлек кебек нәрсәләрдән пакьләгез, торган вакытыгызда үзегез җыеп куегыз?

93. Мөмкин булганда, йокыгызны тәртип белән үтәгез, иртә ятып иртә торыгыз, ягъни тугыз сәгатьтән калмыйча йоклагыз вә алты сәгатьтән калмыйча торыгыз• Вә вакытында булачак йокыны калдыру сәламәтсезлеккә сәбәп булачагыннан, гадәтләнгән вакытыннан кичектермәскә тырышыгыз. Ярты төн әүвәлендә булган бер сәгать йокы ярты төн соңында булган ике сәгать йокыга бәрабәрдер дигән сүзне онытмагыз!

94. Чалкан ятканда яман төшләр күрелүе вә бастырылу дигән нәрсәләр булганы өчен, йөзтүбән яту бозык һава суларга сәбәп булганы өчен, ягыгыз белән ятыгыз.

95. Кирәк булмаганда бер бүлмәдә күп кеше булып җыелып ятмагыз вә салкыннан саклану өчен өстегезгә бернәрсә ябыгыз, йокы вакытларында тәрәзәләрне ачык хәлендә калдырмагыз!

96. Йоклаган вакытыгызда изү вә бауларыгызны чишегез, тыгыз балдакларыгыз булса салыгыз, киемнәрегезне кысан хәлендә куймагыз, кан йөрүне туктатачак нәрсә булмасын, зарарлыдыр.

97. Йокы бүлмәсендә хушбуй, чәчәк вә гөлләр булдырмагыз. Ятмастан элек һәм торган вакытыгызда (яки көне булса) тәрәзәләрне ачып, һавасын яңартыгыз, йокы бүлмәсендә яңа саф һава булуы тиештер.

98. Хәсрәт вә кайгылы вакытларда йоклау өчен беркадәр күңелегез рәхәтләнүен сабыр итеп көтегез. Ашказаныгыз тулы вакытта да йокламагыз, бәлки ашыгыз сеңгәнче сабыр итегез!

## 19. АШАУ ВӘ ЭЧҮ ГАДӘТЛӘРЕ

99. Тәрбияле кызлар белән тәрбиясез кызлар аш янында мәгълүм булыначагыннан хәбәрдар булып, ашаган вакытыгызда әдәпле булыгыз!

100. Аш янына барлык кеше утырганнан соң, үзегезгә яраклы булган урынга инсаф белән генә утырыгыз!

101. Ашарга утырганда аш әйберләре белән уйнамагыз, тәнегезне кашымагыз, ашъяулыкка бик якын да, бик ерак та булмагыз, кулыгыз белән таянмагыз, туры утырып ашаган вакытыгызда ашар өчен беркадәр башыгызны түбән иегез, уң кулыгыз белән ашагыз!

102. Тастымалны тезләрегезгә куегыз» ләкин бу тастымалларга тир сөртмәгез, борын сеңгерсәгез, иң элек “бисмилла” әйтегез, соңыннан ашарга тотыныгыз!

103. Ашаган вакытыгызда комсызланмагыз, берсен яхшы чәйнәп йотмастан элек икенчесен авызыгызга алмагыз, авыз тутырып капмагыз, кашыгыгызны табакның һәр тарафына йөртмәгез!

104. Ашалачак нәрсәләрне актармагыз, берен куеп икенчесен сайламагыз, яныгызда булган хатын вә кызларга уңайсызлык тудырмагыз?

105. Олылар мәҗлесе булмаганда иптәшләрегез белән әдәпле генә, сабырлык белән сөйләшегез, ләкин сүз ярыштырмагыз. Хәсрәтле сүзләр сөйләшмәгез, үзегезнең ашавыгыздан вә башкаларның ашауларыннан һич сүз чыгармагыз.

106. Кунакта булган вакытыгызда ашарга яки чәй эчәргә өй хуҗасы үтенсә, вакытыгыз булса — сүзләрен кабул итегез, вакытыгыз булмаса — үз-үзегезне көчләмәгез, бәлки «Рәхмәт, рәхмәт әйтәм!» кебек мөлаем сүзләр белән җавап бирегез!

107. Бер кеше сораган суны элек сез алып эчмәгез, су эчкән вакытыгызда тавышсыз вә әдәп белән авызыгызда әйбер юк вакытта эчегез, соңыннан тастымалыгыз белән авызыгызны сөртегез!

108. Кунакта булган вакытыгызда «Мин моны яратмыйм!» дип әйтү кебек сүзләр сөйләшмичә, бәлки «теләмим» кебек сүзләр белән гүзәл гозер күрсәтегез вә сый-хөрмәтләренең яхшы икәнлеген аңлатыгыз.

109. Башкаларны чакырган вакытыгызда сый-хөрмәтләрегезне мактамагыз, ашагыз-эчегез дип кыстамагыз. Кешенең оялып артык ашавына сәбәп булмагыз, кунакларны кыстау аларның рәхәтләрен җибәрү икәнен онытмагыз!

110. Ашаган вакытыгызда күңел болгану, косасы килү, какырык-төкерек вә башка җирәнгеч вә күңел болгануына сәбәп булачак нәрсәләрне һич сөйләмәгез!

111. Кул сөртергә, шуның өчен хәзерләнгән пакь вә яхшы тастымаллар хәзерләгез, күлмәк вә башка киемнәрдән алынган чүпрәк кисәкләрен, зинһар кунаклар вә аш янына чыгармагыз!

112. Каз, үрдәк, күркә, ит вә күмәч кебек нәрсәләрнең һәммәсен кунаклар алдына турап ваклап чыгарыгыз. Кунаклар алдында боларны туратып, кадерле вакытларын исраф иттермәгез вә мәҗлестә булганнарны интектереп көттермәгез!

113. Кулларыгызда бетчә, кычу, җәрәхәт вә җәрәхәт әсәрләре булган хәлдә ит турамагыз вә мәҗлесне идарә итмәгез (табынчы булмагыз)!

114. Ашаганнан соң кулларыгызны, авызыгызны су вә сабын белән яхшы юыгыз вә тастымал белән сөртегез, теш араларыгызда ризык калдыклары калдырмагыз, юыныр өчен башкалар белән тыгызлашмагыз, бушаганнарын көтеп торыгыз!

115. Пешмәгән җимешләрне, хосусан кызу көннәрдә майлы ашларны артык ашамагыз, авызга алган ризыкларны тәмам чәйнәгез!

116. Тәмам ачыкмый торып, шулай ук каты шатлык вә хәсрәт вакытларында ашамагыз, ашаган вакытыгызда өстегезгә тар вә кысан киемнәр кимәгез, ачлык авыруы беткәннән соң тукталып, эчегез тулганын, ягъни ашыйсы килүегез бетүен көтмәгез, бу нәрсә — сәламәтлек югалу өчен олы бер сәбәптер, һичвакыт онытмагыз!

117. Ашаган вакытыгызда бик ашыкмагыз вә бик акрын да булмагыз вә ашаганнан соң беркадәр вакыт үтмичә торып су эчмәгез!

118. Эчәсегез килгәндә балчыклы, комлы, куе су һәм күл сулары вә бозлы сулар түгел, бәлки саф сулар эчегез!

## 20. ЧӘЙ ЭЧҮ ӘДӘПЛӘРЕ

119. Кунак алдына чыгарылачак чәй әсбапларының керсез, тузансыз, гаять тә саф вә пакь булуына дикъкать итегез, самоварыгызны чистартып, көл, күмер кебек нәрсәләрдән пакьләгез!

120. Күгәргән вә тутыккан пычаклар белән лимон кисмәгез, лимонны калын вә эре турамагыз, хуҗалар ихластан үтенеп әйтмәгән вакытта кунакка барганда, чәй янында булган әфлисун, алма вә башка җимешләрне кисмәгез, салып китмәгез!

121. Эчкән вакытыгызда чәйнең чүпләрен тәлинкәгә салмыйча, бәлки йомры вә стакан төбендә сыгып калдырыгыз, чәегезне дә тавышсыз вә шапырдатмыйча эчегез, бөекләр алдында алардан элек эчәргә башламагыз, тәлинкәгезне ике кулыгыз белән тотмагыз, кирәк булмаганда сул кулыгыз белән эчмәгез!

122. Чәй бөртекләрен чәйнеккә салмастан элек, кайнаган су белән чәйнекне чайкап бер мәртәбә кайнарлап түгегез вә чәй бөртекләре салынганнан соң кайнап торган суны кызу чәйнеккә җибәрегез. Чәй эчүдә булган шартларның иң олылары шушы ике төрле шарт булганлыктан, болар хакында һич ялкауланмагыз!

123. Чәйнең иң файдалы матдәсе — суынуы белән очуыннан, чынаякка салынуыннан соң өч-дүрт минуттан артык тотмыйча әчегез вә суынуын көтмәгез. Ләкин бик кайнар хәленчә эчәргә керешмәгез!

124. Кунакта булганда чәй янында булган бал, вареньены катык кебек ашамагыз, кашык тутырып алмагыз, ашъяулыкка тамызмагыз, хәзерләнгән булса — вак савытларга бүлеп алыгыз (шәһәр җирләрендә шундый гадәт бардыр), хәзерләнмәгән булса — кашык белән агызмыйча гына алыгыз!

125. Чәй янына күбесе зиннәт өчен куелган нәрсәләрне, кунакка барган вакытыгызда икмәк урынына ашамагыз, бәлки махсус ашар өчен куелганнарны авыз итегез вә башкаларны саклык белән алыгыз!

126. Чәй янында каймак вә майлы ашлар булса, киемнәрегезгә тамызмагыз, кулларыгызны майламагыз, майлы кулларыгызны киемнәрегезгә вә читекләрегезгә сөртмәгез, һәрни булса да — чиста вә саф булыгыз!

## 21. КИЕМ ӘДӘПЛӘРЕ

127. Тәрбиясезлеккә вә яки исраф итүчеләргә хас булган киемнәрне кимәгез, бәлки халык күзендә әйбәт сыйфатлы, ят һәм көлдергеч булмаган киемнәрне, вә озын гомерле булган нәрсәләрне ихтыяр итегез, кием турында һичкем белән ярышмагыз, кеше белән ярышу (кием турында) олы бер бәла икәнлеген истә тотыгыз!

128. Киемнәрегезне керле йөртмәгез, халык сөйли дип мода сөйләмәгез, модага әсир булмагыз, һәркем тарафыннан хуш күрелгән, ясалма булмаган киемнәрне киеп, моданы үзегезгә әсир итегез!

129. Үзегезгә, хәл вә дәрәҗәгә туры килмәгән киемнәрне хәтта кодрәтегез җитсә дә кимәгез, бөек гаиләләр вә байлар гадәтенчә киенергә көчәнмәгез вә кызыкмагыз! Кызларның иң сөйкемле булганнары — гадәти киемнәрдә, саф һәм чиста киемдә булганнарыдыр.

130. Башкаларның киемнәрен кимәгез, мөмкин булганда үз киемнәрегезне башкаларга кидермәгез, башкаларның саф вә чиста киемнәренә кызыкмагыз, бәлки үз киемнәрегезне саф вә чиста йөртегез!

131. Муеннарыгызга көмеш тәңкә тезелгән камыт кимәгез, чәчләрегезгә авыр чулпы вә тәңкәләр такмагыз, ашаган вакытыгызда кышкы вә тышкы киемнәрегезне салып утырыгыз!

132. Өстегездән салганнан соң, киемнәрегезне анда-монда, хосусан юеш вә пычранган киемнәрегезне ташламагыз, бәлки яхшы төреп вә киптереп, билгеле урыннарына куегыз!

## 22. ЗИННӘТ (БИЗӘНҮ) ӘДӘПЛӘРЕ

133. Кызларга бизәнергә дөрес икәнлеген дәлил тотып та, гомерегезне бизәнеп кичермәгез, потларга табынучылар мисалында бер тоташтан көзге тирәсендә йөрмәгез, хатын вә кызларның мәхәббәтләре иң табигый вә тәрбияле булганнары икәнен белегез!

134. Сәламәтлеккә зарарлы, дин вә гакылга хилаф булган зиннәтләрдән ерак булыгыз, үзегезне олы вә халык арасында игътибарлы итәчәк рәвештә мөлаем сурәттә бизәнегез!

135. Әдәпсез хатыннар кебек йөзләрегезгә, иреннәрегезгә ак вә кызыл буяулар сөртмәгез, кашларыгызны йолыкмагыз, кашларыгызны, тешләрегезне карага буямагыз!

136. Беләкләрегезне, муеннарыгызны, күкрәкләрегезне ачык йөртмәгез, чәчләрегезне вә яланаякларыгызны читләргә күрсәтмәгез, бу нәрсәләргә исә кадерле динебезнең рөхсәте юк икәнлекне онытмагыз!

137. Тар вә кысан киемнәр кан йөрүенә зарар иткәнлектән, бераз иркен киемнәр киегез, ләкин иркен киям дип, гадәттән тыш иркеннәрне киеп, чүмәлә кебек булып йөрмәгез, һәрнәрсәнең гадәтчәсе яхшы икәнлегенә шикләнмәгез. Алъяпкыч бауларын вә башка моның кебек нәрсәләрне артык кысып бәйләмәгез, әмма зинһар корсет кимәгез!

138. Мөмкин булганда, тән өстендә әүвәлге катта булачак киемнәрне ак киндерләрдән булдырыгыз, әгәр дә үзегез сугып киндер ясап кияр булсагыз — бигрәк гүзәл булыр.

139. Кирәк булмаганда башыгызга бүрек кимәгез, башыгызны эссе йөртмәгез, йөзегезгә пәрдә куйганда, тын йөри алмаслык рәвештә бик калын яки ап-ачык күрсәтеп тотырлык рәвештә бик сирәк нәрсәләрдән куймыйча, бәлки уртача булганны куегыз. Аякларыгызны суыктан саклагыз, мөмкин кадәр җылы йөртегез, өшетмәгез!

## 23. РИЯЗАТ (ГИМНАСТИКА) ӘДӘПЛӘРЕ

140. Риязат, ягъни гимнастика сеңерләрне вә итләрне хәрәкәтләндерер, каннарны йөртер, ашыйсы килүне куәтләндерер, ашказанын җиңеләйтерер, шуңа нигезләнеп, яраклы вакыты вә заманы белән әдәпле генә риязат та ясагыз, җәяү йөрү, тән хезмәтләре итү, Аллаһы Тәгаләнең фарыз иткән намазларын уку — һәммәсе риязаттыр.

141. Уйнаган вакытыгызда үзегезгә яраклы вә әдәпләргә каршы булмаган рәвешчә уйнагыз, шәригать каршында бозык саналган мәҗлесләргә бармагыз.

142. Уеннарны фәкать беркадәр күңел ачар өчен генә уйнап, соңыннан шөгылегезгә керешегез. Бөтен вакытыгызны уенга корбан итмәгез, уен вакытында тәрбиясез кызлар кебек кычкырышып бакырмагыз, мәзәк сөйләшмәгез, бер-берегезне мәсхәрә итешмәгез, ачуланышмагыз вә уен вакытында булган сүзләрне вә хәлләрне соңыннан шикаять итеп сөйләп йөрмәгез!

143. Тәрбиясез вә гакылсыз кызлар белән уйнамагыз, алар белән дус вә белеш булмагыз, йөрергә кирәкле булган уеннарда ашыгыз сеңгәнен көтегез, уйнап тәннәрегез кызганда салкын нәрсәләр эчмәгез вә салкын урыннарда тормагыз!

## 24. ЗИЯРӘТ (ХӘЛ БЕЛӘ БАРУ) ӘДӘПЛӘРЕ

144. Якыннарыгызны зиярәт итәргә булганда, артык кирәге яки нык вә аеруча дуслыгыгыз булмаса, аларның эшсезрәк вакытларын ихтыяр итегез, чөнки кешенең эшен калдыру — әдәпкә каршыдыр.

145. Керле киемнәрегез вә эш киемнәре белән зиярәт итмәгез, кунаклар янына да чыкмагыз, бәлки бу эшләрнең саф вә чиста сурәттә булуына дикъкать итегез. Көтмәгәндә, шулай бер ваемсыз вакытында берсе килеп керсә, гүзәл сүз белән гафу үтенегез. Шулай ук юлдаш ларыгыз дан артык сурәттә киенмәгез!

146. Мәҗлесләргә барганда, барып керүегез белән тышкы киемнәрегезне салып куегыз, мәҗлескә җыелган кешеләрнең иң олыларыннан башлап иң кечеләренә кадәр тәртип белән күрешегез, исәнләшегез, күп кеше булганда бер баштан башлап күрешә бару да ярыйдыр. Бөекләр алдында гаять әдәпле бер хәлдә утырыгыз!

147. Кунак килгәндә ачык йөз белән каршы алыгыз, тиешле урынга утыртыгыз, әгәр дә бөек бер кеше булса — килгәне өчен рәхмәт әйтегез вә мөмкин булса — зиярәтне каршы кайтарыгыз!

148. Зиярәт иткән өегездә өй әйберләре белән уйнамагыз, китапларны актармагыз, әйберләрне тотмагыз, аулак урыннарына, хосусан йокы бүлмәләренә үзлегегездән кереп йөрмәгез!

149. Зиярәтенә барган кешегез, бернәрсә язу яки уку белән шөгыльләнсә, ни укыганын вә ни язганын сорамагыз!

150. Кирәкле бернәрсә укыган вә язган вакытыгызда берәр кеше зиярәтегезгә килсә: «Сезгә читен булмаса — эшемне тәмам итәр идем!» — дип гафу үтенегез!

151. Хәстәләр хәлен сорарга барган вакытыгызда озак тормагыз. Кайгылы сурәт белән аз сөйләгез, хәстәне көендерәчәк нәрсәләр сөйләүдән сакланыгыз вә һич шелтәләмәгез, хәтерен калдырмагыз!

152. Шикаятьләре булса тыңлагыз, йомшак сүзләр белән хәсрәт кызуын сүндерергә тырышыгыз, мөмкин кадәр куркуларын җибәрегез, сәламәтлеге өчен тышыгыздан да эчегездән дә ихлас дога кылыгыз!

153. Ашатыр өчен барганда өстегезне зиннәтләмичә, гадәти рәвештә барыгыз, хәсрәтле сыйфатта булыгыз, көлмәгез, гүзәл сүзләр (уен вә мәзәк) сөйләмәгез!

154. Кунакларны өйләренә кайтып киткән вакытларында шул заманның вә ерак гореф-гадәте белән озатып калыгыз!

## 25. ХӘСТӘЛӘРНЕ КАРАУ ӘДӘБЕ

155. Бөтен гомерегез — кызлык, хатынлык, аналык диелгән өч хәлдән гыйбарәт булганлыгы вә хәстәләрне карау хезмәте дә бу хәлдә булган кешеләрнең хезмәте булганлыктан, бу хезмәтләрне игътибар белән үтәгез!

156. Хәстәләрнең яннарында, һәрвакыт кушканнарына көтеп торучы буларак, хезмәтләрендә торыгыз, кечкенә генә сурәттә булучы сүзләренә колак салыгыз, теләкләрен шунда ук үтәгез, һич авырсынмыйча озын төннәрне аларның хезмәтләрендә үткәрегез!

157. Хәстәләргә сүз сөйләгән вакытыгызда балаларга сөйли торган итеп сөйләгез, ал ар дан каты сүз вә шелтәләр ишетсәгез сабыр итегез. Яннарында тавышланмагыз, күңелләрен бозачак сүзләрне вә хәсрәтле хәбәрләрне сөйләмәгез!

158. Хәстәләрне мөмкин кадәр саф вә пакь тотарга тырышыгыз, табиб тыймаган сурәттә күлмәкләрен тиз-тиз алмаштырыгыз, күлмәкләрен салкын хәленчә түгел, бәлки җылы итеп кидерегез. Ята торган бүлмәнең һавасын саф хәленчә тотарга тырышыгыз!

## 26. ДИН ӘДӘПЛӘРЕ

159. Бөтен галәмне яраткан Аллаһы Тәгалә хәзрәтенең әмерләрен бөтен нәрсәдән артык күреп сөегез, хәлегездән килгән кадәр фарыз, ягъни үтәлүе тиешле булган гыйбадәтләрне үз вакытларында үтәгез, тыелган нәрсәләрдән тыелыгыз, белегез ки: дөнья вә ахирәт, хосусан кыямәт көнендә сыеначак җиребез — фәкать Аллаһы Тәгалә хәзрәтенең мәрхәмәтедер.

160. Пәйгамбәрләрнең һәрберсен чын күңел белән сөегез, аларның Аллаһы Тәгаләнең гөнаһсыз бәндәләре вә хөрмәтле, бөек илчеләре икәнен яхшы белегез!

161. Хәләл вә хәрамнәрне бәян иткән, ахирәт галәменә барачак юлыбыз булган ислам диненә камил ихлас вә мәхәббәтегез белән ябышыгыз, һәрбер яхшылык дин бинасы эчендә булып, дин һәр хәсрәтләребездә ярдәмче вә һәр тарлыкларда эчләребезне иркенләндерүче икәнен үзегез сынагыз!

162. Аллаһы Тәгалә каршында кимчелек белән хезмәттә торганлыгыгызны хәтерләп, гыйбадәт вакытларында әдәп вә инсаф белән булыгыз, һәрвакыт күңелләрегез белән тәүбә итегез, зәгыйфь коллар икәнлегебезне онытмагыз!

163. Һәр кеше белән гүзәл тереклек итегез, һәр кеше хакында мәрхәмәтле булыгыз, һәркемгә хәерхаһ-теләктәш булыгыз, һичнәрсә өчен үз-үзегезне белмәс дәрәҗәдә кайгырмагыз вә ачуланмагыз, һәрнәрсәнең гүзәл тарафын алга алыгыз, һәркемгә яхшы күренергә тырышыгыз, һәрвакыт көләч йөзле булыгыз, нәсыйхәт итүче кем булса да булсын, колак салыгыз «яхшы кеше — кеше сүзеннән гыйбрәт алыр» диелгән сүзне белми калмагыз!

164. Ата вә аналарыгыз, әби вә бабаларыгыз, туган вә кардәшләрегез, кыямәт көненә кадәр киләчәк бала вә тармакларыгыз өчен, ислам дине белән дөньядан үтү насыйп булуы хакында һәрвакыт, хосусан күңел нечкәргән чакларда Аллаһы Тәгаләгә дога кылыгыз! Ислам дине белән ахирәткә киткән кеше — иң бәхетле кеше икәнен һәрвакыт хәтерләгез! Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре мондый бөек дәүләт белән барчагызны бәхетле итсен!

## 27. ИҢ КЫЙММӘТЛЕ ВӘ ИҢ СОҢГЫ НӘСЫЙХӘТ

165. Кадерле диңгезгә зарар китермәс, әхлакыгызны бозмас, кызлык, хатынлык, аналык вазифаларына кимчелек итмәс вә белгәннәрегез белән тәкәбберлек итмәс шарты белән, ни булса да булсын, укыгыз!

(Тәмам)

# Олуглар вә бөекләр өчен

*Әхлак гыйлеменнән*

**III**

**китап**

## БИСМИЛЛӘҺИР-РАХМӘНИР-РАХИМ

Нәсыйхәт итүгә гакыл әһелләре, «Мин гүзәл холыклы бер адәм» дип әйтүнең мәгънәсе: шулай ук китап вә рисалә язуга да «Бу нәрсәләрне фәкать мин генә беләм» дип әйтү кебек бер мәгънә бирсәләр иде, нәсыйхәт сөйләү вә китап язу түгел, авызымнан бер хәреф чыгармас вә каләм белән кәгазьне кулыма тотмас идем.

Ләкин нәсыйхәт сөйләргә вә китап язуга гакыл әһелләре тарафыннан шундый мәгънәләр бирелмиләр. Бәлки, болар өстә булган бурычларны төшерү, азмы-күпме бер файдалы нәрсәне соңгы буыннарга ядкәр калдырудан гыйбарәттер.

Бер ата үзе никадәр гөнаһлы булса да булыр, моның сәбәбеннән балаларына нәсыйхәт бирү бурычы өстеннән төшмәс. Вә бер гаилә башлыгы, никадәр кимчелеккә дучар булса булыр, үзен саклавына әманәт ителгән гаиләсен тәрбия итү вазифасыннан азат вә мәхрүм тормас. «Һәрберегез — көтүчесез вә һәрберегез көтүләрегез хакында җавап бирәчәксез» мәгънәсендәге «күллүкүм рагун вә күллүкүм мәсьәүлүн гань рагыййәтиһи» дигән изге сүз — һәркем өчен бәрабәр булган бер хөкемдер.

Шушы сәбәп өчен, тәрбиясе өстемә әманәт ителгән гаиләмә вә моның белән бәрабәр үземә; шулай ук балаларым вә кыямәт көненә кадәр киләчәк тармакларыма нәсыйхәт итү вә хәл җиткән кадәр ядкәр калдыру максаты белән шушы нәсыйхәт китапларын яздым. Беренче нәсыйхәт — балалар өчен, икенче нәсыйхәт фәкать кыз балалар өчен язылмыш иде. «Күллүкүм рагун...» изге хәдисе озын буларак «Бохари шәрифтә» (изге Бохарида) телгә алынадыр. (6 том, 152 б.) Әгәр дә башкалар да укысалар вә файда да алсалар, безнең өчен ике мәртәбә файда булачактыр. Укып гамәл иткәннәрнең барчасын Аллаһы Тәгалә дөньяда һәм ахирәттә бәхетле итсен!

## 1. ӨЙЛӘНҮ ӘДӘПЛӘРЕ

1. Өйләнүдән максат — табигый хаҗәтне үтәү, бик хөр. мәтле Рәсулулла әфәндебез (Аңа Аллаһы Тәгаләнең хәер догасы һәм сәламе булсын!) хәзрәтләренең өммәтен күбәйтү, дөнья сәфәрендә һәрбер шатлык вә авырлыкларны күтәрәчәк бер иптәш булу, малны вә вакытны исрафтан һәм изге дине-безне зәгыйфьләндерүдән саклау булганлыктан, бик яшь вакытта өйләнмәгез, вакыты җиткәннән соң вакытыгызны уздырмагыз, бәлки табигать кушуы буенча, тиешле вакытында өйләнегез!

2. Изге хатын — дөнья тереклегендә иң куәтле бер таяныч; усал хатын — адәм угылы өчен олы бер бәладер. Шуның өчен алыначак хатыннарны кирәк бай вә кирәк фәкыйрь булсын, хөрмәтле гаиләләрдән эзләгез, туры сүзле вә яхшы күңел-ләрне табарга тырышыгыз, моның өчен хатыннар, баш кодалар сүзенә алданмыйча, бәлки үз күңел вә гакылыгыз белән гүзәл фикер йөртегез!

3. Иргә барырга булганда, ир булачак кешенең акчасыннан элек холкын; кабиләсеннән элек динен, гүзәллегеннән элек һөнәрен сорагыз вә үзегезгә тиңдәш булганнарны ихтыяр итегез!

4. Күркәм тереклек — мәхәббәткә, мәхәббәттә — табигать берлегенә бәйле булуы өчен: тереклек иптәшләрегез белән табигатьләрегез дә яраклы булуына дикъкать итегез. Ягъни һәрникадәр мөшкел булса да — табигатьләрегездә берлек булган кешеләрне

табарга тырышыгыз. (Гасырыбызда булган бер табиб үзенең әсәре булган бер язмасында табигать җәһәтеңчә тәмам каршы булган кеше белән өйләнешмәскә васыять иткәндер.)

## 2. ИР ӘДӘПЛӘРЕ

5. Хатыннарыгыз — кайгы вә шатлык вакытларында иптәшләрегез, дөнья тереклегендә юлдашларыгыз булганлыктан, аларны ихлас күңел белән сөегез. Урыннарның рәхәте гөл вә чәчәк яки һәртөрле зиннәтләр белән түгел, бәлки изге хатын белән булыр, моны исә гүзәл белегез!

6. Хатыннарыгызга дөнья вә дин кирәкләрен өйрәтегез, туры юлда йөрүләренә һәрвакыт ярдәм итегез, гакылларын вә диннәрен камилләштерү вә сәламәт тоту өчен тырышыгыз, аларга шәфкатьле вә ачык йөз белән карагыз, аларның ихлас вә мәхәббәтләренә каршы хыянәт итмәгез, хөрмәтләрен бетермәгез, изге хәдисләр боерганча мөгамәләдә булыгыз!

7. Ашату вә эчертүдә, кием-салым кебек нәрсәләрдә билгеле булганча, хакларын җиренә җиткерегез, көчләре җитмәслек хезмәтләр белән көчләмәгез, золым итмәгез, кул күтәрмәгез, аларны кәнизәкләр яки кирәк яхшы вә кирәк яман булса да, фәкать сезне ризалатыр өчен яратылган җан ияләре дип хисапламагыз!

8. Һәрникадәр гаилә башлыгы булсагыз да, холыксызлык күрсәткәннәре вакытта сабыр итегез вә һәрвакыт аларга үзегезне миһербанлы күрсәтегез, аларга ачу вә көч белән түгел, шәфкать белән өстен булыгыз!

9. Хатыннарның ялганчы, хәйләкәр, мәкерле булуларының баш сәбәбе — ирләрдер. Ал арның холыкларын бозучы вә чын адәмлектән чыгаручы кинә, ягъни яшертен дошманлык — ирләрдер. Шуның өчен хатыннарыгызны тәрбияләмәгән хәлегездә, аларны ялганчы, мәкерле вә фәлән дип сөйләмәгез, бәлки иң элек үзегез яхшы булыгыз вә соңыннан хатыннарга яхшы тәрбия бирегез, хатыннарыгыз һич шөбһәсез яхшы булырлар. Ирләр бозык булмасалар, хатыннар фәрештәләр кебек яхшы булырлар иде.

## 3. ХАТЫН ӘДӘПЛӘРЕ

10. Ирләрегезнең хосусан өй эчендә булган хезмәтләрен гүзәл вә рәхәтлек белән башкарыгыз, кушканнарын үтәгез, тыйган нәрсәләреннән ерак торыгыз, чытык йөз белән каршы алмагыз, эндәшмичә үпкәләп йөрмәгез, юк-бар нәрсә өчен мөгерәмәгез вә ыңгырашмагыз, каршы сүз кайтармагыз, хәтерен калдырырлык эш эшләмәгез, аның рөхсәтеннән башка өеннән чыкмагыз!

11. Хыялый, әдәпле, намуслы булыгыз, ирләрегезгә гүзәл мөгамәлә күрсәтегез, хөрмәтләренә вә хакларына кимчелек китермәгез, кушканнарын җиренә җиткерегез, серләрен фаш итмәгез, малын исраф итмәгез, аның рөхсәтеннән башка һичкемне яныгызга чыгармагыз, кием-фәлән өчен артык әйберләр теләмәгез!

12. Ирләрегезнең ата вә аналарына итагатьле булыгыз, башка якыннарын карендәш санап, шәфкатьле булыгыз, балалары булса — ирләрегез хәтере өчен якын күрегез!

13. Замана мәшәкатьләренә каршы торуда ирләрегезгә ярдәм итегез, шатлык вә хәсрәт көннәрендә аның белән берлектә булыгыз, бу дөньяның ачы вә төчеләрен аның

белән ур. таплашыгыз, аларга һич ялган сөйләмәгез, күрше хатыннарының: «Иремә ялган сөйләдем дә белмәде!» —дигәннәренә алданмагыз. Белегез ки: хатынның бер ялган сүзе иренә сизелсә — ире күзендә гомерлек хөрмәте бетәр.

14. Хатыннарны мәхәббәтле күрсәтәчәк нәрсә — чибәрлек түгел, холыктыр. Күп хатыннар булыр ки: чибәрлекләре камил булмаган хәлдә, һәркем каршында теләнгән булып күренерләр. Вә хөрмәт белән сөйләнерләр. Шуның өчен гүзәл холыклы вә миһербанлы булыгыз!

15. Ачулы йөзле булмагыз, ачу галәмәтләре белән һичкемгә күренмәгез, ачу вакытында сөйләшмәгез, хосусан башкаларга җавап бирүдән сакланыгыз, чөнки ачу вакытында җавап бирү сәбәпле ачу көчләнер. Бәлки ачуны бастырыр өчен тәһарәт алыгыз, мөмкин булганда намаз укыгыз!

16. Һәркемнән хөрмәт көтеп тормыйча, бәлки башкаларның кимчелекләрен күтәрегез, сүзегезне гүзәл тавыш белән сөйләгез вә мөлаем сөйләшергә гадәтләнегез. Сөйләшү олы бер камиллек булган хәлдә, сабыр мәртәбәсенә ирешмәгәнен белегез. Сүз йөртүче вә гайбәт сөйләүчеләрдән сакланыгыз. Кулыгыздан килгән кадәр яхшы эш эшләгез. Һич булмаса, бозыклык итмәгез!

17. Тирә-юнегездә булганнарның холыкларын өйрәнегез, кирәк — олуг вә кирәк — кече булсын, кайгы вә шатлык вакытларында белешләрегезне сабыр итәргә өндәгез һәм юатыгыз. Хәстәлеккә һәм хәсрәткә дучар булган вакытыгызда сабыр итегез, бәлки шулай булуы хәерледер дип күңелләрегезне бастырыгыз вә хәерле булуы өчен Аллаһы Тәгаләгә дога кылыгыз!

18. Ул тиешле чараларны саранлык та итмичә, исраф та итмичә, гадәттәгечә үтәгез, хезмәтчеләргә бик каты да вә бик йомшак та булмагыз, һәр эшегездә ихласлы вә тугрылыклы булыгыз, мондый кешеләрнең хезмәтчеләре итагатьле булырлар вә теләп хезмәт итәрләр.

19. Ашханәне тәмам үз күзегез белән идарә итегез, ашханәнең пакь вә әсбапларының низамлы вә һәрбер нәрсә үзенә яраклы җирендә куелган булуына бик дикъкать итегез, бакыр вә җиз савытларны һәрвакыт чистартып тотыгыз, мондый савытларда ашларны озак асрамагыз!

20. Һәркөнне иртә белән өйдә булган нәрсәләрнең тузаннарын селкегез, чүпләрне себерегез, лампа вә шәмдәл кебек нәрсәләрне чистартыгыз, китапларда булган тузаннарны сөртегез!

21. Югалмасыннар өчен чәй вә аш әсбапларының, шулай ук кием вә керләрнең барчасының хисапларын белеп торыгыз, болар күп булганда, һәрберсен үзенең сыйныфы белән дәфтәрләргә языгыз, һәрнәрсәне билгеле вә үзенә яраклы булган җирләргә урнаштырып, кирәк булганда, шуннан алыгыз вә хезмәте тәмам булуы белән шунда куегыз.

22. Кер әсбапларын күздән кичерегез вә һәрберенең баш хисабын зиһенегездә тотыгыз, һәртөрле нәрсәләрне сөртү өчен мөмкин булганда үзенә яраклы әйберләр булдырыгыз!

23. Керләр кипкәннән соң, гүзәл итеп төрегез вә кирәгенчә урнаштырыгыз, ертыклары булса — киңәйгәнен көтмичә, тизлек белән ямагыз, сүтелгәннәрен тегегез!

## 4. АНА ӘДӘПЛӘРЕ

24. Әгәр дә Аллаһы Тәгалә балалар бирсә — аларны дикъкать белән тәрбияләгез, яхшылык вә әдәп өйрәтеп, күркәм табигатьләргә гадәтләндерегез, холыкларын гүзәлләндерегез, өс-башларыннан артыграк гакылларын тәрбия итегез!

25. Бала күп булганда авыраймагыз, елаганнары вә тавышланганнары өчен тарланмагыз. Ал арның Аллаһы Тәгаләнең бәндәләре икәнлекләрен хәтерләп гайрәт вә шатлык белән тәрбияләгез. Ихтимал ки: уразалар тотып, хаҗларга йөреп булдырылмаган саваплар, бала тәрбиясендә хасил булыр. Ихтимал ки: бала мәшәкатьләрен йөкләү күләгәсендә ахирәт куркынычларыннан иминлек табылыр.

26. Мөмкин булганда, балаларыгызны җылы су белән һәр-көн ике мәртәбә юыгыз вә соңыннан яхшы сөртегез, артык эсселәндермәсен һәм баланың үсүенә зарар бирмәсен. Кан йөрүләрен туктатмасын өчен, кат-кат нәрсәләргә чолгамагыз, тар вә кысан киемнәр кидермәгез, әмма һич бәйләмәгез!

27. Балалар яхшы һавага бик мохтаҗ булганнары өчен, йокы урыннарын мөмкин кадәр бозык һавалы итмәгез, өсләрен капламагыз, кирәге булмаганда өсләренә, хосусан калын нәрсәләрдән чебенлек (халык арасында ялгыш «чыбылдык” дип танылган) кормагыз, бишеккә салып та тибрәтмәгез, бу исә — бала өчен зарур нәрсә түгелдер.

28.Күзләр чалышаймасын өчен тәрәзә вә ут яктыларына каратып яткырганда, кырын түгел, бәлки туры яткырыгыз, үтәдән-үтә җил йөрүдә булган җиргә куймагыз!

29. Алты ай булганга кадәр сөттән башка ризык бирмәгез моннан соң аз-азлап шулпа бирү дә дөрес булыр, тешләре чыкмастан элек ит ашатмагыз, көчегез җитсә итне бөтенләй ашатмаска гадәтләндерегез, һичвакыт һичнәрсәне чәйнәп ашатмагыз!

30. Сөт имезгән вакытыгызда, сөтегез бозылмасын өчен суган, сарымсак кебек исле нәрсәләрне ашамагыз, борыч, горчица, керән кебек нәрсәләрне артык кулланмагыз, кофе, чәйне сакланып эчегез, әмма зинһар исерткеч эчмәгез, исерт-кеч исә баланың холкы вә сәламәтлеге бозылуына беренче сәбәп булыр.

31. Балаларыгызны гадәттән тыш иркәләмәгез, һәрнәрсәне алар ихтыярына салып тормагыз, аларны каршы сөйләргә вә сүгәргә өйрәтмәгез. Ягъни алар хозурында үзегез карышмагыз вә яман сүзләрне яратмый торган булып күренегез аларга, сез шулай булсагыз, карышырга һәм кеше сүгәргә алар да өйрәнмәсләр.

32. Баһадир булсыннар өчен, балаларыгызны курыкмаска гадәтләндерегез, җен, пәри вә башка моның кебек нәрсәләр сөйләп гомерләре барынча куркак булачак мәртәбәдә каннарын бозарга сәбәп булмагыз. Күп кешеләр булыр ки: бер бүлмәдә ялгыз йокларга вә яки авыл җирендә чокыр өстендә булган мунчада ялгызы кереп юынып чыгарга куркырлар. Моның сәбәбе исә яшь вакытларында аналары тарафыннан каннары бозылган булыр. Шуның өчен сез балагызны мондый нәрсәләргә гадәтләндерегез!

## 5. АТА ӘДӘПЛӘРЕ

33. Балаларыгызны тәрбияләргә иң кечкенә чакларыннан башлагыз, ал арның күңелләренә күркәм холык орлыклары чәчегез, адәмчелекне вә изгелек ничек булганын белдерегез, урынына карап бераз йомшаклык вә вакытына карап бераз катылык та күрсәтегез, ләкин куркып түгел, бәлки киңәш чишмәсе икәнен аңлап, сүзләрегез белән гамәл кылачак кадәр, үзегезне олы итеп тота белегез.

34. Балаларыгызның үзләрен вә алар күз алдында башкаларны да сүкмәгез, әгәр дә бер кешегә яман сүз әйткәннәрен ишетер булсагыз, әлбәттә тыегыз, сүгәргә өйрәнмәсеннәр!

35. Балагыз күз алдында үз-үзегезне хөрмәтле тотыгыз, алар сездән үзләрен тотарга өйрәнсеннәр вә бу күләгәдә гаилә эчендә бердәмлек вә мәхәббәт нык булыр. Аларга һич ялган сөйләмәгез вә аларга яман дога кылмагыз, бу нәрсәләр исә аларга ялган сөйләргә өйрәтер вә атаның хөрмәтен киметер.

36. Хатыннарыгыз тәрбияләргә керешкәндә балаларның араларына кермәгез, сез тәрбияләгәндә хатыннарыгыз да арага кермәсен. Бу нәрсә — тәрбия түгел, тәрбиясезлектер, Чөнки бу хәлне күреп, бала үзен кыерсытылган игеп санар вә иркәлеккә өйрәнеп, һичбер тәрбия алмыйча, ата белән ана арасында бер-берсеннән качып вә шикаять итеп йөрер.

37. Бу дөньяда адәмнәрнең кыйммәтләре — фәкать үз тырышлыклары белән булганлыгын, һәркем үз эшен үзе күрергә бурычлы икәнлеген балагызга аңлатыгыз, кешегә таянырга вә фәкать бәхет, вә хәер догаларга ышанып торырга өйрәнмәсеннәр.

38. Иман вә дин хөкемнәрен, фарыз вә хәрамнарны белдерегез вә гамәлләрен кылырга гадәтләндерегез (дин тәрбиясен яшьлегеннән алган бала олыгайгач та шәт югалмас).

39. Балаларыгызга файдалы максатларны хасил итү турысында ярдәм итегез вә мөмкин булганда бу юлда акча кызганмагыз, аларны кеше ишекләренә йөрергә вә яки хәерсез эшләр эшләргә мәҗбүр итмәгез!

40. Балаларыгыз өчен мал җыеп та, тәрбияләрен ташламагыз, бәлки малны аларның тәрбияләре юлына сарыф итегез. Бетми торган мирас гүзәл тәрбия икәнен белегез. Дөрес тәрбия булмавы соңында балалар өчен дөнья тулы алтын калса да — файдасы юктыр, бәлки тәрбиясезлекләре — бер бәхетсезлектер вә аның өстенә калган алтыннары икенче бәхетсезлек булыр.

41. Балаларыгызны мәдрәсәгә җибәреп тә, алар хәленнән хәбәрсез тормагыз, бәлки һаман хәлләрен күзәтегез, һәрбер хәлләрен күз уңында тотыгыз, хәтта китап вә язу әсбапларына кадәр нәрсәләренә барганча аңлап вә белеп торыгыз!

42. Гаделлек вә инсаф өйрәтү өчен, хаҗәтләрен үтәгәндә вә кирәкләрен булдырганда барысын бертигез күрегез, бүләк биргәндә барчасына тигез бирегез, берсенә яшереп бернәрсә биреп тә «Сак бул, туганнарыңа белдермә!» дигән кебек нәрсәләрдән

сакланыгыз, чөнки болай итү аларга җәбер, золым, алдау, хыянәт кебек нәрсәләрне өйрәтер. Саранлык вә үз-үзеңне сөю кебек бозыклык орлыкларын күңелләренә чәчәр.

43. Көчләре җитешерлек булганда, балаларыгызга үз эшләрегезне вә һөнәрләрегезне өйрәтегез, фикерләрегез белән әшнә итегез, дөнья күтү өчен аларның күзләрен ачыгыз, тормыш кагыйдәләрен аңлатыгыз, хезмәтчеләрегез белән түгел, үзегез белән бергә йөртегез, ашау-эчү вакытларында күз уңыгызда булдырыгыз, зиһеннәрен ачарлык нәрсәләр сөйләгез, ничек булса да гакылларын нурландырыгыз, кәсеп вә һөнәрләр белән әшнә-дус итегез, вакыты җиткәндә изге гаилә әгъзалары белән таныштырыгыз.

44. Балаларыгызны кеше дип санап, аларның адәм булуларын теләсәгез, аналары белән гүзәл вә шәригать әдәбе белән мөгамәлә итегез. Бала мәхәббәте ата белән ана арасында уртак икәнен балаларыгызга гамәлләрегез белән белдерегез. Әгәр дә алар сездән мондый нәрсәләрне күреп үсәр булсалар, үзләре дә сездән алган гыйлем вә тәрбияләре кулəгәсендә, үз хатыннары белән гүзәл тормыш итәрләр, үз балаларын тәрбия-ләүдә дә кимчелек күрсәтмәсләр.

45. Вакыты җитү белән әдәп өйрәтегез, Коръән Шәриф өйрәтегез, кодрәтегез җиткән кадәр чыгымнарына акча бирегез, тәрбияләгез, дөнья тереклеге өчен тиешле булган кәсеп вә һөнәрләрне мәхәббәтле күрсәтегез, күңелләренә гайрәт бирегез, олуг кешеләрнең тәрҗемәи хәлләрен сөйләгез!

46. Кызларыгызны камил игътибар белән укытыгыз, укырга вә язарга өйрәтегез, булса — мәктәпләргә җибәрегез, дин вә дөнья кирәкләрен, өй тәрбияләү гыйлемнәрен өйрәтегез, вакыты җиткәндә фәкать байлыгына күз салып, тәрбиясезләргә вә үзләренә тиң булмаган картларга түгел, бәлки тәрбияле вә гүзәл табигатьле адәмнәргә бирергә тырышыгыз, туй вә җиһаз өчен артык тартынмагыз, тәрбияле булу кадәр бөек җиһаз вә шөһрәтле туй һич булмас.

## 6. ТЫРЫШЛЫК ӘДӘПЛӘРЕ

47. Тәрбияләнмәгән вә эшләнелмәгән җирләрдә, гадәти булганнардан башка нәрсә җитешмәгән кебек, үз хәлендә бер эшсез торачак адәм балалары да бер файда да китермәсләр. Шуның өчен дөньягыз өчен мәңге торачак кеше кебек вә ахирәтегез өчен иртәгә булачак кеше кебек тырышыгыз!

48. Аллаһы Тәгалә гамәл итәргә боерган вә гамәлгә күрә җәза бирергә вәгъдә иткән вә бәндәнең вазифасы да үзенә бирелгән эшләрне җиренә җиткерү өчен тырышудыр, шуңа нигезләнеп, өстегезгә тиешле булган гамәлләрне ихлас вә иҗтиһатыгыз-тырышлыгыгыз белән үтәгез, тәкъдир вә яки кабул ителеп-ителмәячәген вә Аллаһы Тәгаләнең бәндәләренең гыйбадәтләренә һич мохтаҗ түгел икәнлеген, сөйләү вә ялкаулыкка боларны сылтау итү кебек нәрсәләр белән мәшгуль булмагыз, чөнки бу нәрсәләр — бәндәнең вазифасы түгелдер.

49. Һичнәрсәсе булмаган кеше — фәкыйрь түгел, бәлки һөнәре вә тырышлыгы булмаган кеше — фәкыйрьдер. Үзе хакында тырышкан кешегә эш һәрвакытта ярдәм итәр. Тырыш кеше гүзәл тереклек иткән хәлдә, ялкау кеше ачлыктан үләр. Бу дөнья тереклеге

һәркемнең үз гайрәтенә тапшырылган. Шуның өчен дөньяда торыр вә көн кичерер өчен һичкемгә ышанып тормыйча, фәкать үз гайрәтегездән өмет итегез вә үзегез өчен үзегез тырышыгыз.

50. Ризык һәрникадәр бүленгән вә билгеләнгән булса да, моны эзләү вә теләү бәндәләргә боерылган. Шуның өчен үз ризыгыгызны эзләгез. Күрмисезме, һичкемгә күктән алтын яуганы вә җирдән үлән кебек көмеш үсеп торганы юктыр.

51. Зирәк булган вакытыгызда — зирәклеккә ышанып яки һөнәрле булган вакытыгызда — һөнәргә арка биреп, эшсез вә хәрәкәтсез, тик ятмагыз. Чөнки тырышлык күренмәгән вә хәрәкәт ителмәгән хәлдә, зирәклек белән һөнәрдән бер файда хасил булмас.

52. Ялкаулык вә нәфес теләге артыннан йөрү (шәригать тәртибеннән тыш) адәм баласына хәстәлек китерер, табигатен бозар, фәкыйрьләндерер, шуның өчен һичвакыт эшсез тормагыз, ялкау булмагыз, шөһрәт әсире булмагыз, гакылыгызны буш вә эшсез асрамагыз!

53. Дөньяда булган көннәрегездә ахирәттә файдалы булачак гамәлләрдән дә гафил булмагыз, гүзәл белегез ки; дөньяда тузан кадәр изгелек иткән кеше ахирәттә яхшы җәза күрер вә тузан кадәр усал гамәл иткән кеше дә ахирәттә усал җәза күрер. Нәркемнең гамәле ахирәттә тышка чыгар вә һәр гамәлнең җәзасы каршы килеп алыр.

54. Дөнья сәфәрендә булган вакытыгызда, үзегезгә кирәкле эшләрне туктатып тормагыз, чөнки дөнья исеп куйган җил кебек тизлектә үтәр, бәлки вафат көнегезгә кадәр файда эшләр өчен тырышыгыз вә һичвакыт ялыгып калмагыз, артыгызда гүзәл бер исем калдырыр өчен тырышыгыз. Чөнки адәм баласы вафат булыр, ләкин гүзәл исеме вафат булмас, мәңге калыр.

## 7. ҺӨНӘР ВӘ СӘНАГАТЬ ӘДӘПЛӘРЕ

55. Эшегезне ашыкмыйча, гүзәл вә нык итеп, вә һәрнәрсәнең үзенә туры килгән вакытында эшләгез, фикерегезне бозачак нәрсәләрдән сакланыгыз, алдан күрүчән булыгыз! Бер эшкә керешкәч, гүзәл рәвештә тәмамларга тырышыгыз, чөнки эшне башлап, юлда калдырудан — һич башламыйча тору тагын хәерлерәктер.

56. Бер сәгатьтә берничә төрле эшне эшләргә керешмәгез, чөнки болай итү бөтенесеннән мәхрүм калырга сәбәп булыр, бәлки керешкән эшегездә гайрәтле булыгыз һәм ихлас булыгыз вә һич ялыкмыйча дәвам итегез!

57. Бүген бетәчәк эшне иртәгә калдырмагыз, чөнки ир. тәнең тагын үзенә кирәк эшләре булачак. Бүген эшне иртәгә калдырыгыз да, бу көн бушка үтәр вә иртәгесе көнгә ике төрле эш җыелыр да, авырлык китерер. Әмма һәркөннең эше бетеп барса — үзегезгә рәхәт булыр.

58. Эшегезнең аз заманда тәмамлануына түгел, бәлки гүзәл, яхшы, нык вә тәртипле булуына дикъкать итегез. Тәртипле булган эшләр вакыт уздырмас вә үкендермәс. Халыклар да эшләрнең никадәр заманда тәмам булуына түгел, бәлки яхшы булуына дикъкать итәрләр.

59. Эшләрне башлаган вакытыгызда игътибар белән башлагыз, чөнки башында яхшы булган эшләрнең ахырлары да яхшы булыр, башы бозык булган эшләрнең ахыры да гүзәл булмас.

60. Эшләрне кеше күрсен вә мактасын өчен түгел, бәлки файдасы булсын өчен эшләгез. Файдалы эш бүген булмаса — бер вакыт күзгә күренер, гакыллы кешеләр тарафыннан яхшы күрелер.

61. Вакытларыгызны мөмкин кадәр гамәлләрегезгә бүлегез вә көчегездән артык эшләргә көчәнмәгез, аның өчен болай итү авыру китерер. Эшләрегездән ялыкмагыз, бәлки шатлык белән йөрегез, күңел кайтарачак фикерләрне күңелегездән чыгармагыз, бәлки эшләрегезне эшләгез вә файда өмет итегез!

62. Эшләгән вакытыгызда, соңыннан, киләчәк файдалар хакында фикер йөртегез, чөнки болай итү шатлык килүгә сәбәп булыр. Шатлык белән булган эш никадәр авыр булса да, җиңел күрелер.

63. Һөнәрегезне көннән-көн тәрәккый иттерегез, булган хәлгә риза булып тору, яки көннән-көн түбән калудан сакланмау — хиссез вә һиммәтсез затлар гадәтедер.

## 8. КӘСЕП ӘДӘПЛӘРЕ

64. Дәресләрегезне тәмамлавыгыз белән, дөнья кичерү өчен үзегезгә яраклы берәр кәсеп вә һөнәр сайлагыз вә бер төрле һөнәр вә кәсеп белән әшнә булудан элек, башкалары белән шөгыльләнмәгез!

65. Кәсебегез азлыгыннан вө яки күп файда күрә алмага-ныгызга оялмагыз, тырышканнан соң файда азлыгы гарьлек түгел, бәлки ялкаулык вә кәсеп белмәгәнлек — гарьлектер.

66. Сайланган һөнәрегездә дөрес сүзле, ышанычлы, шат вә гакыллы, алдан күрүчән, пакь булыгыз, көннән-көн эшегезне яхшыландыруга вә халыкларның игътибарларын җәлеп итәргә тырышыгыз, хыянәт итмәгез, ялган сөйләмәгез, җитештерә алмый торган көн белән вәгъдә итмәгез, иткән вәгъдәгезгә хилаф итмәгез!

67. Әгәр дә игенчелек белән шөгыльләнер булсагыз, иген гыйлемен белегез вә бу турыда язылган рисаләләрне — язмаларны вә китапларны укыгыз, кирәкле тәҗрибәләрне ясагыз, файдалы орлыкларны табып чәчегез, җир алу вә сату һәм хезмәтчеләр яллау хакында булган тәртипләрне белегез!

68. Сәүдәгәр булсагыз, сәүдә хакында булган тәртипләр белән әшнә булыгыз, эшләрегезне тәртип белән йөртегез, зарар белән файда юлларын аерыгыз, үзегезгә зарар вә башкаларга хыянәт итмәгез. «Хакы арзан» дип, кирәге булмаган нәрсәләрне күп алып куймагыз, гаепле нәрсәләр сатмагыз, аз булса да — табышны җибәрмәгез, ачык йөзле булыгыз, үлчәүләрдә гаделлек итегез, озын сүзнең кыскасы, шәригать кушуынча гамәл итегез, файдасы аз булса да — бәрәкәте күп булыр.

69. Бер кешенең хезмәтендә булсагыз, хезмәтләрегезне тугрылык белән башкарыгыз, дөрес сүзле, ихлас гамәлле- вә җитәкчеләрегезгә итагатьле булыгыз, хыянәт итмәгез, вөҗдан вә хөрмәтле йөкләмәләргә каршы эштә булмагыз!

70. Башкаларның хезмәтләрендә булганыгыз вакытта, кием-салымда алар белән бертигез йөрмәгез, хатыннарыгызны артык киендермәгез, дөньяда ярышырлык кеше бетәчәк бул-маганлыктан, зиннәт вә кием турысында үзегез дә ярышмагыз, хатыннарыгызны да ярыштырмагыз, әгәр дә мосафирыгыздан артачак акчагыз булса — күпме-азмы булыр, кара көннәр өчен саклау сандыгына (сберегательная кассага) салыгыз, никадәр бәхетле булсагыз да — киләчәктә булган кара көн өчен хәзерләнмичә, гафил, ягъни белмичә тормагыз!

## 9. ИКЪТИСАД (ТОТА БЕЛҮ)

71. Акчасы вә дәүләте күп кеше — бай түгел, бәлки икътисады булган кеше — байдыр. Шуның өчен файдасыз җирләргә вә хәрам урыннарга бер тиен булсын — акча сарыф итмәгез, мондый урыннарга сарыф ителәчәк акчаларны яны-гызда саклагыз, җыегыз, киләчәктә бәлки зарары булмас.

72. Өй идарәсендә булган аз гына бурыч та киемнәрдә булган ертык кебектер, һаман күренер-күренмәс тормас, ямал-маса зураер, үз-үзенә зураер. Шуның өчен көтәргә әйбер алмагыз, әгәр дә кирәк булу сәбәпле алынса — акчасын ашы-гып тапшырырга тырышыгыз, өстегезгә бурыч өймәгез, адәм баласын вакытсыз картайтачак нәрсәләрнең берсе дә — бурычтыр.

73. Акчаларның кыйммәтләрен, әйберләрнең хакларын яхшы белегез, сату-алу вакытында алданмагыз, кирәк булган нәрсәләрегезне мөмкин булганда үзегез карап алыгыз, кирәк булмаганнарын арзанлыгына кызыгып яки фәкать җиһаз вә зиннәт өчен сатып алмагыз, мондый нәрсәләрне алу — никадәр арзан хак белән булсын — кыйммәттер.

74. Килер вә китәрегез хисапларын бер дәфтәргә языгыз вә һәрвакыт бу дәфтәрне күзегездән кичереп торыгыз, мондый дәфтәрләр икътисад аршины вә алдан күрүчәнлек үлчәве булырлар. Чөнки кесәсеннән чыккан акчаларны күреп торганда, кирәкмәс урыннарга акча бирү өчен һәркем беркадәр саклык күрсәтер.

75. Китәрегезне килерегездән артык итмәгез, бәлки кара көн өчен һәр айда күпме-азмы бер микъдар кесәгезгә беректерә барыгыз, болай итү күңелгә рәхәтлек китерер вә тырыш булырга сәбәп булыр. Әмма китәрегез артык булса — күңелгә хәсрәт булыр, канны бозар.

76. Бик кирәк булмаганда, бурыч буларак әйбер алмагыз, шулай ук мөгамәлә җәһәтенчә мәҗбүр булмаганда вә яки хәлләрен тәҗрибә итмәгән кешеләргә бурыч та бирмәгез. Әмма халык арасында киенеп, күкрәгән киереп йөрүчеләргә вә корсакларын кунак итүчеләргә, хатыннарын дәрәҗәләреннән тыш киендерүчеләргә бер тиен булсын бирмәгез!

77. Вәгъдәсе җиткәндә алачагыгызны — уйнап вә көлеп түгел, бәлки чын сурәттә вә акча кирәк икәнен белдерерлек рәвештә сорагыз, бирәчәгегез — вәгъдә ирешеп тә бирергә көчегез булмаганда, гүзәл сурәттә гафу үтенегез!

## 10. ТӘДБИР, ЯГЪНИ АЛДАН КҮРҮЧӘНЛЕК

78. Вакытын сарыф итә белгән кеше малын да сарыф итә белер, ягъни бер минут вакытын буш җиргә сарыф итмәгән кебек, бер тиен булсын — акчасын да урынсыз җиргә җибәрмәс. Шуның өчен вакытыгъзиы до малыгызны әрәм итмәгез, алдан күрүчән булыгыз, ахмак кешеләр кебек акчагызны, дөнья вә ахирәттә файдасы өметле булмаган әйберләргә сарыф итмәгез, вакытыгызны да исраф итмәгез.

79. Мал никадәр күп булса-булсын, гомер никадәр озын булса-булсын, алдан күрү булмаганда, яз көненең, кары кебек эрер, бетәр, исеме вә эзе калмас. Әмма алдан күрү булса — аз гына маллар да бәрәкәтле булыр, кыска гомерләр дә файдалы булыр. Моның өчен алдан күрү белән дөнья көтегез, алдан күреп яшәгез, алдан күреп эш итегез!

80. Исраф иң хөрмәтле гаиләләрне бозар вә иң бай өйләрне туздырыр, иң биек урыннардан түбән төшерер, иң шөһрәтле фамилияләрне харап вә фәкыйрь итәр. Шуның өчен исраф итүдән бик сакланыгыз вә һәр эшегездә икътисадлы булыгыз!

81. Алдан күрү белән кулланылса — мал азаймас, артыр, саран кеше ач калыр, исраф итүче хәстәләнер вә фәкыйрь үләр, шуның өчен акча сарыф итүдә әшәкелек дәрәҗәсенә бармагыз, исраф та итмәгез, бәлки икътисадлы вә алдан күрүчән булыгыз!

82. Фәкыйрь булганыгыз хәлдә бай күренмәгез вә бай булганыгыз хәлдә фәкыйрь сурәттә йөрмәгез, бәлки булганынча күренегез вә күренгәнегез кебек булыгыз, хатыннарыгыз ирләре өчен дә мал (ир кеше үзе үлгәннән соң, аннан калган мал белән хатынының башка иргә тормышка чыгуы күздә тотыла.— Ә. Х.) җыймагыз, бу исә — алдан күрүдер.

## 11. БАЙЛЫК ВӘ ЯРЛЫЛЫК ӘДӘПЛӘРЕ

83. Мал — дөнья тереклегендә зиннәт булган кебек, ахи-рәт-мәртәбәләрен кәсеп итәргә дә чарадыр. Шуның өчен малыгызны үзегезгә дөньяда изгелек китерәчәк вә үлгәндә гүзәл исем белән искә алдырачак урыннарга сарыф итегез.

84. Мал — әгәр дә Аллаһы Тәгалә хәзрәте боерган рәвешчә сарыф ителмәсә, бәндәне адаштыруга сәбәп булыр, шуның, өчен малның үзен сөймәгез вә Аллаһы Тәгалә хәзрәте риза булмаган урыннарга сарыф итмәгез, сак булыгыз!

85. Бәндәнең Аллаһы Тәгалә хәзрәтенә тоташтырачак ди не, әдәбе вә гүзәл холкы булмаса — дөнья тулы малы булса да бер файдасы булмас. Шуның өчен, малыгыз никадәр күп булса-булсын, дин тәрбиясе алыгыз, гыйлемле, әдәпле, гүзәл холыклы булыгыз!

86. Малыгыз белән файдалы китаплар алыгыз, укытучы ларга вазифа бирегез, үзегезнең вә гаиләгезнең кирж ирн к ларын белеп башкарыгыз, тиеш җирләргә Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен гаделлек белән сәдака һәм бүләк бирегез, дин вә милләт файдаларына да сарыф итегез,

87. Аз булса да, Аллаһы Тәгалә риза булмаган урыннарга, ахмак адәмнәр файдаларына, бозыклык урыннарына, бозык холыклы кешеләрнең мактауларын ишетер өчен бер тиен да бирмәгез. Мондый нәрсәләр адәм баласының хөрмәтен ж.и бәрер, игътибарын югалтыр, динен бозар.

88. Дөньягыз тар булса, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән өмет өзмәгез, иркен булганда азгынлык вә женси дәрт колы булмагыз, байлык — бер айлык икәнлеген вә күп бай фамилияләр азгынлыклары сәбәпле иң фәкыйрь булып калуларын фикерләп, күңелләрегезне, үз-үзегезне тәрбия итеп торыгыз!

89. Фәкыйрьлек — гаеп вә гарьлек булмыйча, бәлки кәсеп итәргә көч житешмәү вә кәсеп тәртипләрен белмәү вә башкалардан сорашып йөрергә мәжбүр булу — гаептер. Шунын өчен, бер тарафтан фәкыйрьлек баш күтәрсә, сез дә икенче тарафтан кәсеп итәргә керешү белән бу фәкыйрьлек белән сугышыгыз, ихтимал ки, гайрәтегез вә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте күләгәсендә фәкыйрьлекне жиңәрсез, һәртөрле адәмнәрдән сорашып йөрмәс өчен, куәт табарга тырышыгыз, бу турыда зинһар жиңелгә санамагыз!

90. Бай булу өчен артык ашыкмагыз, акчаның үзен сөймәгез, икътисад белән тотылса, аз байлык та ярар, ләкин кешеләргә йөз суы түкмәс өчен, көч хасил итәр өчен арысланнан качар кеше кебек ашыгыгыз!

91. Тырышып-тырытттытт та житәчәк дәрәждә байлык хасил булмаса өметсез бер хәлдә булмагыз, бәлки холык вә фигыльләрегезне төзәтергә тырышыгыз, холык төзек булу да — олы бер байлыктыр. Байлык белән табылмаган хөрмәт вә гүзәл исемнәр күркәм холык күләгәсендә хасил булыр вә соңларга кала белер.

92. Акчаның үзен сөю — иң каты фәкыйрьлектер. Адәм баласы акчасыз фәкыйрьлеккә сабыр иткән хәлдә, акча сөю фәкыйрьлегенә сабыр итә алмас. Әгәр дә адәм баласы, Алла сакласын, акча сөю фәкыйрьлегенә дучар булса, бөтен тереклеге хәсрәтле булыр, адәмчелеге вафат булыр, кара икмәккә туймыйча, башын ташка куеп яткан фәкыйрьләр күрмәгән мәшәкатьләрне акча сөюдә булган бай фәкыйрьләр күрерләр. Сез бу хәлне һәрвакыт алдыгызда тотыгыз, акчасызлык фәкыйрьлегеннән артык акча сөю фәкыйрьлегеннән куркыгыз, сакланыгыз!

93. Гадәти рәвештә генә дөнья кичереп риза вә Аллаһы Тәгаләнең өлешләвенә буйсынып, үзеннән түбәннәрнең хәлен күреп шөкер итүдә булган зат биек сарайларда утырып вә һәр төрле зиннәтләргә туеп та, үзеннән югарыларны күреп вә алар кебек булмавы өчен кайгыруда булган кешедән кат-кат бәхетледер. Шуның өчен сез дә бәхетне байлыктан, яки ат, арба вә олы сарайлардан эзләмичә, бәлки күңелегезнең канәгатьле вә жаныгызның тыныч булуыннан эзләгез!

94. Дөньяда булган барлык максатыгызны мал жыюдан гыйбарәт итмәгез, күзегезне яхшы ачып як-якка карасагыз күрерсез ки; мал жыючылар — бал корты кебек көне-төне хәсрәт тартып жыйганнары хәлдә, ашаучылар башкалар булыр. Вә кайбер адәмнәр, жан тирләрен агызып, хатыннарының ирләре өчен мал жыялар. Вә моннан башка, мал жыю — адәм баласында бер хәстәлектер ки, я исраф, я саранлык кебек бозык холыкларга тоташтырыр. Шуның өчен башкаларга мохтаж булмас, гаиләгезне гүзәл тәрбия итәр, яхшы жирләргә гыйлем вә милләт һәм гомуми файдаларга сарыф итү нияте белән кәсеп итегез вә тапкан малыгызны да хатыннарыгыз-ның ирләрен симертер өчен түгел, бәлки дөнья вә ахирәттә файда күреләчәк, үзегезгә вә фамилиягезгә гүзәл бер исем алачак жирләргә үзегез сарыф итегез!

95. Акчагызны выигрышний билетларга бирмәгез, сак булыгыз вә отыш уйнамагыз, бәлки аз булса да — болардан башка кәсеп итегез, бар кадәренә канәгать итегез, белегез ки; һәр комсыз кеше — фәкыйрь вә һәр канәгатьле кеше — байдыр.

96. Данны байлык вә акчада яки ат-арба, җир-суда санамагыз, бәлки дан — гүзәл холык, тәрбия, әдәп вә гыйлемдер. Әгәр дә игътибар күзен салсагыз күрерсез ки: бу дөньяда күп байлар булыр, холыклары бозык вә тәрбиясез булуларыннан рәхәтнең ни икәнен дә белмәсләр вә күп фәкыйрьләр булыр ки: гыйлем вә тәрбияләре күләгәсендә дөнья сәфәрен бик рәхәт кичерерләр.

## 12. ГЫЙЛЕМ ӘДӘПЛӘРЕ

97. Һәрбер кеше вә һәрбер кавем вә милләтнең бәхетле булуларына баш сәбәп — гыйлемдер. Ашлыклар өчен яңгыр никадәр кирәкле булса, адәм баласы өчен дә гыйлем шул рәвештә кирәкледер. Этләр барысы ят булганнары хәлдә, гыйлемле этләргә ислам шәригатебез өстен хаклар бирәдер. Шуның өчен сез дә гыйлем өйрәнегез вә балаларыгызны гыйлем юлына салыгыз, гыйлемгә ярдәм итегез вә таратыгыз!

98. Бу — бер замандыр ки; гыйлемле кавемнәр сәгатьләп вә минутлап үскәннәре хәлдә, гыйлемсез кавемнәр юкка чыгып бетәләрдер. Гыйлемле утын кисүчеләр янында гыйлемсезләре җиңелә, күз уңында булган башкаларга ни кала?.. Шуның өчен Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт итәр өчен гыйлем кәсеп итегез. Вә һөнәр вә сәнагать яки игенчелек вә сәүдә белән көн кичерер булсагыз гына гыйлем өйрәнегез!

99. Укытучы булсагыз, шәкертләрне кагыйдә буенча тәрбия итегез. Холыкларын гүзәлләндерегез, хәлләренә яраклы гыйлемнәрне өйрәтегез, гомерләрен әрәм итмәгез, шәкертләр өчен җаваплы булачак кешеләрнең иң беренче дәрәҗәдә булганнары — мөгаллимнәр белән мөдәррисләр (укытучылар белән өлкән укытучылар) икәнлекне онытмагыз!

100. Шәкертләрегезнең һәрбер хәрәкәтләренә карап торыгыз, аларны яхшы мөгамәләләргә, гүзәл вә шәфкатьле гадәтләргә төшендерегез, сүзләрен вә фигыльләрен тугрыландырыгыз. Өс-башларын, кием-салымнарын пакь вә чиста йөртүләрен күзәтегез. Озын сүзнең кыскасы, эч вә тыш игътибары белән һәркемгә үрнәк булырлык дәрәҗәсенә ирештергән вакытыгызга кадәр шәкертләрегезне тәрбияләгез!

101. Шәкертләрегез белән уйнамагыз, көлмәгез, аларга йомшак вә миһербанлы булыгыз, һәрнәрсәне дөрес сөйләгез, барысын да бертигез күреп, барысы да файда алачак рәвештә өйрәтегез, файдалы гыйлемнәр, кирәкле булган әдәпләрнең барчасыннан хәбәрдар итегез!

102. Ишеткән нәрсәләрегезнең гүзәлләрен языгыз, язган нәрсәләрегезнең гүзәлен күңелләрегезгә салыгыз, күңелегездә булганнарның гүзәлен сөйләгез, язачак нәрсәләрегезне — иң элек бер дошман күзе белән тәнкыйтьләгез, хак сүзне сөйләүдә Аллаһы Тәгаләдән башка һичкемнең шелтәсеннән курыкмагыз!

103. Язган вакытыгызда каләмегезгә ия булыгыз, халыкларның мәртәбәләрен вә гомумгадәтләрен хөрмәт итегез, язган нәрсәләрегез — дөньяда гакыл әһелләре хозурында вә ахирәттә каршыгызга килгәндә йөз кызартачак рәвештә булмасын!

104. Оҗмах эченә кереп ни телегез вә ни каләмегөз белән һичкемне ачуланмагыз, сүкмәгез, ислам мәзһәбләренең һичберенә “бәд мәзһәб” (“бозык мәзһәб”), “фиркаи заллә” (“начар мәзһәб”) дигән кебек әдәпсез сүзләрне сыламагыз, меңнәр вә миллионнар җаннарын газапламагыз вә аларга дошманнары тарафыннан бергә унны вә йөзне кушып арттырып сөйләгән сүзләргә ышанмагыз, башкалардан бигрәк үзегезнең инануларыгызны тикшерегез вә үз инануыгызны дөресләгез, кешеләрне тикшереп, үзегезне мәхрүм итмәгез! Ахирәттә котылырга теләсәгез - шигый мәзһәбен, ваһһабиларны сүгеп гомер уздырачак җирдә үз хәлегезне кайгыртып вә Рәсүлулла (Аңа Аллаһы 'Тәгаләнең хәер догасы һәм сәламе булсын!) һәм аның изге сәхабәләре юлына иярегез вә аларның юлыннан аерылмагыз вә моның белән бертигез киләчәк көннәрдән һаман тыныч вә хәбәрсез тормагыз!

105. Ялган вакытыгызда көчегез җитү, өскә чыгуга вә үзегезне булган дәрәҗәгездән биек бер дәрәҗәдә күрсәтергә көчәнмәгез, болай итү язылган әсәрләрнең әһәмиятен вә язучының да дәрәҗәсен түбән төшерер.

## 13.. ВАТАН ВӘ МИЛЛӘТ

106. Күге астында яшәгән, һаваларын иснәп, суларын эчкән вә икмәкләрен ашаган ватаныгызны сөегез, моның исемен бөек итәр өчен тырышыгыз!

107. Ватан адәмнәрнең хөрмәте вә һәркем алдында изге итәчәк бер мактаныч булыр. Шуның өчен Ватан тугрысында малыгызны кызганмагыз, көчләрегезне аямагыз. Ватан хакында болай фидакяр булмаган кеше анда яшәргә лаек түгелдер.

108. Ата вә анагызны, якын кардәшләрегезне ничек сөйсәгез - милләтегезне шулай сөегез, милләтегез өчен хезмәт итүне җаныгызга зур табыш дип санагыз. «Милләт» вә «тәрәккыят», ягъни «алга китү» сүзләрен мәсхәрә итүчеләрнең сүзләрен ишетмәгез, алар исә — хисләрдән мәхрүм калган мескеннәр вә бичаралардыр. Бәлки аларның үзләрен кызганыгыз вә мондый дәрәҗәдә ким калулары өчен хәлләренә мәрхәмәт итегез!

109. Милләт вә Ватан өчен хезмәт итү насыйп булса — аның бәрабәренә рәхмәт вә бүләк көтмәгез. Бүләк көтү шулай торсын; фараз итик, ягъни күз алдына китерик: милләт сезгә җәфа итсен, сез һич үпкәләмәгез, өстегезгә бурыч булган хезмәтләрдән һаман кире тормагыз. «Шәһәрләр вә кавемнәр һәрникадәр миңа җәфа итсәләр дә, минем күземдә генә хөрмәтлеләрдер” дигән гарәп шигырен укыгыз вә моның белән хәтерегезне юатыгыз!

110. Дин, гыйлем тарату, мәктәпләр вә яхшы эшләр өчен, вә һәрни рәвешчә булса да халыкка ярдәм бирү өчен тырышлык сарыф итү —иң гүзәл гайрәттер, моның җәзасы да - гүзәл җәза булачактыр. Шуның өчен изге вә диндарлык эшләренә, милләт вә дин файдаларына ярдәм бирүен зур табыш санагыз, күңелегез белән сөя-сөя ярдәм бирегез, милләтегезгә гыйлем вә мәгърифәт таратыгыз, араларына дуслык вә мәхәббәт орлыклары чәчегез, дошманлык вә гөнаһ эшләргә ярдәм итешүдән сакланыгыз. Хосусан милләт зарарына бер хәреф тә сөйләмәгез вә бер нокта да язмагыз!

111. Милләт файдасына хезмәт итүчеләрне үзләре белән бер җиргә килеп сөйләшмәстән элек, белер-белмәс фәкать күкрәгегез тарлык бәласе сәбәпле, төрле-төрле яла ягулар белән каралту теләгенә төшмәгез, кешенең зарарына хөкем итәргә ашыкмагыз,

бер кешегә гаеп ташлау вә яла ягуны шәм сүндерү кебек җиңел санамагыз, үз фикерегезнең тугры икәнлеге белән хөкем итмәстән элек шөбһәгезне гакыл әһелләренә җиткерегез, аларның фикерләрен алыгыз, ихтимал ки үз фикерләрегез ялгыш булыр.

## 14. МӨГАМӘЛӘ ӘДӘПЛӘРЕ

112. Мөгамәләләрдә әдәпле вә сак булу холкың ризалыгына сәбәп булганы хәлдә, һичбер акча сарыфына да ихтыяр булмаячактыр. Мөгамәлә әгәр дә әдәпле булса — иң мөшкел максатлар хасил булыр, бикле ишекләр ачылыр, йомшак сүзләр, күңелләрне рәхәтләндерер, ихлас сүз олы бүләкләрдәй артык шатлык китерер, ачык йөз вә катлаусызлык, дуслык вә мәхәббәткә дәлил булыр. Шуның өчен теләсә кем булсагыз булыгыз, адәм балалары белән әдәпле мөгамәлә итегез. Йомшак вә мөлаем сүзле, ихласлы булыгыз!

113. Күңелсез яки ачулы вакытыгызда халык белән сөйләшмичә, бәлки ачу-кызуы сүрелгәнгә кадәр сабыр итегез, адәмнәрнең кимчелекләрен гафу итегез, һәр эштә фикерле вә игътибарлы булыгыз, бу исә — тәрбияле булу билгеседер.

114. Адәмнәргә катнашмыйча бер читтә тормагыз вә яки кем очрады исә аңа катышып, дуслык күрсәтмәгез, бәлки һәр эштә гаделлек белән хөр фикерле, дөрес сүзле, баһадир, әчегез вә тышыгыз бер рәвешле булыгыз!

115. Кешеләрнең усал мөгамәләләренә каршы яхшылык итегез вә яхшы мөгамәләләренә каршы тагын да артык яхшылык итегез, башкаларга күрсәтәчәк мөгамәләгез — алардан күрергә теләгән мөгамәләләрдән һәрхәлдә артык дәрәҗәдә булуына игътибар итегез!

116. Үзегездән кечкенәләрне түбән күрмәгез, гакылыгыз вә байлыгыгыз белән горурланмагыз, бәлки үз мәртәбәгезне вә башкаларның мәртәбәләрен дә яхшы белеп, һәркемнең үзенә яраклы булган мөгамәләсен күрсәтегез. Бер бөек затның: «Барча яхшы — без яман!» — дигән сүзеннән гыйбрәт алыгыз!

117. Халыктан күркәм мөгамәлә күрергә өметегез булса, үзегез дә ал арга яхшы мөгамәлә күрсәтегез. Алардан хөрмәт күрергә теләсәгез, үзегез дә ал арга хөрмәт күрсәтегез. «Халыкның дошман булуында хәстәрем юк»,— димичә, бәлки дуслыкларны эшкә җигәргә тырышыгыз. Гакыл әһелләренең күңелләрен үзегезгә каратачак сурәттә булыгыз, максатларыгызны катылык вә куркыту белән түгел, бәлки мәхәббәт белән хасил иттерәчәк бер дәрәҗәдә булырга гайрәт итегез. Халыкларга мәхәббәтле булуыгыз сәбәпле һичбер камиллегегез югалмас.

118. Халыкларга күркәм карашта булыгыз, яхшы эшләрне сөйләгез, яман эшләрне яшерегез, әмма үлекләрне исә изгелектән башка нәрсә белән искә алмагыз. Адәмнәр белән мөгамәләгез шундый булсын ки: дөньяда торган вакытыгызда сезне сөйсеннәр, вафат булганыгыздан соң юксынсыннар вә кайгырып еласыннар.

119. Халыкларга ярдәм бирү фәкать кирәкле вакытларына гына махсус булып, башка вакытта һичкем-һичкем өстенә салынып торуы, ни гакылча, ни шәригатьчә дөрес түгелдер. Шуңа нигезләнеп, адәмнәр өстенә салынмагыз, аларның малларына өметләнмәгез, бәлки үз ризыкларыгызны үзегез эзләгез, үзегез өчен үзегез йөрегез!

120. Ант итүләрегезне саклагыз, вәгъдәләрегезне җиренә җиткереп, дусларыгызга тугрылыклы булыгыз, халыкларның кайгы вә шатлыкларын уртаклашыгыз. Үзегез сөймәгән нәрсәләрне аларга да сөйдермәгез, әгәр дә мөгамәләгез бу нигезгә нигезләнер булса, арада бердәмлек нык булыр, дуслык таралыр.

121. Халык файдасы вә хак җирләргә ярдәм юлында үткән вакытларны әрәм ителгән вакыт дип санамагыз. Чөнки башкаларны сөю вә аларга ярдәм бирү вә аларның җитешмәгән җирләрен җитештерү — бөеклек вә адәмчелек билгеседер.

## 15. ҖӘМГЫЯТЬ ӘДӘПЛӘРЕ

122. Гәүдәгездә булган әгъзалар, бер-беренә мохтаҗ буларак вә барлык әгъалар берлектә сәламәт булулары хәлдә, камил бер кеше булуы кебек, бу дөньяда торган вакытларында, хәтта җәннәткә кергәннәрендә дә барлык адәм балалары тереклек итү тугрысында бер-беренә мохтаҗ булып торалар. Кешеләрнең бергә җыелуларында кирәкләре табылыр вә хаклары да үтәлер, нәселләре сәламәт калыр Вә мондый бергә җыелуда әдәп, кагыйдә вә кануннар булып боларны олылау тиешле була. Шуның өчен бер-берегезне һәрвакыт хөрмәт итегез. Мөгамәләләрегездә инсафлы булыгыз, җыелу кагыйдәләрен җиренә җиткерегез, үз файдагыз өчен башкаларны җәберләмәгез, эшләрегездә тотрыклы булыгыз!

123. Бергә җыелудан максат исә — бер кеше эшләргә мөмкин булмаган эшләрне эшләү тугрысында ярдәм итешү вә тиешле киңәшләрне бирешү, милләт вә Ватан хезмәтләрен уртаклашудыр. Шуның өчен мондый сәгатьләрдә ярдәм бирүне вә мондый эшләргә катышуны җаныгызга ярдәм дир белегез, адәм баласы берьялгызы аз булган хәлдә, кардәш вә дуслары белән күптер. Әгәр дә мондый сәгатьләрдә, җәмәгатькә хезмәтегез булмаса, барлыгыгызга нисбәт белән юклыгыгыз тагын артыктыр.

124. Шәригать боерган өлешләрне дин вә милләт файдасы өчен сарыф иткән затлар, гүя ахирәттә алу шарты белән Аллаһы Тәгаләгә бурыч бирү кебек булырлар. Шуны исәпләп сез дә, әгәр дә малыгызда мондый чыгачак кисәкләр булса, дин вә милләтне ныгытачак җирләргә сарыф итегез, дөньяда шөкер вә рәхмәт ишетерсез вә ахирәттә бурычыгызны тәмам, бәлки артыгы белән кайтарып алырсыз.

125. Мөселман кешенең теленнән, кулыннан, мөселманнар сәламәт торырлар, дингә өндәгән мөбарәк, ягъни яхшы сүз — хәтерләрендәдер, шуның өчен телегез, кулыгыз вә барлык гамәлегез белән мөселманнарны рәнҗетмәгез, юлга чыгудан элек юлдаш табыгыз, йорт алудан элек күрше алыгыз, кеше көлдерәчәк сүзне сөйләмәгез, кул астыгызда булганнарның холык вә фигыльләрен саклагыз!

## 16. БЕРЕНЧЕ ҮГЕТ

126. Әгъзаларыгызны гөнаһлардан саклап, Аллаһы Тәгалә хәзрәтенә диндарлык күрсәтегез, кушканнарын җиренә җиткерегез, кайгы килгәндә сабыр итегез, халыкларга инсафлы булыгыз вә алардан инсаф көтмәгез вә һичбер мөселманны, һичбер адәм баласын дошман күрмәгез. Аллаһы биргән ризык вә мәртәбәләргә канәгать итегез, халыкларның хөрмәтләрен аяк астына салмагыз, кулыгызда булган байлыкны алга карап тотыгыз. Үзегезгә кирәк булмаган нәрсәләрне тикшерен йөрмәгез. Адәм балалары очраганда сәлам

бирегез. Хәлләрен сорагыз, вәгъдәгездә торыгыз, әдәпле булыгыз. Көчегез җиткән кадәр һәркемгә ярдәм итегез, яхшы кешеләрне дус күрегез, усал кешеләргә яхшы мөгамәлә күрсәтегез. Үзегез мохтаҗ булган нәрсәләрне өйрәнегез, гыйлем тугрысында гарьләнмәгез. Халыкларны рәнҗетмәгез. Күп уйлагыз вә аз сөйләгез, наданнарга вә хыянәтле гакыллыларга серләрегезне сөйләмәгез, киңәш итмәгез, үз белдегегезгә таянмагыз, юашларның мәкерләреннән, чая вә үткен кешеләрнең зарарларыннан тыныч булмагыз. Галимнәргә иярегез, әдәпле кешеләргә кардәш булыгыз, мөрәүвәтле кешеләрдән үрнәк алыгыз, бозык кешеләргә катнашмагыз, тышыгызны пакь вә күңелегезне саф йөртегез. Дин вә дөнья бурычларыгызны вәгъдәсендә тапшырыгыз, халыклар белән бердәм булыгыз. Якын кардәшләрегезгә барыгыз, хәлләрен белегез, халыкларның, ышанып торган очракта, уйларына каршы килмәгез, кулыгыздан килгән хезмәтне һичкем өчен кызганмагыз. Һәр көнне башыгызны ястыкка куйган вакытыгызда, көн буена нинди эшләр эшләгәнегезне санап чыгыгыз, изге эшләрегез булса — Аллаһы Тәгаләгә шөкер итегез, усал эшләрегез булса үкенегез, тәүбә итегез вә иртәгә эшләячәк эшләрегез хакында план корыгыз. «Иртә өчен ишәк кайгырыр»,— димәгез. Рәнҗетелгәннәр догасыннан сакланыгыз, ләззәтләрне боза торган үлемне онытып җибәрмәгез, көннәр — гамәлләрне күрсәтә торган дәфтәрләрдер, бу дәфтәрләргә бозык нәрсәләр яздырмаска тырышыгыз, кич вә көндез — сезнең изге гамәлләрегезне азайтадыр, сез исә кич вә көндезне изге гамәлләрегез белән азайтыгыз. Мөбарәк шәригатебезгә каршы булмас шарты белән теләсә кемгә булсын, итагать итегез, ягъни күндәм булыгыз. Бозык фигыльләр белән дөнья тулганлыктан, сез гүзәл холыклар белән изге эшләр эшләгез.

## 17. ИКЕНЧЕ ҮГЕТ

127. Күзебезгә мондый зиннәтле күрелгән дөнья — хыянәт, алдау, җәбер вә золым итү кебек дөньяви нәрсәләргә дәлилләүдә булганлыктан, ахырда беркөн Аллаһы Тәгалә хәзрәтенә барачагыбыз вә һәрбер яхшы вә яман эшләр хакында җавап вә хисап бирәчәгебезне онытмагыз. Ахирәттә мәсхәрәлеккә әтөшерәчәк, дус вә дошман арасында йөз кызартачак нәрсәләрне эшләмәгез, гүзәл холыкларны гадәт итегез, тугры юлдан, бер карыш булсын аерылмагыз. Дөнья игътибарында үзегездән түбәннәргә, дин җәһәтенчә үзегездән бөекләргә карагыз, дөнья-ахирәттә бәхетле булырсыз. Изгелек орлыклары чәчегез, бәхет игеннәре урырсыз. Гүзәл холыклы кешеләргә юлдаш булыгыз, төшкән вакытларыгызда күтәрерләр вә кыерсытылган вакытыгызда ярдәм итәрләр. Бозык холыклардан ерак булыгыз, чөнки алардан яхшылык күрмәссез, дәрәҗәгездән төшерерләр, әманәтләрегезгә хыянәт итәрләр, серләрегезне фаш итәрләр. Гөнаһларыгыз өчен үкенегез, Аллаһы Тәгаләгә кимчелек белән булса да, гыйбадәт кылыгыз, пәйгамбәренә хөрмәт белән дога кылыгыз. Балаларга сабырлык сорамастан элек, Аллаһы Тәгалә хәзрәтеннән балаларга саулык-сәламәтлек сорагыз. Сабырлык бирергә кодрәте булган Аллаһы Тәгаләнең саулык-сәламәтлек бирергә дә көче бардыр. Саулык-сәламәтлек кадәр кыйммәтле вә ләззәтле нәрсә һич юктыр. Моны исә сәламәт вакытыгызда белегез. Ятимнәр хакларына кул сузмагыз, күршеләр белән яхшы көн кичерегез. Намазларыгызны калдырмагыз, мөмкин булганда мәчеткә барыгыз, бер-берегезнең хәлен белешеп торыгыз, изгелек белән яшәгез. Усаллыктан бер-берегезне тыегыз. Гакылсызлар белән дус булмагыз, яхшы мөэмин булырга теләсәгез, Аллаһы Тәгалә юлына берләшегез, базарларда кирәксезгә җыелып сөйләшеп утырмагыз, халык җомга намазына барганда, сез сәфәргә

чыгып китмәгез. Юк-бар нәрсә өчен ачуланмагыз, кешеләрнең өстенлек вә бәхетләренә һич вакытта көнләшмәгез, көнләшү фәкать вөжданны рәхәтсез итеп тору булып, башка бер файдасы юктыр. Үлем килүеннән хәбәрсез булып тормагыз, һәрвакыт вә һәр сәгатьтә исә үлем килү мөмкиндер, Аллаһы Тәгаләгә якын итәчәк нәрсәләрнең ахирәттә уттан ерак итәчәген, утка якын иткән нәрсәләрнең Аллаһы Тәгаләдән ерак итәчәген һәрвакыт күңелегездә тотыгыз!

## 18. ӨЧЕНЧЕ ҮГЕТ

128. Башкаларның гайбәтләрен күргән вакытыгызда, үз гаепләрегезне хәтерегезгә китерегез, үз гаепләрен күргән кеше башкалар гаебе белән шөгыльләнмәс. Һичкем өчен чокыр казымагыз, үзегез төшәрсез. Хаклык белән көрәшмәгез, егылырсыз. Мөселманның йөз суын түкмәгез, үз йөзегезнең суы түгелер. Фикерегезгә хәйран булмагыз, адашырсыз. Халыкларга тәкәбберлек күрсәтмәгез, хур булырсыз. Эшләрегездә гакыл әһелләренә киңәш итегез, үкенмәссез. Галимнәр мәҗлесенә дәвам итегез, олы булып күренерсез. Ахмаклар мәҗлесенә кермәгез, аларның берсе саналырсыз. Аз сөйләгез, аз ялгышырсыз. Ялган сөйләү белән исем чыгармагыз, барлык халыкның күзеннән төшәрсез. Җенси дәрт әсире булмагыз, мәсхәрәлеккә калырсыз. Һәркемнең дәрәҗәсен белегез, хайваннар дәрәҗәсеннән чыгып, кешеләр дәрәҗәсенә аяк басарсыз. Аллаһы Тәгаләдән башка һичкемнән өмет итмәгез. Үз гөнаһыгыздан башка һичнәрсәдән курыкмагыз. Белмәгән нәрсәләрегезне «белмим» диюдән оялмагыз, белергә тиешле гыйлемнәрне өйрәнүдән гарьләнмәгез. Үзегез өчен сөйгән нәрсәләрне башкалар өчен дә сөегез, үзегез өчен теләмәгән нәрсәләрне башкалар өчен дә теләмәгез. Ирекле булган нәфесегезне бәндәләргә кол итмәгез. Азгын бай булудан саф вә һөнәрчән фәкыйрь булуны артык күрегез. Аллаһы Тәгалә хәзрәтенә диндар булыгыз, кушканнарын җиренә җиткерегез. Күңелегезне вәгазь белән нурландырыгыз, нәфесегез симерсә — үлемне исегезгә китерегез. Узган кавемнәр өстенә килгән нәрсәләрне фикерләп гыйбрәтләнегез. Дөньягыз өчен ахирәтегезне сатмагыз. Белмәгән нәрсәләрегез хакында белүче булып сөйләшмәгез. Үзегезгә сөйләнмәгән сүзләргә җавап бирергә көчәнмәгез. Ахыры бозыклыкка барыр дип уйлаган юлларга кермәгез. Аллаһы Тәгалә ризалыгы өмет ителгән урында халык шелтәсеннән курыкмагыз. Яхшы кешеләргә якын булыгыз, алардан саналырсыз. Усаллардан ерак торыгыз. Хакыгыз булмаган җирләргә күз салмагыз. Хәрам аш — агудыр. Үз ризыкларыгызны үзегез эшләп табыгыз, кешеләргә ышанып ятмагыз, бу нәрсә исә — фәкать кабердә булганнарга ярашыр бер хәлдер.

## 19. ДҮРТЕНЧЕ ҮГЕТ

129. Изге Коръәнне үзегезгә имам итеп, һәрвакыт аның белән гамәл итегез, һәрвакыт Аллаһы Тәгалә хәзрәтенә диндарлык күрсәтегез, хәрамне — хәрам, хәләлне хәләл дип белерсез, дөнья сезне куса да, сез дөнья кумагыз (ягъни дөньягыз өчен ахирәтегезне һәлак итмәгез, юкса дөрес ният белән кәсеп итү вә байлык булдыру — дөнья куу түгелдер). Дөрес сүзле булыгыз, булмый калган эшләр өчен үкенмәгез. Бер-бере-гез белән киңәшеп тереклек итегез. Яшәп узган халыклар хәленнән гыйбрәт алыгыз. Киләчәк көннәрегезне уйлагыз, кирәк — дөрес, кирәк — ялган булсын, һичнәрсә өчен ант итмәгез. Аллаһы Тәгаләнең исемен шаһит итәр өчен хәтта бөтен дөньяның кыйммәте юктыр. Мөселманнарга зарар китерәчәк нәрсәләрдән сакланыгыз. Күз алдында оят булачак эшләрне яшерен дә эшләмәгез. Әйтергә ярамаган сүзләрне тишермәгез. Һәр ишеткән сүзне

сөйләмәгез. Һәрбер сүзгә каршы торучы булмагыз. Үч алырга көчегез җитсә дә ачуыгызны түгегез. Аллаһы Тәгалә җибәргән нигъмәтләрне кадерсез итмәгез, аның әсәрен — эзен халыкка да күрсәтмәгез. Шөкер итүчегә яхшылык итегез, яхшылык итүчегә яхшылык итегез. Бер җирдә низаг вә тавыш калыкса — дәшми торыгыз. Сугыш булса — ул җирдән башыгызны алып бер якка китегез. Алдыгызда кеше гайбәтен сөйләүчеләрдән, башкаларга барып сезнең гайбәтегезне сөйләмәүләреннән тыныч булмагыз. Теләсә кемнән ялынычы төшмәгән бәйсез кеше булыгыз, аның тиңдәше булырсыз. Теләсә кемгә мохтаҗ булыгыз, аның әсире булырсыз, теләсә кемгә изгелек итегез, аның әмире булырсыз. Сынамастан элек һичкем хакында яхшылык белән шаһитлык бирмәгез. Хәлне белмәгән вакытта һичкемнең хәбәрен дөрес дип дәгъва кылмагыз, яхшы аңламаган затларның тышларыннан күркәм хөкем йөртмәгез. Дус сайларга хаҗәтегез булганда, ярдәм итүче, дөрес сөйләүче, изгелегегезне күрүче, яманлыкларыгызны яшерүче, кайгы вә шатлыкларыгызны уртаклаучы булган кешеләр сайлагыз, болай булмаса — аларның дуслыгыннан файда чыкмас. Мал вә дәүләтегез белән халыкларны ризаландыра алмасагыз да, холкыгыз белән ризаландырыгыз. Яхшы кешенең ач вә усал кешенең тук вакытларыннан сакланыгыз. Бозык холыклы кешеләргә яр булмагыз, үзегез һич сизмәгәндә аларның холыкларын алырсыз. Бер кешенең аягы таюдан шатланмагыз. Бәлки мондый хәл үзегезгә дә килер. Әдәпсез кеше белән ярышмагыз, исерек белән сөйләшмәгез. Динегез тугрысында Аллаһы Тәгалә хәзрәтен риза итәчәк юл белән вә дөньягыз тугрысында тереклегегезне төзәтәчәк рәвеш белән йөрегез. Һичбернәрсә өчен үкенмәгән хәлдә дөньядан аерылыгыз, рәхәтлек исә — мондадыр.

## 20. БИШЕНЧЕ ҮГЕТ

130. Бер кеше өчен икенче бер кеше белән бозылышмагыз, ихтимал, алар дуслашырлар, сез исә уртада дошман булып калырсыз. Гүзәл эшләрне күреп торуда булган күзләр вә язып торуда булган каләмнәр бардыр. Шуның өчен изгелек эшләрегезне халыкларга фаш итәргә ашыкмагыз. Гакылына караганда теле куәтле кеше белән дус булмагыз. Дин тугрысында башка кайгыларны кайгыдан санамагыз. Гакылыгыздан башка дәрес киңәш бирүчене эзләмәгез. Наданлыгыгыздан башка дошманнан курыкмагыз. Озын телегездән артык ялганчы, әҗәлегездән артык вәгъдәдә торучы юктыр. Үз фикеренә хәйран булган кешеләргә акыл бирмәгез. Аллаһы Тәгаләнең фарыз, ягъни үтәлергә тиешле нәрсәләрен җиңел санамыйча, вакытында өстегездән төшерегез, хәрам иткәннәрен эшләү түгел, хәтта эшләргә дә теләмәгез, бу ике арада булган эшләрне тикшереп йөрмәгез, ниятегез бозык булганда керешмәгез, ниятегез бозык булмаса тырышыгыз. Гыйлем нурын гөнаһ белән сүндермәгез. Диндарлыктан гүзәл кием эзләмәгез. Әдәпсез табигать (холык) гүзәл булмас, тырышмыйча торып гыйлем табылмас, моны исә белегез. Бер көн файда булса — икенче көн зарар булыр, адәм баласы шушы көннәрне чиратлап үткәрер, ләкин һәр икесен дә әҗәл сәфәре дип белеп үзенә күрә хәзерләнегез!

## 21. АЛТЫНЧЫ ҮГЕТ

131. Аллаһы Тәгалә хәзрәтенең Коръән Шәрифенә (Изге Коръәненә) барыгыз берлектә ябышыгыз да һич аерылмагыз. Арагызда булган дошманлык вә каршылыкларны чыгарыгыз да дус булыгыз. Изге шәригать вә милләт ярдәме өчен барча тырышлыгыгызны сарыф итегез. Мәртәбә вә олуглык сөюгә дучар булмагыз. Фәкыйрь вә зәгыйфьләрнең кулларыннан тотыгыз вә аларга ярдәм бирегез. Аллаһы Тәгалә хәрам

иткән урыннарга вакыт вә акча исраф итмәгез. Йокыларыгыз дан уяныгыз, күзләрегезне яхшы ачып дөнья тәртибен күрегез. Нинди фәкыйрьлек вә наданлык эчендә булганыбызны белегез. Күп аталар бардыр ки, балаларының тәрбияләрен вә гыйлем өйрәнү юлында һич кайгырмаганнары вә байлык сарыф итмәгәннәре хәлдә, исерткеч вә фәхишәләр өчен барлык хәзинәләрен сарыф итәләрдер. Күп хатыннар бардыр ки: ирләре бер кадак икмәк табудан гаҗиз булып йөргәннәре хәлдә, киявен көтүдә булган кызлар мисалында киенеп урамнарга йөриләрдер. Күп сакаллы сабыйлар бардыр ки: кызларына бер хәреф гүзәл холык өйрәтмәгәннәре хәлдә, ислам шәригатенең иң бөек вә иң хөрмәтле булган җомга көннәрендә, яшь егетләр вә буй җиткән кызлар белән уйнар өчен җибәрәләрдер. Бу хәлләр исә — күңел күзләренең сукыраюына вә күңелләренең каралуына олуг дәлилдер. Һәр эштә түбән, фәкыйрь, надан, артта калуына һичкем сәбәп түгел, үзебездер. Аллаһы Тәгалә җибәргән нигъмәтләрнең китмәвенә баш сәбәп — бәндәләр үзләре булыр. Шуның өчен бу хәлләр дән гыйбрәт алыгыз, үз яклавыгызда булган гаиләгезне вә аның әгъзаларын ислам тәрбиясе белән тәрбияләгез. Үзегез дә холык, фикер, инану, гамәл, диндарлык тугрысында аларга үрнәк булыгыз. Диндарлык итүчеләргә Аллаһы Тәгалә ярдәмче, хак юлны эзләүчеләрне Аллаһы Тәгалә тугры юлга күндерүчедер. Моны исә көн кебек ачык белегез.

## 22. ҖИДЕНЧЕ ҮГЕТ

132. Адәмнәрнең гаепләрен эзләп йөрмәгез. Бер-берегездән көнләшмәгез, үпкә тотмагыз, ачу кумагыз, бәлки бертуган кебек дус булыгыз. Мөмкин булганда кешедән әйбер сора. магыз (теләнчелек итмәгез). Дин тугрысында низаглашмагыз әмма зинһар юк-бар нәрсәләр өчен бер-берегезне кяферлектә ягъни дингә ышанмауда гаепләмәгез. Никадәр гөнаһлы бәндә булса да, аның хакында кяфер, ягъни динсез дип шаһитлык бирү Рәсулулла (Аңа Аллаһы Тәгаләнең хәер хәер догасы һәм сәламе булсын!) тарафыннан тыелды. Кирәге булмаганда, сул кулыгыз белән ашамагыз. Сорап йөрүчеләрне мәхрүм итмичә, аз булса да биреп җибәрегез. Күршеләрегезнең хөрмәтен саклагыз. Ишеткән гыйлем вә яхшы сүзләрне дәфтәрегезгә теркәп куя торган булыгыз. Кирәкмәс сүзләрне сөйләүдән телегезне саф тотыгыз. Кунакларыгызны хәлегез кадәр хөрмәт итегез. Тагун һәм ваба, ягъни чума һәм үләт булган җирләргә бармагыз, булган җирләрдән качып чыкмагыз (тагун, вабаларны хәдисләр җеннәр сәбәбеннән дигәннәре — бүгенге акыл ияләренең микроб дигәннәренә каршы түгелдер. Чөнки микробларда — җеннәрдер), гайбәт сөйләмәгез, зина кылмагыз. Йокы вакытында, ишекләрне, тәрәзәләрне бикләгез, савыт-сабаларның өсләрен ябыгыз (моның кебек нәрсәләрнең сәбәбе исә өсләре ачык булган савытларга зарарлы микроблар күп төшмәсен дип сакланудыр), шәмнәрне сүндерегез. Мөселман кардәшләрегез очраганда сәлам бирегез. Чакырыр булсалар — җавап бирегез. Хәстәләнсәләр — хәлләрен сорагыз, вафат булсалар — җеназаларына барыгыз. Изгелеге ерак, усаллыгы якын йөрүдә булган затлардан сакланыгыз. Бер кавемнең хөрмәтлесе килсә — хөрмәт итегез, бүгенге гамәлне иртәгәгә кичектермәгез!

## 23. СИГЕЗЕНЧЕ ҮГЕТ

133. Адәм балаларына, Аллаһы Тәгалә хәзрәтеннән бөек бүләк вә башка хайваннардан аерачак сыйфат булган «гакыл»ны олуг бер нигъмәт дип белегез һәм саф вә камил асрау тугрысында игътибарлы булыгыз. Мондый бөек нигъмәтне вә мондый изге булган Аллаһы Тәгаләнең бүләген саклап тоту — адәм баласы өчен иң беренче бурыч

икәненнән хәбәрдар булыгыз. Хәл болай икән, дөньяда кайбер кешеләр булыр ки, бу газиз нигъмәтне исерткеч өчен әрәм итәрләр. Әгәр дә гакыл базарларда алтын бәрабәренә сатылса иде, адәм угыллары соңгы нәрсәләрен сатып, гакыл алу өчен йөгерешерләр иде. Хәлбуки мондый кешеләр, акчалары белән диваналык сатып алалардыр. Фараз итик: исерткеч эчү шәригать карамагында хәрам булмасын, ахирәттә аның бәрабәренә җәза да булмасын, дөньяда мәсхәрә булуга вә хәстәлеккә төшүгә дә сәбәп булмасын, аның яман эш икәнен исбат итү өчен шушы гакыл нурын сүндерүе дә тәмам җитәчәктер. Вә хәлбуки исерткеч эчү ислам шәригатебездә беренче мәртәбә тыелган нәрсә булып, ахирәттә булачак җәзалары да адәм баласы көч китерәчәк дәрәҗәдә түгелдер. Дөньяда да иң бөек мәсхәрәлекләргә вә дәвасыз булган хәстәлекләргә сәбәп булачак агу вә зәһәрдер. Ислам каршында исерткеч «Өммел-хәбаис», ягъни «Барлык явызлыкларның вә усаллыкларның анасы»,— дип әйтелә. Чыннан да, исерткеч эчүдә булган зат — дөньяда булган бозыклыкның һичберсен эшләүдән тартынмас. Исерткеч эчү сәбәпле, адәм утлы Сафлык, Горурлык, Сабырлык, Намуслылык, Ышаныч, Пакьлек, Сер саклау, Икътисад, Алдан күрү, Гаилә тәрбияләү кебек күркәм холыклардан тәмам мәхрүм калыр, Байлык вә Вакыт кебек кыйммәтле хәзинәләрне әрәм итәр. Вә бу бозык холыкны аркасыннан, ягъни артыннан килгән вә яки киләчәк булган мәгъсум, ягъни гөнаһсыз сабый балаларына кадәр мирас калдырып китәр. Табиблар хәбәренә күрә, чахотка, баш, йөрәк, ашказаны авырулары күп вакытта исерткеч эчү сәбәпле пәйда булыр вә бала һәм нәселләргә ядкәр буларак калыр. Ничбер гүзәл тәрбия бирмәгән хәлдә, гөнаһсыз булган баласына чахотка яки башка бер хәстәлек; яки фәкать исерткеч эчү — бозык гадәтне мирас итеп калдыру — никадәр кызганыч вә күңелләргә җәрәхәтле эз бирәчәк бер хәлдер. Шуның өчен бу зәһәр вә бу агудан иң элек үзегезне вә соңыннан гаиләгезне, хәтта ки барлык кардәш вә кабилә, дус-ишләрегезне саклау хакында барлык тырышлыгыгызны сарыф итегез, тырышыгыз, бу исә иң кирәкле вә иң файдалы бер сугыш булыр. Бу сугышта җиңгән кеше мәңгелек бер гүзәл исем алыр, соңыннан да бу гүзәл исем макталыр. Иң якын бер дустыгыз каза белән суга батып үлгәнен ишеткәч кайгырыгыз, ләкин «Шөкерләр булсын, исерткеч эчмәде, фәкать суда батып үлде, әгәр дә исерткеч эчү белән мавыккан булса — ни чара булачак иде?!» дип, Аллаһы Тәгаләгә мактаулар әйтегез.

## 24. ТУГЫЗЫНЧЫ ҮГЕТ

134. Бер-берегездән көнләшмәгез, ачуланышмагыз, сүз үлчәшмәгез, бер-берегездән аерылып тормагыз. Ачу вакытында үз-үзегезне тота белегез. Рәнҗетүдән, процент алудан (риба) вә саранлык итүдән сакланыгыз, ялган, гайбәт, яла ягу сөйләмәгез. Сүз йөртмәгез, вәгъдәгезгә каршы килмәгез. Әманәткә хыянәт итмәгез, мөэмин кардәшләрегезне, хосусан үлекләрне сүкмәгез, ләгънәт кылмагыз, динсез дип сөйләмәгез, яман уй йөртүче булмагыз. Кеше көлдерер өчен сүз сөйләмәгез. Белешләрегезнең вә белеш түгелләрегезнең барчасына сәлам бирегез. Якын кардәшләрегездән аерылып тормагыз, фәкыйрьләргә яхшылык итегез. Кешеләр йоклаганда сез кайбер вакыт булса да намаз укыгыз. Үзегез, ата вә аналар, әби вә бабайлар, туганнарыгыз, ирләрегез вә хатыннарыгыз, кыямәт көненә кадәр киләчәк нәсел-нәсәпләрегезнең иман белән дөньядан кичүләре хакында дога кылыгыз. Кабул булса булмаса да дога кылу — Аллаһы Тәгалә хәзрәтенә ялвару — гыйбадәттер, шуның өчен бу эшне дәвам итегез, хосусан күңел төшкән вакытларны файдалана белегез. Ләкин үзегез белән Аллаһы Тәгалә арасына һичбер кешене уртага куймагыз, һәр хаҗәтегезне тугры үз телегез белән һәм ихлас күңелегез белән сорагыз.

Ихлас соралган догалар — бүген булмаса, бер көнне кабул булыр, моны исә шөбһәсез дөрес белегез.

## 25. УНЫНЧЫ ҮГЕТ

135. Үз-үзен белүче вә киләчәк көне өчен гамәл итүче кеше — зирәктер. Диннән иң элек югалачак нәрсә — әманәт, ягъни ышаныч вә иң соң югалачак нәрсә — намаздыр, намаз югалуы күренсә, «Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун», «Чыннан да, без Аллаһы Тәгалә тарафыннан барлыкка китерелгәнбез һәм чыннан да без Аңа әйләнеп кайтабыз» (берәр кеше вафат булгач укый торган дога.— Ә. Х.) дип уку вакыты килгән булыр. Монафикъларда, ягъни икейөзле кешеләрдә диндә игътибарлы булу һәм дә күркәм холыклы булу һич күренмәс. Дөнья хурлыгы ахирәт хурлыгыннан җиңелдер. Зина иткән кеше фәкыйрь булыр, якын кардәшләренә кушылган кешенең гомере бәрәкәтле булыр. Аллаһы Тәгаләдән курку — хикмәтнең нигезедер. Балаларына мал җыеп та, Аллаһы Тәгалә каршысына фәкыйрь барган кешеләр — бәхетсезләрдер. Усаллыктан кайгыру, яхшылык өчен сөенү— мөэминлек, ягъни ислам динендәге кеше булу билгеседер. Ризыкларны туфрак астыннан эзләгез (сабан сөреп ашлык чәчегез, Урал тауларына барып тимер вә алтын һәм асыл ташлар казыгыз, моны казый белер өчен махсус мәктәпләргә кереп укыгыз). Аллаһы Тәгалә биргән дәүләтне балаларыгызны вә гаиләгезне тәрбияләүдән кызганмагыз. Тоташтан сәламәт булып тору — хәстәлектер. Йөрәксез сәүдәгәр — мәрхүм булыр. Үлем үзеннән элек хәлгә караганда авыр булса да, үзеннән соңгы хәлгә караганда җиңелдер. Кешеләрне яманларга ниятләгәндә, үз хәлегезне үзгәртегез. Фарызлардан, ягъни үтәлергә тиешле бурычлардан элек өстәмәләре белән мәшгуль булмагыз. Серегезне саклаган вакытыгызда ихтыярыгыз кулыгыздадыр. Бер-берегез белән дус булыгыз, йөрешегез, ләкин күрше белән булышмагыз. Кечкенә хәсрәтләрне зур күрмәгез. Белмәгән әйберләрегезне «белмим» дип әйтүдән һич кире тормагыз. Ялган шәһадәт бирмәгез. Хакыгыз булмаган нәрсәләрне дәгъва кылып алмагыз. Аллаһы Тәгаләнең нигъмәтләренә, ягъни муллыкларына-байлыкларына шөкер-рәхмәт вә кайбер вакыт бирелгән бәлаләренә сабыр итегез. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте-мәрхәмәте сабыр итүчеләргә булуын онытмагыз!

## 26. УНБЕРЕНЧЕ ҮГЕТ

136. Гөнаһ онытылмас, изгелек җирдә калмас. Киләчәк көндә үлем бар, соңыннан зур һәм куркыныч сурәттә хисап булачак. Бу көндә күп йөзләр ак вә күп йөзләр, Алла сакласын, кара булачак!.. Һәркем дөньяда кылган гамәленең җәзасын ахирәттә күрер вә һәркем ни чәчсә — шуны урыр. Үлем тамырлары киселмәстән элек бер көн элек хәзерләнегез, изгелек итәргә дә ашыгыгыз. Җенси дәртегезгә дучар булып, динегезне бозмагыз, юк-бар шөбһәләр белән гүзәл инануыгыздан азмагыз. Яхшы гамәлләр өчен тырышыгыз, һич бул-маса — усаллык артыннан йөрмәгез. Сәламәтлек белән тынычлык — бик бөек нигъмәтләрдер, кадерен белегез. Гомер файдасыз җирләргә сарыф итәчәк дәрәҗәдә озын түгелдер, дөнья малы Аллаһы Тәгалә риза булмаган урыннарга түгәрлек мәртәбәдә күп тә түгелдер. Изгелек итүчеләрдән дә бу дөнья үтәр, яманлык итүчеләрдән дә! Ләкин тешләрең бер-береңә сугылачак вә тезләр дер-дер калтырап торачак көннәр алдадыр. Бу көндә нәселдән, кабиләдән, гүзәллектән вә башкалардан соралмый, ләкин

фәкать яхшылыктан соралыр. Дөньягызда булмаган максатларыгыз өчен үкенмәгез, булганнары өчен дә үз-үзегезне белмәс дәрәҗәдә шатланмагыз. Тәүбәне кичектермәгез, үлемне дә гүя башкаларга гына киләчәк дип уйламагыз. Башкаларның гаепләрен тикшермәстән элек үз гаепләрегезне тикшерегез. Хәләл кәсеп белән тапкан малыгызны да тиешле урыннарына сарыф итегез. Дин әһелләренә, күңеле төшкән кешеләргә мәрхәмәтле булыгыз. Гыйлем вә намуслы булганнарга катышыгыз. Гыйлемегез белән гамәл итегез, гыйлемегездә риялы, ягъни ялган, икейөзле булмагыз. Үлекләрне юыгыз, үзегезгә дә шулай бер көн киләчәкне күз уңында тотыгыз. Каберләргә барыгыз, дөньядан эш вә мәшәкатьләре бетеп, киләчәк көннәрне көтеп ятуда булган бу бәндәләрнең хәлләрен тирән уйлагыз. Күңел йомшаячак вә гыйбрәт алыначак җир — үлекләр вә аларның хөрмәтле урыннары булган каберлекләрдер. Аллаһы Тәгалә хәзрәте бу көннәрдә барыбызга да мәрхәмәтле булсын!

(Тәмам)

# Шәкертлек әдәпләре

*Әхлак гыйлеменнән*

## ГЫЙЛЕМ

Гыйлем дөньяда һәм ахирәттә үзенә файдасы яки зарары булачак нәрсәләрне белү дип атала. Гыйлем — кешеләргә хас булган бер сыйфаттыр. Гыйлемнән башка сыйфатлар, мәсәлән, батырлык, юмартлык, шәфкать итүчелек кебекләр башка вакытта, башка хайваннарда да табылыр.

Гыйлем өйрәнү — бәндәләр өстендә олуг бурычтыр. Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре: «Белмәгән нәрсәләрегезне белгән кешеләрдән өйрәнегез!»— дип боерган. Һәм: «Белгән кешеләр белән белмәгән кешеләр бер дәрәҗәдә була алырмы? Булмаслар!»— дигән. Шулай ук хөрмәтле Рәсүл әфәндебез Мөхәммәд-тән (Аңа Аллаһы Тәгаләнең хәер догасы һәм сәламе булсын!) менә мондый изге хәдисләр риваять итеlә: 1) Һәр мөселман өчен гыйлем өйрәнү — фарыздыр, ягъни үтәлергә тиешле бурычтыр. 2) Гыйлем өйрәнүчеләрдән риза булып, фәрештәләр канатларын иңдереп торырлар. 3) Гыйлем юлына кергән кешене Аллаһы Тәгалә җәннәт юлына кертер. 4) Аллаһы Тәгалә хәзрәте, фәрештәләр, җир, күк әһеле, хәтта ки ояларында булган кырмыскалар, суда булган балыклар, гыйлем өйрәтүчегә рәхмәт һәм дога кылырлар. 5) Гыйлем өйрәнергә дип өеннән чыккан кеше, кайтып кергәнче, Аллаһы Тәгалә юлында дип исәпләнер. 6) Кыямәт көнендә пәйгамбәрләр, аннан соң галимнәр, аннан соң шәһидләр арадашчы булырлар. 7) Аз гыйлем — күп гыйбадәттән хәерлерәктер. 8) Гыйлем өйрәнгән вакытында вафат булган кеше, пәйгамбәрләрдән генә түбән булганы хәлдә, Аллаһы Тәгалә юлына юлыгыр. 9) Галимнәр — пәйгамбәрләрнең варисларыдыр.

Болардан башка хәдисләр дә күп. Инде юлбашчыбыз булган хөрмәтле Пәйгамбәребез хәзрәтләре мондый рәвештә мактаган нәрсәне өйрәнүебез һәм бурыч, һәм бәхет-сәгадәтебезгә дә сәбәп булыр.

Хәзрәти Гали (Аллаһы аннан риза булсын!): «Аллаһы Тәгалә дошманнарга малын һәм безгә гыйлемен бүлеп бирде. Ләкин без табышлы чыктык, аның өчен мал беткән хәлдә, гыйлем артадыр», — дигән.

Габдулла бине Мәсгуд хәзрәтләре (Аллаһы аннан риза булсын!) гыйлем өйрәнүчеләрне күрсә: «Хуш киләсез, акыл чишмәләре, караңгылык шәмнәре, иске киемле яңа күңеллеләр, һәр кабиләнең чәчәкләре!!!» — дип әйтә торган булган.

Хәзрәти Гали (Аллаһы аннан риза булсын!): «Гыйлемнең дәрәҗәсе олуг икәнлеге моннан мәгълүмдер; һәркемдә азмы-күпме гыйлем дәгъвасы буладыр, ул — «Гыйлеме бар» дигәннән шатланадыр, «Надан» дигәнне ишетергә риза булмыйдыр»,— дигән.

Имам Шәгъби хәзрәтләре: «Һәмаданнан бер фәкыйрь кеше булганым хәлдә хаҗ кылган кеше янына кердем, гыйлемем булу сәбәпле, бай һәм әфәнде булып яныннан чыктым»,— дигән. Чөнки гыйлемдә камил икәнлеген белгәннән соң, хаҗ кылган кеше аңа күп вазифалар йөкләгән.

Гыйлемле кеше вафат булганда, исеме һәрвакытта кала. Галимнәр кабердә ятсалар да тереләрдер; әмма наданнар җир өстендә йөрсәләр дә үлеләрдер. Гыйлемлелек — диндарлыкка сәбәп, диндарлык — дөнья һәм ахирәттә бәхетле булуга сәбәптер. Гыйлем — һәр авырлыктан котылырга сәбәпчедер. Гыйлемлелек — бетми торган хәзинәдер. Гыйлем

— дөнья сукырлыгыннан, ахирәт газабыннан саклаучы нурдыр. Гыйлем — аулакта иптәш, ялгызлыкта — сердәш, дуслар каршында — бизәк, дошманнарга каршы үткен коралдыр. Гыйлем өйрәнгән кешенең максатлары — үзенә каршы килеп көтеп торудыр. Гыйлем — олуг дәрәҗәдер, бу дәрәҗәгә ирешкәннән соң, кешенең башка дәрәҗәгә ихтыяҗы булмас, бәлки башка дәрәҗәне дәрәҗәгә дә санамас. Гыйлемлелек — бер ләззәттер ки: аның кебек ләззәт — дөньяда юктыр, бәлки ахирәттә дә булмас.

Гыйлеме булган кешегә олуг вә кечек ишекләр барысы да ачык булыр. Гыйлем белән шәригать хөкемнәре беленер, Аллаһы Тәгаләгә буйсынылыр һәм гыйбадәт кылыныр. Гыйлем белән хәләл һәм хәрам беленер, кешеләрнең кыйммәтләре артыр.

Шуның өчен гыйлемне ихлас һәм мәхәббәт белән өйрәнү тиешле булыр. Ләкин гыйлемне өйрәнүчеләр өчен бер кадәр вазифалар бардыр, аны хөрмәтләү кирәктер. Аның юлыннан йөрмәгәндә максатка җитешү авыр булган кебек, вазифаларны хөрмәтләмәсә, гыйлем өйрәнү авыр булыр, яки өйрәнелми калыр. Әлеге вазифалар хакында без бу язмабызда да бәхәс алып барачакбыз.

**БЕРЕНЧЕ ВАЗИФА (Дәрес уку тәртибе)**

Гыйлем өйрәнүдә үзенең тәртибе белән өйрәнү тиешледер. Ягъни кирәклердән элек бик кирәкләрне һәм кирәкмәслердән элек кирәкләрне өйрәнергә кирәк буладыр.

Сәүдә белән шөгыльләнергә керешсә, ул вакытта сәүдәнең шәригать каршында булган хөкемнәрен белү кирәк. Шулай ук, башка берәр кәсеп белән шөгыльләнсә, шул нәрсәнең дә шәригатьчә булган гыйлемнәрен өйрәнү тиешле булыр.

Имам Мөхәммәд бине Хәсән хәзрәтләре (Аңа Аллаһының рәхмәте булсын!): «Заһидлек, ягъни дөнья эшләреннән ваз кичеп, гыйбадәт белән генә шөгыльләнү турында китап язсаңчы!» —дигән сүзгә каршы: «Сәүдә хакында шәригать хөкемнәрен бәян итеп яздым»,— дип җавап бирде. Бу җавап белән, заһидлек, ягъни дөнья эшләреннән ваз кичеп, гыйбадәт белән генә шөгыльләнү, тәкъвалык-диндарлык мөгамәләләре дә шәригать боерганча булудан башка нәрсә түгел икәнлеген белдерәдер.

Шулай ук балигъ булган кешеләрнең барысына да әхлак гыйлемен белү тиештер. Мәсәлән, тәвәккәл булу, тәүбә итү, сабыр итү, риза булу, курку, сорый белү, тыйнаклык, намуслылык һәм боларның кире мәгънәләрен белү тиештер. Чөнки бу нәрсәләр белән гамәл итү бәндә өстендә бурыч булып торадыр. Әгәр дә гыйлемнәре беленмәсә, ул вакытта болар белән гамәл кылу мөмкин булмас.

Озын сүзнең кыскасы, гыйлем бик күп. Әмма, гомер бик кыска һәм аз булганы өчен, бик кирәкләр санында кирәкләрне өйрәнү һәм дә мөмкин кадәр борынгы бабаларыбыз юлынча гына йөрергә тиешле була. Мәсәлән, фарыз гайн, ягъни аерым үзеңнең йөкләмәң булган иманулар гыйлеме — борынгы бабаларыбыз ысулынча укылганда, сабый балалар да, гомерләрендә мәктәп һәм мәдрәсә күрмәгән гади халык та һәм хатын-кызлар да аңларлык дәрәҗәдә җиңелдер.

Шулай ук хөрмәтле сәхабәләр, ягъни Мөхәммәд Пәйгамбәрнең фикердәшләре һәм борынгы бабаларыбыз гадәтенә караганда, иманударның дәлилләре белән белү — авыр түгелдер. Чөнки болар каршында иманударның дәлиле Коръән белән Хәдис булып, шул

ардан үтмәсләр иде. Шулай булгач, Коръән һәм Сөннәттә булган инануларның дәлилләре бик ачык, аз гына булса да сарыф (морфология) һәм нәху (грамматика) белгән шәкертләр аңларлык дәрәҗәдә җиңелдер (дөрес тәрҗемәләре белән мәктәп шәкертләре һәм башлангыч сыйныфлар да белерлектер).

Инануларны белгәннән соң, хөрмәтле Рәсүлебездән һәм аның сәхабәләреннән — фикердәшләреннән мирас булып калган башка гыйлемнәр өйрәнелер. Аерым алганда, Рәсулулланың (Аңа Аллаһының хәер догасы һәм сәламе булсын!) сиярен, ягъни туганнан башлап үлгән көненә кадәр булган хезмәтләрен уку тиешледер. Бу гыйлем исә, беренчедән, ислам мәхәббәтен урнаштырган өчен һәм, икенчедән, шәкертләрнең зиһеннәрен ачып нурландырган өчен, иң саф файдадыр. Сияр гыйлемен белгән кеше күңелендә, үзе дә һич сизмәстән, хөрмәтле Рәсүл — Пәйгамбәребезнең Аллаһы Тәгаләнең хак Рәсүле икәнлеге тәмам һәм ныклап урнашыр. Моннан соң үзенең башта дин кирәкләрен, аннан соң дөнья кирәкләрен (мәсәлән, хисап-арифметика, җәгърафия) — барысын да, вакыты һәм заманы белән өйрәнер.

## ИКЕНЧЕ ВАЗИФА (Ният)

Гыйлем өйрәнүдә булган кеше үзенең ниятен дөресләргә тырышырга тиеш. Ният — күңел эчендә булган фикер (уй) дип әйтүдер.

Гыйлем юлында йөргән, дәресханәләргә кергән шәкерт өчен бу ниятне дөресләү олуг бәхет булыр. Хөрмәтле Рәсүл әфәндебез (Аңа Аллаһының хәер догасы һәм сәламе булсын!): «Гамәлләрнең саваплары ният бәрабәренә, ягъни нияткә күрә булыр»,— дигән. Һәм тагын: «Күп гамәл булыр, дөнья гамәле сурәтендә күренсә дә, изге ният булу сәбәпле, ахирәт гамәленнән исәпләнер һәм күп гамәл булыр, ахирәт гамәле сурәтендә күренсә дә, бозык ният булу сәбәпле, дөнья гамәленнән исәпләнер,— дип әйткән.

Ниятләре дөрес кешеләрнең гамәл дәфтәрләре күп гыйбадәт һәм олуг гамәлләр белән тулы булыр.

Шул сәбәпле укыганым һәм гыйлем өйрәнүем белән эчем һәм тышым нурлансын иде, беркадәр булса да наданлыгым кимесә иде, шулай ук башкаларга, аерым алганда, кавем һәм кабилә, мөселман кардәшләремә өйрәтсәм иде, хөрмәтле Рәсүлнең (Аңа Аллаһының хәер догасы һәм сәламе булсын!) кадерле юлына һәм шәригатенә хезмәт итсәм иде, Аллаһы Тәгалә хәзрәте биргән гакыл һәм сәламәтлек нигъмәтләренә гыйлемем булу сәбәпле шөкер итә белсәм иде, Аллаһы Тәгалә хәзрәте риза булырдай инану һәм гамәлләр белән дөньядан үтеп, әфәндебез хөрмәтле Рәсүлнең (Аңа Аллаһының хәер догасы һәм сәламе булсын!) яклавына лаек булсам иде», - дип ният итү (чын күңелдән фикерләү) һәрбер шәкерт өчен тиешле булыр. Моның нәтиҗәсе исә «Аллаһы Тәгалә хәзрәтенең ризалыгын тапсам иде»,— дип әйтүгә кайтып калыр.

Чөнки Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы ният ителмәгән гыйлем — файдасыз гыйлемдер. Файдасыз гыйлем исә әрәм бәр нәрсәдер. Хөрмәтле Рәсүл әфәндебез (Аңа Аллаһының хәер догасы һәм сәламе булсын!) файдасыз гыйлемнән күп мәртәбә сакланган.

Гыйлемем сәбәпле олуг һәм хөрмәтле кеше булып та, халык арасында кадерем югары булсын, сүзем дә йөрсен һәм шул сәбәпле дин юлында хезмәт итсәм иде, дип ният итү дә дөрес, диләр.

Гыйлем өйрәнүдән төп максат исә — белеп гамәл итүдер. Гамәл кылырга сәбәп булмаган гыйлем белән файда алырга мөмкин булмаган хәзинә — икесе бер дәрәҗәдәдер. Хәтта ки: гамәлсез гыйлем Аллаһы Тәгалә хозурында бәндәнең үз зарарына дәлил булыр, диләр.

Ләкин, ниятне дөресли алмыйм, дип гыйлем юлыннан чыгу һәм өйрәнүдән туктау да дөрес түгел. Бәлки уку, кирәк — ният дөрес булсын, кирәк — ният дөрес булмасын, шикксез — тиешледер. Әгәр дә: «Хәзер дә ниятне дөресли алмасам да, бәлки киләчәктә Аллаһы Тәгалә хәзрәтенең мәрхәмәте булыр, дөреслармен»,— дигән фикер күңеленә төшә башласа, нәкъ үзе — ният дөресләү булыр.

Хәбәрләрдә: «Бер кеше — гәрчә бозык ният белән гыйлем өйрәнгән булса да, бер хасил булганнан соң, бу кешенең ниятен гыйлем үзе дөресләр»,— дигән сүз килеп җитте. Олуг галимнәрнең берсе булган Мөҗаһид хәзрәтләре: «Гыйлем өйрәнгән вакытыбызда, әйтерлек яхшы ниятебез юк иде, Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре соңыннан ният дөресләүне насыйп итте»,— дигән. Шулай ук Суфиян Сәүри хәзрәтләре: «Гыйлемне Аллаһы Тәгаләдән башка нәрсә өчен өйрәнгән идек, ләкин гыйлем безне бу ниятебездән кайтарды, бәлки, мин — Аллаһы Тәгаләдән башка зат өчен булырга риза булмыйм, дип безне үзенә ияртте (ният дөресләнде, дияргә телидер)...» —дигән.

Моның кебек эшләр әүвәлге заман кешеләренә яки бик аз кешеләргә генә булса-булыр, дип үз-үзен кимсетергә дәлил юктыр. Бәлки әүвәлге заманда булган кебек, хәзерге заманда да булыр. Элеккеге хәлебездә ниятебез бозык иде дә, соңыннан дөресләнде диючеләр аз булса да, сөйләмәгәннәре яки сөйлә-сәләр дә сүзләре безгә җитешмичә калганнары бәлки сансыз күптер.

Кирәк — әүвәл заманда булсын, кирәк — соңгы заманда булсын, Аллаһы Тәгалә хәзрәтенең рәхмәтеннән өметсез тору _ олуг гөнаһтыр. Чөнки аның рәхмәт ишекләре ачык, һәм мәр. хәмәт кояшлары һәр урынга һәм һәркем өстенә төшәдер.

Бу сүзләрдән максат исә — гыйлем өйрәнү вакытында ният дөресләү өчен тырышу, көтмәгәндә дөресләнүебез исә — кайчан булса да бер дөресләнүне өмет итеп, һаман тырышлык һәм мәхәббәт белән уку, өйрәнү тиеш икәнлекне белдерүдер.

Бозык ният белән наданлыкны каршы куйсак, наданлыкның зарары күп мәртәбәләр артык һәм көчле икәнлеге ачык булыр. Гакыллы кешеләр: «Ике зарар очраса, җиңелрәген сайлау тиешле булыр»,— диләр.

**ӨЧЕНЧЕ ВАЗИФА (Остаз сайлау)**

Шәкертләр өчен остаз сайлаган вакытта, тәкъва (диндар), олырак яшьтәге, күркәм холыклы, пакь нәселле, йомшак сүзле, сабыр, тирән гыйлемле, мәрхәмәтле, комсыз булмаган, шәфкатьле остазны табарга тырышырга кирәк. Әгәр дә моның кебек кеше табылмаса, табылган кадәрле дә ярап торыр. Кешенең үзеннән элек остазын сорарлар һәм остазына карап та мөгамәлә кылырлар.

Әбү Хәнифә хәзрәтләре (Аллаһы аннан риза булсын!) күп фикер (уй) соңында, остазлык өчен Хаммад хәзрәтләрен сайлагандыр. «Хаммадның гыйлеме күп иде, үзе — йомшак кеше, горур һәм сабыр кеше иде, шуның өчен аны остаз итеп, янында даими булдым, гыйлемнән дә өлешемне алдым»,— дигән.

Югарыда әйткәнебезчә, камил остазга туры килү насыйп булса, аны хөрмәтле тоту һәм һәр эшендә аңа киңәш кылып һәм аның ихтыярына карап мөгамәлә кылу тиешле булыр. Аерым алганда, дәрес һәм китапларны сайлауда, аның фи-керенчә булу тиештер. Аның өчен тәҗрибәле булган остазлар һәр гыйлемгә лаек булган шәкертне һәм һәр шәкерт өчен яраклы булган гыйлемне белерләр. Мөхәммәд бине Исмәгыйль әл-Бохари хәзрәтләре, гыйлем өйрәнү өчен Мөхәммәд бине әл-Хәсән (Аллаһы аннан риза булсын!) янына килеп намаз мәсьәләсен кабатларга башлаганда: «Синең табигатең — Хәдис гыйлеменә яраклы күренәдер»,— дип, Хәдис галимнәре янына җибәргән. Шул сәбәпле имам Бохари хәзрәтләре Хәдис гыйлемендә беренче дәрәҗәдә камил имам булган.

Галимнәрнең барысын да хөрмәтле тоту тиеш булса да, остазның хакы тагын башкалардан артыктыр. Шуның өчен остазны гыйззәтле-кадерле итеп белү һәм хөрмәтен камил саклау тиешледер. Хәзрәти Гали (Аллаһы аннан риза булсын!): «Мин — гыйлем өйрәткән кешенең колымын, теләсә — мине сатсын, теләсә — хезмәт иттерсен, теләсә — азат итсен!»— дигән.

Ата белән ана мәшәкать йорты булган бу дөньяга килергә сәбәпче булганнары хәлдә, остаз бәхет йорты булган оҗмахка барырга сәбәпче буладыр.

Остаз өчен яшерен дә һәм ачыктан-ачык та дога кылу тиеш. Әбу Хәнифә хәзрәтләре (Аллаһы аннан риза булсын!): «Хаммад вафат булганнан алып бу көнгә кадәр, укыган намазларым соңында Хаммад өчен, атам белән анам өчен, үземнән укыган шәкертләрем өчен, дога кылмыйча калмадым»,— дигән.

Шәкерт булган кеше остазының гайбәтен сөйләмәс, кеше сөйләсә дә, риза булмас, бер читкә китәр, кирәк булмаганда алдыннан йөрмәс, аның урынына утырмас, рөхсәтеннән башка янында сөйләшмәс, гореф-гадәтләргә каршы рәвештә ишекләрен тартмас, аның ачуыннан куркыр, гөнаһ булмаган эшләрдә кушканын җиренә җиткерер, балаларын һәм барлык якыннарын һәм дусларын хөрмәтләр һәм олылар. Әбу Хәнифә хәзрәтләре (Аңа Аллаһының рәхмәте булсын!): «Хаммадны хөрмәтләвем сәбәпле, аның ханәсе (йорты) тарафына аякларымны озайтмадым»,— дигән.

Шәкерт булган кеше мөмкин булган кадәр остазының хезмәтен үтәр. Казый Фәхреддин хәзрәтләре олуг галимнәрнең берсе иде, үзен шул замананың солтаны да хөрмәт итәр иде. «Бу дәрәҗәләрне остазымны хөрмәт итеп таптым, остазым Әбу Зәед әд-Дәбүсинең ашын пешерәдер идем һәм башка хезмәтләрен дә үтидер идем»,— дигән. Бохарада олуг галимнәрдән берсе мәчеттә шәкертләренә дәрес биргәндә кайбер сәгатьтә аяк өстендә тора икән. Шәкертләре тарафыннан бу хәлгә гаҗәпләнүне белеп: «Остазымның сабый баласы үзенең иптәшләре белән уйнап йөргәндә, кайвакытта мәчет янына киләләр, шул баланы күргәндә, остазымны олылап, аяк өстендә торам»,— дип, сәбәбен аңлатып биргән.

Сәдидеддин әш-Ширази исемле бер галим кеше: «Углым гыйлем әһеле булса иде, дигән кеше, гыйлем һәм өстенлек ияләрен хөрмәт итсен; ялгызларга һәм мосафирларга шәфкать һәм мәрхәмәт күрсәтсен; моның кебек кешенең углы галим булыр. Әгәр дә углы галим булмаса, углының углы галим булыр»,— дигән.

Хәзрәти Габдулла бине Габбас (Аллаһы аннан риза булсын!) галим сәхабәләрдән берсе булганы хәлдә, Зәед бине Сабит хәзрәтләренең атының тезгенен тотып торыр икән. Һәм дә: «Хөрмәтле Рәсүл олугларыбызга бу рәвештә хезмәт күрсәтергә боерыр иде»,— дигән.

Белмәгән нәрсәләрне (ислам динендә кирәкле булганнарны), өйрәтүче кеше, теләсә — олуг, теләсә — кечкенә булсын, теләсә — фәкыйрь, теләсә — бай булсын, өйрәнергә кирәк. Бу очракта гарьләнү дөрес булмас. Ләкин остаз ясар өчен югарыда әйткәнебезчә, саф күңелле, ике йөзле булмаган, дәгъвасыз, түзем, диндар кешене табарга тырышырга кирәк.

Бохарага укыр өчен барган бер шәкерт, Сәмәрканд шәһәрендә бер акыл иясе янына кереп, үзенең максаты хакында киңәш иткән. Акыл иясе исә бу шәкерткә: «Бохарага баргач ук дәрес башлавың ярамас, чөнки тиз арада бер кешене үзеңә остаз итсәң, ихтимал ки ул кешенең холкы һәм фигыле сиңа ошамас, аны ташлап китәргә мәҗбүр булырсың, остаз булган кешене ташлау күп вакытта гыйлемнән өлешсез калырга сәбәп буладыр, бәлки бер-ике ай кадәр торып, фикер һәм гакыл ияләренә киңәш итеп, шуннан соң остаз сайлап алуың бик яхшы булыр»,— дип, гүзәл киңәш биргән.

Гакыллы кешеләр: «Табибыңны рәнҗетсәң — шифа таба алмассың, остазыңны рәнҗетсәң — надан калырсың»,— дигәннәр.

## ДҮРТЕНЧЕ ВАЗИФА (Иптәш сайлап алу)

Шәкертләр дәресләрендә, тырыш, гүзәл холыклы, белгәне белән гамәл итүче, әдәпле һәм инсафлы иптәшләрне сайлап алып; кешедән көлүче, ялкау, күп сөйләүче, кеше арасын бозучы, яман эшләргә өйрәтүче кебек бозык холыклы иптәшләрдән бик ерак булырга тиешләр. Шәкертләрнең алга баруларында яки артта калуларында иптәшләрнең олуг тәэсире барлыгы мәгълүм.

Яхшы һәм тырыш иптәшләрне сайлап алу, шәкертләр өчен сабакташ һәм сыйныфташ булу мәсьәләсенә генә хас булмыйча, бәлки һәрвакытта тиешле һәм кирәкле бер кагыйдәдер. Чөнки бер кешенең нинди фигыльдә һәм нинди холыкта икәнлеген белергә теләк туса, иң элек ул кешенең үзеннән сорамыйча, бәлки кем белән иптәш һәм юлдаш икәнлеге тикшереләдер. Әгәр дә юлдашы яхшы булса — бу кешенең дә яхшылыгы белән, яман булса — моның да яманлыгы белән хөкем ителер.

Хикәят ителәдер: беркадәр халык, мосафир булып бер шәһәргә килгәч, шәһәр халкына: «Шәһәрегезнең яхшылары кемнәр дә, усаллары кемнәр икәнлеген ике көндә белеп бетердек, аның өчен безнең үз арабызда булган яхшылар белән усаллар үзебезгә мәгълүм иде. Боларның һәрберсе сезнең шәһәрегез халкыннан дуслар сайладылар. Әлбәттә, безнең яхшыларыбызның дуслары — яхшы һәм усалларыбыз-ның дуслары да үзләре кебек усаллар булса кирәк»,— дигәннәр.

Инде эш болай булганда, мин үзем яхшы булгач, иптәшем яманлыгыннан ни зарар булыр дип әйтү — ялгыш һәм тиешсез сүздер.

Яман юлдаш — тимерче уты мисалындадыр. Бервакытта очкыны төшеп киемеңне яндырыр.

Ахмак иптәшләрнең яманлыклары кадәр йогышлы һәм зарарлы нәрсә дөньяда юктыр. Гакыллы кешеләр: «Ахмакның юлдашлыгына сабыр иткән кеше дә — ахмактыр», — дигәннәр. Малик бине Динар хәзрәтләре янында бер эт барлыгын күргән кешеләр бу хосуста үзеннән сораганнар. Боларга җавабында: «Бу — эт түгел, ә яман юлдаш һәм ахмак иптәштән яхшырак иптәш»,— дигән. Күп сөйләүче иптәшләр дә — гомер ашаучылар, вакыт исраф итүчеләрдер. Бүлмәдән бүлмәгә, кешедән кешегә йөреп сүз сөйләп йөрүчеләр мәктәп һәм шәкертләр өчен күк казасы, җир бәласе булыр. Мондый шәкертләрнең зарары барлык гыйлем өйрәнүчеләргә ирешәдер.

Күп сөйләүчеләрне борынгы бабаларыбыз бер дә сөймәгәннәр. Агъмыш хәзрәтләре: «Без шундый кавемнәрне күрдек ки, айлар буенча күрешми торганнары хәлдә очрашкач: «Хәлегез ничек? Яхшы!..» — диешеп, сүзләре бетәр иде, әмма мал кирәк булса — шул сәгатьтә ярты байлыкларын бүлеп бирүдән һич курыкмаслар иде. Әмма бу көндә булган кавемнәрне күрәбез, бер көн торып кына очрашканнары хәлдә, хәтта тавыкларының исәнлекләренә кадәр сорашалар, көтмәгәндә араларында мал кирәк булу мәсьәләсе чыкса, бер орлык бирергә кулларыннан килмидер»,— дигән. Аллаһы Тәгалә Агъмыш хәзрәтләренә рәхмәт итсен! Әгәр дә безнең бу заманыбызны һәм бу холкыбызны күрсә — ни әйтер иде икән?.. Ялкау белән иптәш булган кеше дә үзенең максатына ирешүдән мәхрүм калыр. Әбүбәкер әл-Харәзми хәзрәтләре: «Һичвакытта ялкауларга юлдаш булма! Аның өчен күп яхшы кешеләр булыр, юлдашларының бозыклыгы сәбәпле яман булырлар. Ахмак кешенең ахмаклыгы, гакыллы һәм аңлы кешегә тиз авышыр. Утлы күмерне көлгә салсаң, шул вакытта ук сүнәр»,— мәгънәсендә бер шигырь сөйләгән, һич шөбһә юктыр ки дигәннәре бик дөрес.

Әгәр дә Аллаһы Тәгалә яхшы һәм аңлы, диндар һәм итагатьле иптәшләр һәм сыйныфташлар насыйп итсә, моны олы бәхет дип белергә кирәк. Ьәм мондый сабакташларны остаз һәм укытучылар рәвешендә хөрмәтләргә һәм хәтерләрен сакларга кирәк. Һәрбер мөселманның хәлен аңлауга шәригать боерса да, мондый сабакташларны барлык кешедән артык күрергә, аларга һәрвакытта хәер-дога һәм күркәм мөгамәләдә булырга кирәк.

**БИШЕНЧЕ ВАЗИФА (Буш вакыт. Ялгызлык — Тынычлык)**

Гыйлем алу өчен ялгыз булу, ягъни мөмкин кадәр дөнья мәшәкатьләреннән бушану кирәк. Туган-үскән җирләр, дус-ишләр күп вакытта күңелне мәшәкатьләндергәннәре өчен, болардан аерылып ерак урыннарга китү һәм күп кайтып-ки-леп йөрмәү файдалыдыр. Шул сәбәпле шәкерт вакытта хатын алу да ярамыйдыр.

Бәндәләрдә ике күңел булмау сәбәпле, бу рәвештә дөньяга бәйләнүнең гыйлем өйрәнү өчен олуг зарары барлыгы билгеледер. «Үзеңне бөтенләй аңа тапшырмыйча торып, гыйлем сиңа үзеннән бераз гына булса да өлеш бирмәс»,— диләр.

Күңелне төрле урыннарда йөртү, гыйлем мәсьәләсенә карамаган нәрсәләр белән күп шөгыльләнү, онытучанлыкны барлыкка китергәне өчен, мондый хәлләр шәкерт өчен дә файдасыздыр.

Гыйлем өйрәнү өчен ерак урыннарга сәфәр итү һәм мосафирлыкларны сайлау иң кирәкле гамәлләрдән була, диләр. Имам Шәгъби хәзрәтләре: «Бер кеше көнчыгыштан көнбатышка сәфәр итсә, шул озын сәфәрендә шәригать мәсьәләләреннән бер генә мәсьәләне белеп килсә дә, бу кешенең сәфәре әрәм булган дияргә минем кодрәтемнән килмидер»,— дигән.

## АЛТЫНЧЫ ВАЗИФА (Тырышлык)

Гыйлем өйрәнүче шәкертнең бик тырыш булуы кирәк. Тырышлыктан башка дөнья малы да табылмас. Инде ахирәт малы да һәм дөнья малы да булган гыйлем тырышлыктан башка ничек табылыр?.. Тырыш кешеләр теләкләренә ирешерләр. Бикле ишекләр тырыш кешеләргә ачылыр, диләр.

Әбу Йосыф хәзрәтләре: «Углым вафат булды. Кабер казы-тып, җиһазлап күмеп йөрсәм, Әбу Хәнифәнең мәҗлесеннән калырмын, дип куркып, углымны җиһазлап күмү хезмәтен бер кешегә тапшырдым да үзем Әбу Хәнифәнең дәрес мәҗлесенә киттем»,— дигән. Шәкертләр өчен Әбу Йосыф хәзрәтләренең бу чыдамлыгы һәм тырышлыгы күчергеч һәм гыйбрәт булырга яраса кирәк.

Гыйлем өйрәнер өчен шәкерт тырышлыгы, остаз тырышлыгы, ата яки тәрбиячәнең тырышлыгы кирәктер. Бу өч тырышлык бергә җыелса, бертөрле җимеш булмыйча калмас.

Тырыш шәкертләр төннәрен дә гадәттән тыш озак йокламаслар. Чөнки үзе йоклаган кешенең бәхете дә йоклар, диләр. Юрган астында ятып гыйлем өмет иткән кеше, чәчмәгән җиреннән иген өмет иткән кебек, гомерен әрәм итеп буш фикер белән уздырган булыр. Кичләрен гадәттәгечә генә йоклаган кешенең көндез дә күңеле хуш булыр, һәм һәр эше дә рәхәтләнеп барыр. «Бу гыйлемне ничек өйрәндең?» —дип сораучыларга олуг акыл ияләренең берсе: «Кичләрен яндырып бетергән майларым эчкән суларымнан артык булды»,— дип җавап биргән.

Тырышлык дип шәкерт үзенең гакыл һәм фикеренә, шулай ук тән әгъзаларына зарар китермичә, яхшы гына тәртип белән укуга әйтәләр. Бу билгеләмәдән чыгып карасак, шәкерт үзенең сәламәтлегенә зарар китерерлек рәвештә укыса, ул тырышлык түгел, бәлки үзен харап итү һәм гаделсезлек булыр. Шулай булгач, ислам шәригате һәрвакытта гаделлекне иң алга куя.

Хөрмәтле Рәсүл әфәндебез хәзрәтләре (Аңа Аллаһының хәер догасы һәм сәламе булсын!): «Бу ислам дине — ныклы бер диндер, анда гаделлек белән хәрәкәт итегез! Үзегезне дошман күрсәтер дәрәҗәгә җиткереп, нәфесегезне газапламагыз, аның өчен арыган (көчсез калган) хәлендә йөрергә теләгән кеше максатына җитә алмас, атланган атын да сәламәт калдырмас», — дигән. Икенче бер изге хәдистә: «Нәфесең — атланган атыңдыр, аңа һәрвакытта шәфкатьле бул!» — дигән. Хөрмәтле Рәсүл әфәндебезнең (Аңа Аллаһының хәер догасы һәм сәламе булсын!) шул сүзләре һәрвакытта кагыйдә һәм үлчәү

булырга тиешледер. Бәлки «тырышлык» дип әйтү, югарыда әйтелгәнчә, «тәртип белән өйрәнү, кабатлау, аңлау, сорау бирү, файдалану, канәгатьләнү белдерү» дип әйтү булыр.

Күңелдә яхшы урнашып калсын өчен, дәресләрне кат-кат (кабатлап) уку да тиешле буладыр. Элекке заман галимнәре дәресләрне кабатлату мәсьәләсендә бик игътибарлы булырлар иде. Хәтта ки бүгенге сабакны кабатлату белән генә калмыйча, үткән кен сабакларын да бер кагыйдә буенча кабатлатырлар и:и\ Зәрнүҗи хәзрәтләре: «Үткән сабакны — биш мәртәбә, аннан әүвәлгесен — дүрт мәртәбә, аннан әүвәлгесен — өч мәртәбә, аннан әүвәлгесен — ике мәртәбә, аннан әүвәлгесен бер мәртәбә кабатлауга гадәтләнергә кирәк»,— дигән.

Сабаклар, никадәр кабатланса да, аңлашылмас — файдасыз калыр, шул сәбәпле дәресләрне аңларга тырышу тиешледер. Аз дәрес тә аңлашылса күп булыр. Бүгенге дәрес яхшы аңлашылса, иртәгә буласы дәресләрдән күп нәрсәләр үз-үзеннән беленер. Элекке галимнәр: «Ике хәрефне ятлау ике йөк китап тыңлаудан яхшырак»,— дигәннәр икән. Шуның өчен үзенә бирелгән сабакны кабатлау һәм аңлап кую беренче дәрәҗәдәге кирәкле эш булыр.

Белмәгән яки шикләнгән урыннары калса, остаз һәм укытучылардан, хуҗа һәм хәрефләрдән, яки үзенең иптәш һәм сыйныфташларыннан һәм башка белүчеләрдән сорап аңлау тиешле булыр. Болай итү, гыйлемнең урнашып, нык булып калуына сәбәп булган тәҗрибә белән билгеле булган. Шулай ук үзе белгәннәрне икенче бер белмәгәннәргә өйрәтү, арада һичбер белмәгәннәре булмаганда да, тагын бергә-бергә җыелышып кабатлау, сөйләшү — бик файдалы эштер.

Сораганнарны яшерү, сораудан оялу — шәкертләр өчен олуг гаептер. «Бу гыйлемне ничек таптың?» —дип сораучыларга Әбу Йосыф хәзрәтләре: «Кызганмадым — өйрәттем, оялмадым — сорадым»,— дигән. Шулай ук бу рәвештә сораучыларга Ибне Габбас хәзрәтләре (Аллаһы аннан риза булсын!): «Күп сораучы — тел, күп аңлаучы күңел белән таптым»,— дип җавап биргән. Имам Хәлил хәзрәтләре дә: «Гыйлемлелек — бикле булган хәзинә, аның ачкычы исә — сораудыр»,— дигән.

Ләкин сөйләшү бакалар мисалында шаулашу, ишәкләр рәвешендә акырышу, исерекләр кебек җәрәхәтле сүзләр сөйләшү, кулларны бутаудан гыйбарәт түгелдер. Гакыллы кеше мондый хәлләргә һичбер вакытта төшмәс. Бәлки сөйләшү дип, гаять тә әдәп һәм тәрбия белән һәркем үзенең күңелендә булган фикерне иркенләп, ачык итеп сөйләүгә, бер кеше сөйләгән вакытта һичкем катышмыйча, Изге Коръән тыңлаган рәвештә тыңлап торуга, соңыннан арадан бер күп белүчесе барлык кешенең сүзләрен җыеп, арадан дөресен табуга әйтеләдер. Монда исә шауларга нинди ихтыяҗ бар да, кычкырышырга нинди юл бар?! Әгәр дә мәҗлестә моның кебек әдәпсез эш килеп чыкса, ул мәҗлестән ерак тору тиеш булыр. Чөнки мондый мәҗлеснең соңгы дошманлыктан башка нәрсәсе булмас. Белгән нәрсәләр өчен кутәрелмичә (тәкәбберләнмичә), бәлки, Аллаһы Тәгалә хәзрәтенең мәрхәмәте белән насыйп булды, дип әйтә белергә һәм хәле җиткәнчә Аллаһы Тәгалә хәзрәтенә шөкер итәргә тиешле булыр. Әбу Хәнифә хәзрәтләре: «Нинди генә нәрсә белсәм дә, шатланып Аллаһы Тәгаләне мактау сүзләре әйтер идем, шуның бәрәкәтендә бу гыйлемне таптым»,— дигән.

Шәкертләрнең Аллаһы Тәгалә хәзрәтенә күп шөкер итүчән булулары, шулай ук өйрәнгән гыйлемнәреннән үзләре дә: «Кавем һәм милләтләре өчен файда булсын иде!» — дип дога кылырга гадәтләнүләре, алган гамәлләренең файдалы булачагына бер сөенечле билге булыр.

Гыйлемлелекнең яхшы саклануы өчен, һәрвакытта янында китаплар һәм дәфтәрләр булу ихтыяҗы бар. Шуның өчен тырыш шәкертләр, ничек булса да, үз китапларыннан укырга һәм укыган китапларын үз милекләрендә булдырырга тырышырлар. Кеше китабыннан уку — бик яраклы түгелдер. Китап җыю, үзе укыган китапларны яхшы саклау — гыйлемгә мәхәббәтле булуга дәлилдер. Имам Мөхәммәд хәзрәтләре әүвәл хәлендә олуг байларның берсе иде, өч йөз җан вәкил һәм хезмәтчеләре генә булган. Шул зур байлыкны гыйлем юлында сарыф итеп бетергән.

Шулай ук тырыш шәкертләр һәрвакытта һәм һәркемнән аз-аз булса да өйрәнү теләгендә булырлар. Тамчы-тамчы күл булыр, дигән кебек, азлап җыелган гыйлем соңрак күп булыр. Әбу Хәнифә хәзрәтләре Хаммад янына шәригать кануннары укырга баргач, остазы булган хәзрәти Хаммад: «Һәр көнне өч мәсьәләне белсәң — ярар. Аннан арттырма!»— дип боерган. Остазы кушканча, һәр көнне өч кенә мәсьәлә белеп, ахырында Әбу Хәнифә хәзрәтләре заманасында беренче галимнәрдән булган. Аз булсын да беленсен, диярләр. «Кызу йөргән — арыр, акрын йөргән — барыр» дигән сүзләр — мәшһүр сүзләр.

Гыйлем һәм өстенлек әһеле белән танышу һәм аларның мәҗлесләрендә булу — олуг бәхеттер. Борынгы бабаларыбыздан бер хөрмәтле зат: «Күп галимнәрне күргән идем, ләкин алардан өйрәнергә гакылым җитмәде»,— дип кайгырып сөйләгән икән.

Һәм тагын бүген беленергә тиешле сабакны иртәгә калдырмау — гыйлем өйрәнүнең олуг шартларының берседер. Чөнки һәр көн өчен үзенә хас дәрес һәм шөгыль була. Әүвәлге заманның шәкертләре бүгенге дәресләрен иртәгәгә калдыруны һич дөрес санамаганнар, бәлки мөмкин булса, иртәгә буласы дәресләрен дә бүген белергә тырышканнар.

**ҖИДЕНЧЕ ВАЗИФА (Гыйлемне хөрмәтләп тоту)**

Гыйлем өйрәнүче шәкерт гыйлемгә бик мәхәббәтле булыр һәм аның бик хөрмәтле бер камиллек икәнлеген аңлар. Шуның өчен көче җиткән кадәр хөрмәтләп тотар. Бу сүзне меңенче мәртәбә ишетүендә әүвәлге мәртәбә ишетүе кебек теләк һәм ихлас белән тыңламаган кеше гыйлем әһеле түгел, диләр.

Малик бине Әнис хәзрәтләре дәрес вакытларында, гыйлемне олылау нияте белән тәһарәт алыр, сакалын тарар, урынында тезләнеп утырыр һәм соңыннан дәрес башлар иде. Хөрмәтле Рәсүл әфәндебез (Аңа Аллаһының хәер догасы һәм сәламе булсын!) хөрмәтен саклап тавышын күтәрмәс иде. Шуның өчен шәкертләргә, бигрәк тә дәрес вакытларында, китап һәм кәгазь тоткан заманнарында тәһарәтле булырга, баш, кул, кием-салым саф һәм пакь булырга тиеш.

Остаз һәм укытучыларны, кем булса да булсын, гыйлем әһелен һәм үзеңнән күп белүчеләрне олылау, Изге Коръән һәм шәригать китапларын, кәгазьләрен хөрмәтләү гыйлемне хөрмәтләү буладыр...

Шәригать китаплары хөрмәтле булган өчен, кирәге булмаганда аның өстенә башка нәрсәләр кую һәм аның тарафына аяк сузу, Коръән тәфсире, хәдисләр кебек хөрмәтле китаплар өстенә башкаларны кую, кыскасы, гореф-гадәттә әдәпсез күренгән нәрсәләрне кылу олы гаеп саналыр.

**СИГЕЗЕНЧЕ ВАЗИФА (Үҗәтлек һәм түземлек)**

Кошлар — канатлары белән очканда, кешеләр тырышлык, үҗәтлек белән очалар. Тырышмаган кешеләр күзенә кечкенә нәрсәләр олы булып күренгәндә, тырыш, үҗәт кешеләргә бик олы эшләр дә кечкенә күренер. «Ирләрнең тырышлыгы тауларны кубарыр»,— диләр.

Гыйлем юлы — бер кадерле юлдыр, ләкин бик мәшәкатьле һәм авырдыр. Шулай булса да, очы — бәхеткә, ахыры камиллеккә барып туктыйдыр. Шуның өчен бу юлга кергән шәкертләр дә тырыш һәм шат, тырыш һәм чыдам, көчле һәм нык булырга тиешле. Гыйлем ләззәте кадәр ләззәт һичкемдә, һичбер урында һәм һичбер вакытта булмас. Юлда булган михнәтләр һәр никадәр көчле булса да, баһадир гаскәр кебек күкрәге белән каршы торган шәкертләрнең чыдамлыкларына каршы тора алмас, җиңелер.

Имам Мөхәммәд хәзрәтләре кичләрен тырышып мәсьәлә чишкәннән соң: «Падиша балалары бу ләззәттән мәхрүмнәр!..» — дип әйтә торган булган. Әбу Йосыф хәзрәтләренең бик рәхәтләнеп һәм ләззәтләнеп гыйлем өйрәнүдән соң аны кабатлавын күргән бер якыны үзенең иптәшләренә: «Гыйлем юлында дөньясын оныткан! Шулай булса да, аның биш көннән бирле карыны ач икәнлеген мин беләм!..» — дигән. Тырышлык менә шулай була, чыдамлык менә шулай була...

Ата-ананы, туган-үскән урыннарны, кардәш-кабиләләрне калдырып ерак урыннарга китеп гыйлем өйрәнү, мәктәп һәм мәдрәсә тәртипләренә һәм башка михнәт һәм авырлыкларга сабыр итү, нәфес-теләкләреңнән үз-үзеңне саклап тоту — барысы да тырышлык буладыр.

Бер шәкерттә тырышлык булса, аның гыйлем өйрәнүенә бөтен дөнья тырышса да киртә була алмый, тырышырга гадәтләнгән шәкертнең киләчәк бер көндә олы бер зат булачагында һич шикләнмәгез!..

Гыйлем өйрәнүгә киртә булган нәрсә — фәкыйрьлек түгел, бәлки тырышмаудыр. Тырыш булган шәкертләр өчен бүгенгә кадәр фәкыйрьлек киртә була алмады. Моннан соң да булмас.

Дөньяның иң мәшһүр затлары һәм иң бөек галимнәре фәкыйрьлек галәменнән калкып чыктылар. Әбу Хәнифә хәзрәтләре үзенең шәкерте Әбу Йосыфка: «Зирәк түгел идең, ләкин тырышлыгың сәбәпле бу дәрәҗәгә ирештең»,— дигән.

Әй кадерле шәкертләр!!! «Укыганыбыз ярар, никадәр тырышсак та, артык кеше булырга кодрәтебез җитмәс»,— дигән кебек хурлыклы фикердә булмагыз! Бәлки бөек

табигатьле, үткен, тырыш булыгыз! Түземлек-чыдамлык булгач, артык һәм зур галим булуга һич киртә юктыр. Аллаһы Тәгаләнең сер һәм хикмәтләренә гакыллар ирешмәс, мәрхәмәте дә шулкадәр олыдыр. Бөтен дөньяга дәрес бирүдә булган һәм исемнәре Кыяматкә кадәр калган галимнәрне сезнең кебек шәкертләр арасыннан дөньяга чыгарган. Киләчәктә, Аллаһы боерса, тарих белән таныш булырсыз һәм шул вакытта бу сүзнең дөрес икәнлеген ачык белерсез. Хөрмәтле Рәсүл әфәндебез хәзрәтләре (Аңа Аллаһының хәер догасы һәм сәламе булсын!): «Аллаһы Тәгалә эшләрнең бөекләрен яратадыр, түбәннәрен дошман күрер»,— дигән. Рәсүлебез болай әйткәндә, гыйлем өйрәнү вакытында үзебезне кимсетеп, ялкаулыгыбызны пәрдәләр каплар өчен төрле сәбәпләр күрсәтеп торуыбыз һич дөрес булмас.

Шәех Җәмаледдин хәзрәтләрен Мисырдан чыгаргач, янында бер тиен акчасы һәм бер ашарлык нәрсәсе юк икәнен белеп, Сүәештә булган шийгалар (персияннар) (иранлылар. — Ә.Х.), бер кадәр акча җыеп, пароходка кереп: «Бу акчаны бүләк итәбез, әгәр дә бүләгебезне кабул күрмәсәгез — бурыч итеп алыгыз һәм кирәк әйберләрегезгә сарыф итегез!..» — дигәч, «Бу акчага сез миннән мохтаҗраксыз, үзегездә калсын, карчыга һич вакытта чыпчык авызыннан корт алмас, арыслан сунар табудан гаҗиз калмас»,— дигән. Мондый тырыш кеше, иске замана галиме булмыйча, бәлки хәзерге заманыбыз ирләреннән иде.

Шулай ук гаҗәп тырыш галимнәр бүген ислам мәмләкәтләрендә дә юк түгел. Бәлки үз мәмләкәтебездә дә күчергеч булырлык затлардан ике-өч данәсен яхшы беләбез. Әгәр дә ишетсәк — исемнәрен дә язар идек.

Шул сәбәпләр өчен, шәкертлек заманасын олы бәхет дип белеп, Аллаһы Тәгаләнең чиксез рәхмәтләреннән өметсез булмыйча, бер файдалы кеше булып җитешүне теләп, көннән-көн түземлекне һәм үҗәтлекне арттыру тиеш булыр. Шуның өчен шәкертләрнең ялкау булуыннан гына түгел, бәлки ялкаулык китерә торган сәбәпләрдән дә (мәсәлән, күп ашау, күп эчү кебек эшләрдән дә) сакланырлар. Ялкаулык — дөнья һәм ахирәттә хәерсез бер нәрсәдер. Аллаһы Тәгалә Үз өстенлеге һәм мәрхәмәте белән моннан сакласын!

Кырмыскаларда булган тырышлык, бал кортларында булган түземлек белән булдыру-казану күренеп торганда, бәлки бал кортлары үзләренең көчләре белән бу кадәр көч куеп адәм баласы файдалансын өчен тереклек иткәндә, Аллаһы Тәгалә тарафыннан гакыл нигъмәте белән хөрмәтләнгән адәм баласының үз җенестәшләренә аз булса да файда китермичә торуы яки файда китерер өчен тырышмавы кайсы гакыллар каршында дөрес күрелер?!

## ТУГЫЗЫНЧЫ ВАЗИФА (Гыйлем өйрәнүнең яраклы вакытлары)

Адәм баласы өчен гыйлем өйрәнү вакыты бишектән ләхеткә кадәрдер, ягъни һичкем һичбер вакытта гыйлемне кирәксенмичә тормас. Шуның өчен көчле бер кирәклек булмаганда: «Укыганым җитәр!» —дип, гыйлемнән күңелне алу ярамас. «Кайчанга кадәр гыйлем өйрәнәсең?» — дип сораучыларга Габдулла бине әл-Мөбарәк хәзрәтләре: «Кем белер? Бәлки үзем өчен файдалы булачак гыйлемне һаман ишеткәнем юктыр, шуны ишетү өмете белән һаман гыйлем өйрәнүдә булуым кирәктер»,— дип җавап биргән. Хәсән бине Зияд хәзрәтләре дә кырык яшендә вакытында гыйлем өйрәнүгә керешкәндер.

Шулай булса да гыйлем өйрәнү өчен шәкертлек, яшьлек, бигрәк тә сабыйлык чаклары — иң яраклы вакытлардыр. Яшьлектә алынган гыйлем ташка казылган бизәк мисалында бетмәс, онытылмас. Бу вакытларны бәхет дип белергә кирәк, яшьлек заманасы гомергә бер генә килер, ләкин бу кадерле һәм хөрмәтле сәгатьләр озак тормас, китәр.

Әмма заманнар арасында гыйлем өйрәнү өчен яраклы булганнары — кичләр һәм таң вакытлары, шулай ук, тавыштан һәм кешеләрдән аулак вакытлардыр.

**УНЫНЧЫ ВАЗИФА (Китап, ягъни язу яза белү)**

Яза белү — олы бер һөнәр булуыннан башка, шәригать гыйлемнәрен соңгы буыннарга калдырырга сәбәп булганы өчен, саваплы бер гамәлдер. Язу өйрәнүне Аллаһы Тәгалә хәзрәте Изге Коръәндә дә йөкләгән. Кайбер хәбәрләрдә «Шәһитләрнең каннары, галимнәрнең каралары кыямәт көнендә үлчәнер. Ләкин галимнәрнең караларына булган саваплар артык булыр»,— диелгән.

Шуның өчен шәкерт вакытта, бигрәк тә сабый вакытта, бу һөнәрне белергә кирәк! Башлап укырга керешкәч тә, һәр укыган хәрефне яза белү һәм һәр яза белгән хәрефне укый белү бик файдалыдыр. Китаплар күчереп язганда (шулай ук бастырган вакытта) эре каләм, эре хәреф белән яхшы кәгазьгә, читләрен иркен калдырып язу (яки бастыру), шулай ук хат җибәргән вакытта кыска гына сүзләр белән максатны ачык аңлата белү — язу гыйлемендә олы бер әдәп, олы бер камиллектер. Имам Хәлил нәзек, ягъни басымсыз каләм белән нечкә итеп язучыны күргәндә: «Әй туганым! Дөньяда бераз булса да гомер сөрергә өметең юкмы әллә?!»— дип әйткән. Әбу Хәнифә хәзрәтләре нечкә язучыны күргәндә: «Гомерең озын булса — үкенерсең, вафат булсаң — рәхмәт ишетмәссең!» — дигән. Шулай ук Габдулла бине әл-Мөбарәк хәзрәтләре: «Нинди генә язуны күрсәм дә, сүзеннән, чагыштыру белән язучысының гакылы нинди дәрәҗәдә икәнлеген аңладым»,— дигән. Язуны (почеркны) төзәтү, гарәпчә сүзләрнең ноктасыз һәм ноктали хәрефләрен аеру бик кирәк. Бу заманда гәрчә Ибне әл-Мөбарәк хәзрәтләре булмаса да, кем белер? Бәлки Аллаһы Тәгаләнең олуг дәрьясыннан башкалар килеп чыгар. Язуларны һичкем күрмәсен, дип фараз итик, шул вакытта да дөрес язылуы һәм гореф-гадәткә яраклы булуы тиештер.

Кәгазь, кара, каләм, кара савыты, пәке, карендәш каләме һәрвакытта шәкертнең үз янында һәм үз милке булырга тиешле. Бу нәрсәләрне үзеңдә булдырмау — һөнәрсезлек һәм ахмаклыктыр; әмма кешегә ышану һәм кешедән сорап йөрү — олуг гаеп һәм хурлыктыр. Хәтта ки кесәдә карендәш каләме белән бер кечкенә дәфтәр (хәтер дәфтәре) булдыру бик яхшыдыр. Чөнки кайбер йөргән вакытларда күңелгә гүзәл нәрсәләр төшәдер. Әгәр дә шул минутта язып, билгеләп куймасаң, хәтердән чыга һәм икенче мәртәбәдә күңелгә килми каладыр. Шулай ук мәҗлесләрдә һәм башка урыннарда ишетелгән, теләп алынган һәм файдалы нәрсәләрне тиз генә вакытта әлеге дәфтәргә язу мөмкин булыр. Соңыннан һәр көнне, кич яки форсат булган вакытта әлеге дәфтәр ачылып, һәр билгеләр хакында тиешле тикшеренүләр ясау һәм кирәкле эшләрне эшләү тиешле булыр. Гыйлемлек исә шулай артыр һәм үрчер.

Шул сәбәп өчен «Каләмнән аерылма! Яхшылык исә — Кыямәт көненә кадәр каләм әһелендәдер» һәм тагын «Кулында дәфтәр булмаган кешенең күңелендә хикмәт тормас» дигәннәр. Ишеткән гыйлемнәремне онытам, дип зарланган бер сәхабәгә хөрмәтле Рәсүл

хәзрәтләре (Аңа Аллаһының хәер догасы һәм сәламе булсын!): «Уң кулыңнан ярдәм сора!..» — дигән. Ягъни язып куй дигәнне аңлатадыр. «Искә алынган нәрсәләр бер вакытта онытылыр, әмма кәгазьгә язылган югалмас»,— диләр.

Яза белү олы бер өстенлек булган кебек, аны куллана белү дә — олы бер һөнәрдер. Куллана белү исә дөнья һәм дин кирәкләре өчен гамәлгә кую дип атала. Әмма бер кешене мәсхәрәләп язу яки хурлау, яла ягу яки берәү өстенә ялган гаеп ташлау юлында каләм йөртү — шәригать каршында олуг гөнаһ һәм гаептер. Бу эшләр исә шәкерт чагында тиешле тәрбияне алудан мәхрүм калган кешеләрдә күп булыр.

Бер кешенең халык алдында йөзен кызарту дин һәм гадәт каршында тәрбиясезлек, явызлык һәм яманлык дип исәпләнгән хәлдә, кәгазьләргә язып та ахирәт көненә кадәр киләчәк халыкларга фаш итүнең нинди дәрәҗәдә бозык эш икәнлеге үз-үзенә мәгълүм булыр.

Кәгазьгә язу белән эш тәмам булса, ни булса да булыр иде, ләкин бөтен гыйлемнәрне, шулай ук никадәр булса да барлык язганнарны бөтен мәхшәр халкы каршында укылачак бер көн бардыр. Гайбәтләре язылган, ялалар ягылган кеше килеп, шул вакытта Аллаһы Тәгалә янында дәгъвасын кылса, ни аны сакларлык бер адәм булмас һәм ни качачак бер урын табылмас!.. Бу хикмәт өчен «Кыямәттә укырлык булмаган нәрсәләрне дөньяда вакытта язма!..» — дигәннәр. Яла ягып, берәү өстенә ялган гаеп ташлау, гайбәт һәм мәсхәрә итеп язган каралар шәһитләр каннары белән үлчәнми, бәлки шайтаннар гамәле белән үлчәнсә кирәк.

**УНБЕРЕНЧЕ ВАЗИФА (Мәктәп тәртипләренә буйсыну)**

Мәктәп һәм мәдрәсәләр, шулай ук шәкертләр хакында булган кагыйдәләр, заманага яраклаштырып, акыл ияләре тарафыннан төзеләләр. Тәртип булу сәбәпле, аз мәшәкать бәрабәренә күп файда күрелер, һәркемнең хакы сакланыр, гыйлем нигезе дә нык булыр. Моның өчен шәкерт булган кеше мәктәп тәртипләренә патшалыкка буйсынган дәрәҗәдә буйсынырга тиеш.

Көзен билгеләнгән көннән калмыйча мәктәпкә бару, язын да күрсәтелгән көннән калмыйча таралу, шулай ук һәр көнне булган дәрес һәм ял вакытларын белеп тору; ашау-эчү, кию-салу, йоклау-тору вакытларын күзәтеп, тәртип белән хәрәкәт итү тиеш буладыр.

Бу дөньяның яшәве тәртипкә нигезләнгән. Пәйгамбәрләр дә дин белән бәрабәр тәртип аңлатканнар. Ислам шәригатенең һәр ноктасында әлеге тәртип яшидер. Тәртип булмаса, бу дөнья бер сәгать тә яшәмәс иде. Тәртип булмаса, тәртип хөрмәт-ләнмәсә, мәктәпләр мәктәп булмыйча, бер җимереклек булыр иде. Шул сәбәпле мәктәп тәртипләренә буйсынуны гүзәл холык, саваплы гамәл дип белмәгән кешегә (балага) мәктәп ишегеннән аяк атлап керү дөрес булмас.

Бал кортлары үзләренең падишаһларына (аналарына) җаннарын корбан итәр дәрәҗәдә буйсынып йөгергәндә һәм көнозын очып бал ташыганда, дин һәм шәригать, әдәп һәм тәрбия, гыйлем өйрәнер өчен тезелешеп утырган шәкертләр мәктәп тәртибен, остаз һәм башка күзәтче-мөдирләр эшләрен җиңел санасалар, үзләренең гыйлем әһеле булырга, хәтта ки адәм баласы дип саналырга лаеклы түгел икәнлекләрен исбат итәрләр.

Шулай булуга карамастан мәктәп кагыйдәләренә баш бөгү — остаз һәм укытучыларның тиешле чараларына буйсыну, гыйлемне хөрмәтләү һәм мәгърифәтне яратуның тәэсире ул.

Буйсыну исә кеше күрүеннән куркып яки берәр төрле җәзага очраудан сакланып тәртипле булудан гына гыйбарәт булмыйча, боларның һичберсе булмаган хәлдә дә, фәкать мәктәп тәртибе булган өчен генә чын күңелдән яратып һәм хөрмәт итеп үтәүдән гыйбарәт. Адәмчелек тә нәкъ менә шунда инде...

**УНИКЕНЧЕ ВАЗИФА (Чисталык һәм пакьлек)**

Пакьлек — сәламәт булуның беренче дәрәҗәдәге куәтле сәбәпләреннәндер. Ислам шәригате дә пакьлек сакларга боера. Пакьлек — дөрес ният белән булганда, саваплы бер гамәлдер. Дөньяның иң нәҗес, иң шакшы халыклары чисталыкны мактарлар. Үзләреннән пычрак бер кавемне күрсәләр, ал ардан гыйбрәт алып чисталыкка өйрәнерләр.

Гыйлем — бер нур булганы өчен, пычраклык белән бернинди дә мөнәсәбәте юк, бәлки бер-берсенә тәмам каршыдыр. Моны исә һәркем үзе тәҗрибә ясап белер.

Шул сәбәпле гыйлем өйрәнүдә булган шәкертләр чисталыкка гадәтләнергә һәм нәҗеслеккә нәфрәт белән карарга тиешләр. Шәкерт чагында алынган тәрбия, өйрәнелгән гадәт адәм баласыннан аерылмас, каберенә кадәр барыр.

Тән тирләүдән, тузаннар кунудан, бигрәк тә кыш көннәрендә мәктәп һәм мәдрәсәдә тән керләнүчән, күлмәк һәм ыштан да каралучан буладыр. Әгәр дә боларга игътибар ителмәсә, соңыннан тәндә кычулар, кулда бетчәләр, киемнәрдә җанварлар һәм хәшәрәтләр барлыкка килеп, үрчеп, күбәеп китәдер. Хәтта болардан соң кайбер авырулар да буладыр. Шуның өчен бер атнага, һич булмаганда ике атнага бер тапкыр мунчага кереп пакьләнү, бер атнадан калмыйча күлмәк- ыштаннарны алмаштыру тиеш була. Шулай ук чәч төбендә, колак эчендә, тешләрдә, бармак буыннарында, тырнак асларында булган керләрне һәрвакытта пакьләү, тырнакны кисеп тору тиеш була.

Хөрмәтле Рәсүл әфәндебезнең (Аңа Аллаһының хәер догасы һәм сәламе булсын!) тарагы һәм көзгесе, теләсә өйдә вакытта, теләсә сәфәрдә вакытта булсын, яныннан калмас иде. Бу нәрсәләр исә, әлбәттә, чисталык өчен кирәк булыр.

Аш ашаганнан соң, кул һәм авызларны сабын белән юу, теш чистарту кирәк булыр. Бик кирәк булмаганда, пычрак нәрсәләргә буялмаска кирәк.

Пакьлек исә һәрвакытта юынып, төзәнеп торудан гыйбарәт булмыйча, бәлки юылган һәм пакьләнгән нәрсәләрне пакь хәлендә саклаудан гыйбарәттер. Юкса үрдәк кебек бер яктан юынып, икенче яктан пычранган кешене пакь дип әйтеп булмый. Бәлки мондый эштә никадәр су һәм сабын, шулай ук вакыт әрәм итү булганга күрә, бозык сыйфатлардан саналыр.

Мунчага кереп пакьләнү тиеш булыр дигән идек. Тәндә булган керләрне бетерер өчен мунчаның файдалы икәнлеге шөбһәсездер. Ләкин мунчага кергән вакытта ялгыз, әгәр кеше булса, гәүдәнең билдән түбән өлешен каплау өчен билгә бәйли торган җәймә белән булырга тиешле. Чөнки кеше алдында гаурәт, ягъни тәннең кешегә күрсәтергә ярамый

торган җирен ачу хәрам булган кебек, кеше гаурәтенә күз төшерү дә (кирәк булмаганда) — гөнаһтыр.

Шулай булгач, шәригать кушуын исәпләмәгән вакытта да, ят кешеләр алдында ялангач булуга мөселман булган кешенең йөзе кызарыр, инсафы да риза булмас. Инде хөрмәтле шәригатебезнең кушуын (аерым алганда моның кебек мәшәкатьсез кушуын) җиренә җиткерми калырга нинди мөселманның вөҗданы һәм инсафы риза булыр?!

Әбу Хәнифә хәзрәтләре мунчага кергәч, бер дивана килеп кергән. Дивана, биленә җәймә бәйләмәгән булганга күрә, Әбу Хәнифә хәзрәтләре ике күзен ныгытып йомган. Моны күреп, дивана да: «Әй имам! Кайчан сукырайдың?» —дип сораган. Имам хәзрәтләре дә җавабында: «Аллаһы Тәгалә хәзрәте синең пәрдәңне ерткannan бирле!» — дигән. Билгә җәймә бәйләү — шәһәр мунчаларында да, авыл мунчаларында да мөмкин һәм җиңел бер эштер. Шәкерт вакытта моңар гадәтләнергә кирәк.

Бәшәр бине әл-Харис хәзрәтләре: «Бер кешенең байлыгы фәкать бер алтын булып та, мунчада аулак юыныр өчен шуны бирсә, акчасын әрәм итте, дияргә мөмкин булмас иде»,— дигән. Бәшәр хәзрәтләре кебек, тәүлегенә ике кисәк икмәк ашауны да «әрәм итү» дип куркыткан кешенең бу мәсьәләдә болай аңлатуы — игътибарга алынырга тиешле бер сүздер.

Шәригатьтә кайбер мәшәкатьсез, ләкин тиешле мәсьәләләр хакында бездә игътибарсызлык таралды. Җыелышып, билгә җәймә бәйләмичә мунчага керү дә — шуның берседер. Әмма башка мәсьәләләр хакында да хөрмәт һәм игътибарыбыз тиешле дәрәҗәдә түгелдер. Ләкин беләсезме, моның сәбәбе нидә?! Сәбәбе исә, һичшиксез, бу кадерле диннең безгә ата һәм баба-ларыбыздан мирас булып калуындадыр. Әгәр дә без бу юлны үз тырышлыгыбызны әрәм итеп тапкан булсак иде, бер хәрефен йөз алтын исәпләр, аз гына нокталарына барганчы тулы дәрт һәм мәхәббәт белән үтәр идек. Адәм баласы күп вакытта мирас малының кадерен белмәс, аны һичвакытта җан тирләрен чыгарып тапкан дәүләте-байлыгы бәрабәрендә тапмас.

Бу очракта күп сүзләр язар һәм күп гыйбрәтләр күчерер идем, ләкин язганыбыз да җитәр.

## УНӨЧЕНЧЕ ВАЗИФА (Икътисад — малны сак тота белү)

Икътисад тота белү дип әйтеләдер. Кулда азмы-күпме булган акча яки башка нәрсәләрне гаделлек белән тоту — фәкыйрьлек һәм мохтаҗлыктан саклый торган нәрсәләрнең берседер. Изге хәдистә: «Икътисад белән дөнья көткән кеше фәкыйрь булмас»,— диелә.

Ашау-эчү, кию-салу һәм башка тору-йөрү әсбапларын да югары дәрәҗәле булганнарын һәм авыр бәһаленәрне (бик кыйммәтлеләрне) куллану һәрникадәр шәригать хөкеменчә хәрам булмаса да: «Юрганыңа күрә аягыңны суз!» —дип әйтелгәнчә гамәл ителә. Бар булганнарын яхшы гына тәрбияләп кулланырга гадәтләндерелсә, кеше кулында булган нәрсәләргә ач күзләләнеп кызыгылмас, күңел дә шат булыр. Юкса кулда булган кадәргә риза булмаган кешенең нәфесе бөтен дөнья малына канәгать итмәс, туймас. Икътисад белән эш итмәгән кеше һәм ач куала, һәм хирыс (комсыз) булыр. Ач күзлелек

исә — бетми торган фәкыйрьлек, дәвасы табылмаган хәстәлек яки азатлыгы ихтимал булмаган әсирлектер. Хирысның (комсызлыкның) ахыры да хурлык, түбәнлек булыр. Зәрнүҗи хәзрәтләре: «Ач. күзлеләр доиь-и-сында гыйлем хөрмәте дә булмас, хак сүзне дә сөйләмәсләр», дигән.

Шуның өчен шәкертләр, үзләренең күз нурларын түгрп» чәчәк кебек гүзәл вакытларын корбан итеп тапкан гыйлемнәрен, алган әдәп һәм тәрбияләрен ач күзлелек һәм комсызлык кебек бозык нәрсәләргә сарыф итмәскә тиешләр. Тырыш галим ач күзлелек түбәнлегенә төшмәс, хирыс (комсыз) кешенең күзен дә туфрактан башка нәрсә туйдырмас.

Шәкерт вакытта икътисадка гадәтләнгән кешеләрнең доиья га чыкканнан соң да бу гадәтләрен ташламаулары, иркенлек һәм байлык белән гомер итүләре тәҗрибә белән беленгән.

Һәр күренгән нәрсәне алырга, һәр күңелгә килгәнне ашар-га-эчәргә, кием-салымда Казан халкына иярергә падишаһлар байлыгы җитмәс, шәкерт байлыгы ничек җитсен?! Тән сәламәт, җан рәхәт, күңел тыныч булса, шатланып, куанып гыйлем өйрәнергә кирәк. Гыйлем булса — кием табылыр...

Көмеш сәгатьләрен кесәләренә салган күп шәкертләр күренәдер ки: хәзинәләре тикшерелсә, һичнәрсә табылмыйдыр. Кыланмыйча гына киемнәр кигән шәкертләргә туры киләдер ки: хәзинәләре гыйлем, әдәп, инсаф белән тулган буладыр.

**УНДҮРТЕНЧЕ ВАЗИФА (Һөнәр — сәнагать)**

Хөрмәтле Пәйгамбәрләр хәзрәтләренең (Аларга Аллаһының сәламе булсын!) кул эшләре белән ашаганнары һәм үз һөнәрләре белән яшәүләре мәгълүмдер. Моны исә үзегез дә китапларда укып белерсез яки укып белгәнсездер дә.

Үзебезнең Пәйгамбәребез Мөхәммәд хәзрәтләре (Аңа Аллаһының хәер догасы һәм сәламе булсын!) бу дәрәҗәдә булган кадер һәм хөрмәте белән читекләрен, башмакларын ямый; йорт хезмәтләрен эшли; сәфәрендә аш пешерүче сәхабәләргә: «Кеше эшләгән вакытта тик торырга яратмыйм», — дип, утыннар җыеп (коры үлән һәм курайлар) китерә иде.

Һөнәрсезлек сәбәпле, адәм углы дөньяда тору өчен түгел, бәлки җаннан буш калган күңелен саклар өчен дә чара була алмас!.. тәрбияләнер, дин һәм шәригать юлына бирелер; әмма фәкыйрьлек белән нинди изгелек табылыр?!

Пароход, тимер юллар, телеграф һәм телефоннар, машина һәм электр заманны шулкадәр башкаландырдылар ки: аңлатырга каләмнең көче җитмәс. Биш йөз ел элек вафат булган бабаларыбыз, мөмкин булып, Болгар яки Казан каберлеклә-реннән торып дөньяга кире кайтып килсәләр иде, үзләре аерылган дөньяга тәмам башка булган икенче дөнья килүенә инанырлар иде.

Бу сүзләрдән максат исә — шәкертләр ахирәт өчен дин гыйлеменә, дөнья өчен һөнәр гыйлемнәренә мәхәббәт куеп барырга тиешле икәнлекне аңлатудыр. Шәкертлек заманасының барлык сәгатьләре һәм минутлары да гыйлем өйрәнү белән үтмәс. Бәлки

кайбер буш көннәр дә, хәтта ки буш айлар да булыр. Әгәр шул вакытларда кайбер яраклы һөнәрләр, шулай ук кирәк кадәр генә булса да рус теле өйрәнелсә — файдасыз булмас. Һөнәр ашарга сорамас, ашарга бирер. Дин гыйлеменнән башка — ахирәт; һөнәрдән башка дөнья төзек булмас. Әмма дөньясы төзелмәгән кешенең ахирәте дә төзелмәгәне хәтердән чыкмасын!.. Гүя «иртәгә үләчәк кебек ахирәтең өчен гамәл ит! Мең ел торачак кебек дөньяң өчен гамәл ит!» дигән сүзнең бер хәрефе — йөз алтындыр.

Киләчәк көннәрегездә бәлки бу сүзләр кирәк булыр, дип, сезгә бүгеннән сөйләп куйдык. Колакка кергән сүз, тиз бул-маса да, бер вакытта күңелгә дә керер.

## УНБИШЕНЧЕ ВАЗИФА (Гүзәл холык)

Күркәм холыкның (гүзәл холыкның) яхшы икәнлеген, күркәм холыклы булырга кирәк икәнлекне бөтен дөньяда булган гакыллы кешеләр һәрвакытта расларлар. Бу очракта әйтелгән сүзләрнең, язылган китапларның саны һәм хисабы юктыр.

Бу шәкертлек көннәрегездә, Аллаһы Тәгалә теләсә, әхлак дәресләре укыйсыздыр. Уку — олуг бәхет, укып белгәннәр белән гамәл итү — зур бәхет һәм өстенлектер. Шуның өчен укыганнан соң гамәл итәргә тырышырга кирәк.

Хөрмәтле Рәсүл әфәндебез хәзрәтләренең (Аңа Аллаһының хәер догасы һәм сәламе булсын!) күркәм холык мәсьәләсендә: «Адәмнәрне малыгыз белән ризалатырга кодрәтегез җитешмәс, ләкин холкыгыз белән ризалатырга тырышыгыз!» —дигән сүзеннән башка бер сүзе булмаса да, күркәм холыкның дәрәҗәсен дәлилләр өчен безгә шул җитәр иде. Шулай булуга карамастан моның кебек тагын ничәмә-ничә вәгазь һәм нәсыйхәтләр әйтәләр ки, барысы да хәдис китапларында язылган. Хөрмәтле Рәсүл әфәндебезнең үз холкының нинди рәвештә булуын, аның тәртибе, яшәеше турында китаплардан күреп аңлау — безнең өчен олуг дәрес һәм бәһале гыйбрәттер.

Таш йөрәкләр, кара күңелләр күркәм холык алдында йомшарырлар, буйсынырлар. Дошман һәм дусны ризалату өчен, күркәм холыктан үткен корал дөньяда юктыр.

Шуның өчен бу өстен булган күркәм холыкка шәкерт вакытта гадәтләнергә кирәк. Күп гаеп эшләр булыр, алар надан кешеләрдән күрелгәндә, «белмичә», «ялгышлык белән эшләнде» дип гафу ителер. Ләкин укыган кешеләрдә булганда, аз гаепләр дә кичерелмәс; әмма бозык холык булса, һич гафу ителмәс.

Киләчәк гомерләрегездә, кирәк — олы галим, кирәк — мәшһүр мөхәррир (язучы), кирәк — оста сөйләүче (хатиб — вәгазьче), кирәк — сәүдәгәр, кирәк — башка; кыскасы, теләсәгез кем булсагыз да, гүзәл холыктан бер карыш читкә чыкмагыз!.. Гүзәл холык белән аз гыйлем дә — күп, кыска гомер дә озын булыр.

Диндарлык, эштә һәм сүздә дөреслек, сабыр итү, ныклык, тыйнаклык, ялыну, һәр эштә киңәш итү, сәламәтлекне саклау өчен игътибарлы булу — барысы да, күркәм холык булып, бигрәк тә шәкертләр өчен кирәкледер.

Укуда булган китапларыннан һәм фәннәреннән, шулай ук укытучы һәм остазларыннан ялыкмыйча һәм күңел биреп укудан туктамыйча, һаман рәхәтләнеп тырышырга кирәк. Шулай ук дөнья мәшәкатьләре туры килгәндә артык кайгырмыйча

сабыр итәргә; эшләрне Аллаһы Тәгаләгә тапшырып, үз-үзеңне йөртә белергә кирәк. Бер гакыллы кешедән: «Баһадир (батыр) кем?» —дип сораганда: «Бер сәгать сабыр итә алучы»,— дип җавап биргән.

Инде бер сәгать сабыр иткән кеше баһадир булса, ничә ай һәм ничә елларга сабыр итеп һаман гыйлем өйрәнү юлында йөргән шәкертләрне мактарга сүз табылмас.

Гыйлем, адәм баласы өчен олуг бәхет булса, әлбәттә, михнәтсез һәм мәшәкатьсез генә барлыкка килмәс. Максатларга михнәт күпере аркылы барылыр. Ләкин шәкертлек михнәтләре башкаларга үрнәк ителмәс. Шәкертлек михнәтләренә рәхәтлекләр тоташып килгәнлеген күтеп сабыр итүчеләр үз тәҗрибәләре нигезендә сөйлиләр. Вакыты үткәннән соң, шәкертлек михнәтен уйлап шатланмаган һәм шул көннәрне сагынмаган кеше булмас.

Диндарлык (гөнаһтан саклану) — адәм баласы, бигрәк тә шәкертләр өчен мисаллары булмаган бер зиннәттер. Һәр изгелек диндарлык өчен булыр. Диндарлык — һәр яхшылыкның нигезедер, диндарлык белән өйрәнгән гыйлемнең файдасы да кадерле булыр. Әүвәлге заман шәкертләре гайбәт сөйләмәсләр, сүз йөртмәсләр, кешене мәсхәрә итмәсләр, күп ашамаслар, күп йокламаслар, хәтта ки базар әйберләрен авыз итмәсләр иде. Әхлаксыз кешеләр белән аралашмаслар, фарыз, ваҗиб, сөннәтләрне, ягъни мәҗбүри үтәлергә тиешле дини бурычларны олыларлар, дөнья һәм ахирәт өчен кирәкләрен сорап, даими Аллаһы Тәгаләгә догада булырлар иде.

Кергән юлда ныклы, гыйлем өйрәнүгә киртә булган нәрсәләргә каршы торырга кодрәтле булу — шәкертләрнең шартларыдыр.

Тыйнак булу, кирәк вакытта хәтта ки ялыну да шәкертләр өчен тиеш. Артык ялыну — һәрвакытта начар холык булганга күрә, гыйлем өйрәнү мәсьәләсендә булганы — гүзәлдер.

Зур һәм кечкенә эшләрдә остазларга киңәш итү һәм алар тарафыннан күрсәтелгән юл белән йөрү кирәк. Гакыл һәм белүдә хөрмәтле Рәсүл әфәндебез хәзрәтләреннән артык кеше булмаганга күрә, Ул киңәшүнең кирәклеген кат-кат әйтә торган булган. Шуның өчен хәтта ки йорт кирәкләрендә дә сәха-бәләргә киңәш итә торган булган. Гыйлем өйрәнү — эшләрнең олысы һәм максатларның да иң газизедер. Моның иң кечкенә саналган нокталарында да гакыл әһелләре, бигрәк тә укытучы һәм остазлар белән киңәш итү кирәк. Шәкертенең киңәш итүеннән һичкем тарсынмас. Киңәшмәгән эшне аңлату ихтималы да остазда булмас.

Күркәм холык мәсьәләсендә сүз күп булыр, ләкин шәкертләр өчен бик кирәк булганнарына без бу язманың башыннан ахырына кадәр булган сүзләребез белән ишарә иттек.

Кесә һәм янчыкларда алтын вә көмеш булмау хурлык яки бәла-каза түгелдер, ләкин күңелләрдә гүзәл холык белән гыйлем булмау һәм хурлык, һәм олы бәла саналыр.

Аллаһы Тәгалә хәзрәте барыбызга да һәрвакытта диндарлык, риза булу һәм ачулы вакытларда дөрес һәм туры сүзлелек, байлык һәм фәкыйрьлек вакытларында ныклык һәм сабырлык насыйп итсен!

Ахыры җәннәт булса — нәрсә булса да яхшы; ахыры тәмугъ булса — нәрсә булса да начар. Җәннәттән башка булган нигъмәт — нәрсә булса да нигъмәт түгел; уттан башка булган нинди генә авырлык булса да — җиңелдер. Үз гаебе белән шөгыльләнгән кеше кеше гаебен күрергә вакыт тапмас; Аллаһы Тәгаләнең язмышына риза булган кеше дөнья өчен кайгырмас. Кеше пәрдәсен ерткан кешенең үз пәрдәсе ертылыр. Кеше өчен казыган чокырга үзе төшми калмас. Үз хатасын онытучы кеше хатасын күрүчән булыр. Гакылына ышанган кешеләр ялгышыр, тәкәббер кеше хур булыр. Фәкыйрьлекнең зиннәте — сабырлык, байлыкның зиннәте — шөкер итә белүдер. Сәламәтлек — байлык; әдәплелек — камиллек; тәүбә итү — бәхет; күркәм холык — яхшы иптәштер.

(Бетте)

***«Шәкертлек әдәпләре» китапчыгына кушымта.***

Бу язмада исемнәре телдә булган хөрмәтле затларның кыскача тәрҗемәи хәлләре бирелә:

1) Мөхәммәд (Аңа Аллаһының хәер догасы һәм сәламе булсын!) Әбүлкасыйм бине Габдулла бине Габделмоталлаб бине, Һашим Мәккә шәһәрендә дөньяга килеп, кырык яшендә вәхи, ягъни күктән Аллаһы Тәгаләнең иңдермәләре иңү белән хөрмәтләнде. Унөч елдан соң Мәдинәгә күчеп китте. Анда унбер ел торып, 63 яшендә вафат булды.

Кулыбызда булган дини календарьлар күрсәтүенә нигезләнеп, дөньяга килүе рабигыль-әүвәл аеның 9 ында, дүшәмбе көнне, милади ел исәбе буенча 571 елның Европача апрель аеның 21 енә туры киләдер. 622 милади елының сентябрь аеның 20 сендә, дүшәмбе көнне, рабигыль-әүвәл аеның 8 ендә коббәгә — чатырга кереп, сентябрьнең 24 ендә, рабигыль-әүвәл аеның 12 сендә, җомга көнне, Мәдинәгә барып кереп, әүвәлге җомганы укыган. Бу вакытта, Европа белән руми хисапларының аермасы фәкать өч көннән гыйбарәт булу сәбәпле, руми көннәрне белү дә җиңел.

**Ә (Әлиф)**

2) Әбүбәкер әл-Харәзми Мөхәммәд бине Габбас. Атасы — мәшһүр тарихчы Әбу Җәгъфәр Мөхәммәд бине Җәрир әт-Табари белән бертугандыр. Шигырь һәм уйлап табу гыйлемендә заманасының бердәнбере иде. Нижри белән 383 елда, 67 яшендә Нишапур (Нисабур) шәһәрендә вафат булды. Язмалары һиҗри белән 1397, милади белән 1891 елда Бомбейда басылган. Моның язмалары Бәдигыз-Заман әл-һәмадани язмаларыннан гүзәлрәк иде, дип мактаучылар бардыр.

3) Әбу Хәнифә Ногман бине Сабит. Хәнифә мәзһәбенең имамыдыр. Куфә шәһәрендә дөньяга килеп, 65 яшендә, һиҗри белән 100 елда, милади белән 767 елда вафат булды. Хаммад бине Сөләйман янында унсигез ел гыйлем белән шөгыльләнгән. Үткен гакыллы, зирәк, күркәм йөзле, яхшы әңгәмәдәш, күп сүзле, җиңел аралашучан, кыланмый торган кеше булган. Әгәр дә шәригать кануннары буенча имам булмаса — бу зирәклеге белән бер олуг акыл иясе булган булыр иде, дип мактаучылар бардыр. «Әл-фикъһел-экбәр» («Иң зур шәригать кануннары») белән «Әл-васыять» исемле язмалары Дәһли шәһәрендә, 244 битле булып, милади белән 1890 елда басылган. Сарыф, ягъни морфология гыйлеменә караган «Әл-максуд» исемле язма да — моныкы.

4) Әбу Зәед Гобәйдулла бине Гомәр бине Гайса әд-Дәбүсидер (бу кешенең тәрҗемәи хәлендә Мәрҗани хәзрәт: «Әбу Зәед Габдулла бине Гайса бине Гомәр»,— дип язган). Хәнифә мәзһәбендә казый һәм олы имам һәм хөрмәтле бер язучы булган. Каршылык, ягъни конфликтлылык гыйлемен (гыйльме хилафны) дөньяга чыгаручы — шушы заттыр. Һиҗри белән 432, милади белән 1040 елда Бохара шәһәрендә вафат булган.

5) Әбу Йосыф Ягъкуб бине Ибраһим бине Хәбибел-Әнсари. Әбу Хәнифәнең галим шәкерте һәм мәзһәбен дөньяга таратучыдыр. Куфә шәһәрендә дөньяга килгән иде. Имам Әхмәд бине Мөхәммәд бине Хәнбәл һәм Яхъя бине Мәгыйн кебек олуг галимнәр үзенә шәкерт булганнар. 18 ел тоташ — Мәһди, Һади, Рәшид хәлифәләр гасырында казыйлык хезмәтендә булды. Һиҗри белән 182, милади белән 898 елда Багдадта вафат булды. «Китабел-хираҗ» («Салым китабы») исемле әсәре һиҗри белән 1302, милади белән 1880 елда Мисырда басылган.

6) Әгъмыш Әбу Мөхәммәд Сөләйман бине Мәһран. Куфә шәһәрендә олуг галимнәрнең берсе иде. Сәхабәләрдән Әнис бине Малик хәзрәтләре белән әңгәмәдәш булган. 87 яшендә һиҗри белән 148, милади белән 767 елда вафат булган.

**Б (БА)**

7) Бәшәр бине әл-Харис. Хөрмәтле галимнәрдән бу исемдә ике кеше бар. Берсе — Бәшәр Әбу Насыр бине әл-Харис бине Габдеррахман әл-Хафи. Изге күңелле һәм диндар бер зат булган. Багдадта торган. Серле рәвештә үле туган бала турында моннан риваять иткәннәр. 7 яшендә, һиҗри белән 226, милади белән 840 елда вафат булган. Икенчесе — Бәшәр Әбу Габдулла бине әл-Харис бине Әсәд әл-Мәхасиби. Суфичылык гыйлемендә имам Әйди Җәнид Багдадиның остазыдыр. Һиҗри белән 243, милади белән 856 елда вафат булган.

**Җ (Җим)**

8) Җәмаледдин Мөхәммәд бине Сафтәр әл-Әфгани. Кабул төбәгендә Әсгад Абад авылында дөньяга килгән. 18 яшендә шәригать гыйлемнәрен һәм гакыл гыйлемнәрен тәмам өйрәнеп, олуг галимнәр төркеменә кергән. Шәех Җәмаледдин, сирәк очрый торган галимнәрнең берсе булып, ислам милләтенең исемен бөек итәргә сәбәп булган. Гакылы камил, гыйлеме нигезле булуы белән, аны көнчыгыш һәм көнбатыш галимнәре дә таныганнар. Һиндстан, Хиҗаз, Гаҗәмстан (Иран), Европа дәүләтләрендә сәяхәт иткән. Беркадәр заман Петербургта да торган иде. Сабырлык белән батырлыкта мисалсыз, тиңсез булып, гаять тә бөек фикерле, дөньяга игътибарсыз, диндар һәм намуслы бер зат иде, диләр. Бөтен максаты — ислам халкы арасына гыйлем һәм мәгърифәт тарату, бөек фикерләрен аңлатып, күңелләрне нурландыру булган. Шул фикердә нык булып гомер итте, шул фикере өчен шәһәрдән шәһәргә сөрелде, шуның фикере бәрәкәтендә дәүләтләрдән дәүләтләргә, вәзирләргә, хәтта ки падишаһларга хөрмәтләп чакырылды, ахырында шул фикерендә дөньядан үтте, диләр. 60 яшендә, һиҗри белән 1314, милади белән 1897 елда Истанбулда вафат булды. «Рәддед-дәһриййин» («Дәһриләргә каршы») исемле язмасы һиҗри белән 1303, милади белән 1886 елда Бәйрутта, һиҗри белән 1312, милади белән 1895 елда Каһирәдә басылган. «Тәтиммәтел-бәян фи тарихил-әфган» («Әфган тарихын аңлату өчен кушымта») исемле әсәре 45 бит күләмендә Мисырда басылган.

**Х (Хә)**

9) Хәсән Әбу Сәгыйд бине Әбүлхәсән Ясар әл-Басрый. Табигыйннәрнең, ягъни Мөхәммәд Пәйгамбәрне яхшы белүче кешеләрнең иң өстен булганнарының берседер. Хәзрәти Гомәр (Аллаһы Тәгалә аннан риза булсын!) заманасында дөньяга килгән иде. Галим, дәрәҗәле кеше, дөнья мәшәкатьләреннән ваз кичеп, гыйбадәт белән генә шөгыльләнә торган диндар, матур һәм килешле итеп сөйләүче бер зат булган. 89 яшендә, һиҗри белән 161, милади белән 767 елда вафат булды.

10) Хәсән Әбу Гали бине Зияд әл-Лөәлөә. Әбу Хәнифә хәзрәтләренең шәкерте иде. Имам Шафигый белән бер елда, һиҗри белән 204, милади белән 785 елда вафат булган.

11) Хаммад Әбу Исмәгыйль бине Сөләйман. Әбу Хәнифә хәзрәтләренең остазыдыр. Әнис бине Малик һәм Ибраһим ән-Нәхәгыйдән риваять гыйлемен өйрәнгән. Һиҗри белән 120, милади белән 737 елда вафат булган.

**Х (Ха)**

12) Хәлил Әбу Габдеррахман бине Әхмәди әл-Фәрһуди әл-Басрый. Тел, грамматика гыйлемнәрендә остаздыр. Гаруз, ягъни шигырь үлчәве турындагы гыйлемне (метриканы) башлап дөньяга чыгарды. Имам Сәйбәвия моның шәкерте иде. «Башка галим күрмәгән кеше үз укытучысының хатасын аңламас»,— дип әйтә торган булган. Хәлил хәзрәтләре акыл иясе, бик диндар, канәгатьчән, гыйбрәтле сүзле булган. Бик тәэсирле шигырьләре күптер. Бер тиен бакыр акчасы булмыйча, Басра шәһәрендә бер камыш шалашта торган. Шулай булса да, моннан алган гыйлем сәбәпле, шәкертләре олы дәрәҗәләргә һәм зур байлыкларга ирешкәннәр. Фарсы әмире Сөләйман бине Хәбиб, аны зур вазифага билгеләп, үзенең балаларын укытырга чакырган булса да, аның чакыруын кабул итмәгән. Янында булган бер икмәк кисәген күрсәтеп, «Дөньяда торган вакытымда, Аллаһы теләсә, бу икмәк кисәгеннән аерылмам»,— дигән. Нижри белән 170, милади белән 786 елда Басра якынында вафат булган. Телдә йөргән «Әл-гайн» («Чишмә») исемле китап — моның әсәредер. Ләкин бу соңгы заманнарда күп тырышлык белән эзләп тә, һаман да әлеге китапны таба алмыйлар.

**З (Зә)**

13) Зәрнүҗи Борһанеддин (Борһанел-Ислам). Кижри белән алтынчы гасыр, милади белән уникенче гасыр галимнәреннән булып, «Һидая» («Туры юлга керү») исемле китапның иясе — язучысы Гали бине Әбу Бәкер бине Габделҗәлил әл-Фиргани әл-Маргыйнаниның шәкертедер. Уку һәм укыту турында «Тәгълимел-мөтәгаллим тарикыт-тәгаллүм» («Укучыны укыту— белем алу ысулы») исемле китабы бик яхшы дип табылган һәм бик мәшһүрдер. Үзе язган нөсхәсенең бу көндә Париж китапханәсендә икәнлеге риваять ителәдер. Латин теленә дә тәрҗемә ителгән. Бу тәрҗемәсе 1809 елда Роландо исемле кеше тырышлыгы белән Утрихт шәһәрендә бастырып таратылган. Һиҗри белән 1260, милади белән 1843 елда Һинд-станда Мөршид Абад шәһәрендә, 1838 елда Лейпцигта, һиҗри белән 1301, милади белән 1883 елда Мисыр һәм Истанбулда да бастырылган. Бу әсәр бик кадерле һәм бик яхшы бер китап булса да, илебездә кеше булмаган кешеләр кулында кулланыла. Тәрҗемә итәргә теләсәм дә, төп нөсхәсендә булган ләззәтен саклап тәрҗемә итәрлек белем хәзинәсеннән мәхрүм булганым өчен, бу фикердән

кайттым. Шулай булса да «Шәкертлек әдәпләре» исемле әсәрдә күбрәк файдаланган нәрсәләрем шушы китаптан булды.

14) Зәед бине Сабит Әбу Хариҗә әл-Хәзәрҗи әл-Әнсарый. Хөрмәтле сәхабәләр төркеменнән. Әфәндебез иң хөрмәтле Рәсүлнең (Аңа Аллаһының хәер догасы һәм сәламе булсын!) язучысы (сәркәтибе. — Ә.Х.) иде. Изге Коръәнне иң хөрмәтле Рәсүлебезгә укыган Әбу Һөрәйрә, Ибне Габбас хәзрәтләре — бу затның шәкертләредер. 56 яшендә, һиҗри белән 45, милади белән 664 елда вафат булган.

**С (Син)**

15) Сәдидеддин әш-Ширази.

16) Суфиян Әбу Габдулла бине Сәгыйд әс-Сәүри. Мөҗтәһид-ләрнең, ягъни дин китаплары буенча яңа хөкемнәр чыгаручыларның берсе булып, Җәнид хәзрәтләре моның мәзһәбендә иде. Хәдис һәм башка гыйлемнәрдә дәрәҗәсе зур булган, Куфә шәһәрендә дөньяга килеп, 66 яшендә, һиҗри белән 161, милади белән 777 елда вафат булган.

**Ш (Шин)**

17) Шәгъби Әбу Гомәр һәм Гомәр бине Шәрхәбил (Шәра-хил). Куфә шәһәрендә торып, 85 яшендә, һиҗри белән 104, милади белән 722 елда вафат булды. Биш йөз сәхабәне күргән бер галим булган. Габделмәлик бине Мәрван тарафыннан Кайсарга, ягъни Рим императорына илче булып барган. Үзеннән күп мәзәкләр һәм көлкеле, үткен мәгънәле кыска хикәяләр күчереп сөйлиләр.

18) Шәмсел-Әиммәти Габделгазиз Әбу Мөхәммәд бине Әхмәд бине Насыйр әл-Хәлваи. Хәнәфия мәзһәбендә бик танылган бер имамдыр. Хәдис гыйлемен һәм хәдис галимнәрен бик хөрмәт итә торган булган, һиҗри белән 448, милади белән 1053 елда яки соңрак Бохара шәһәрендә вафат булган.

19) Шәмсел-Әиммәти Мөхәммәд Әбу Сәһел бине Әхмәд әс-Сәрхәси. Шәмсел-Әиммәти әл-Хәлваиның шәкерте булган. Ничә томнар булган «Әл-Мәбсут» («Озын, тәфсилле сүз») исемле китабын тоткын булган хәлендә, һичбер китапка карамыйча, фәкать күңелдән язган. Һиҗри белән 500, милади белән 1104 еллар чигендә вафат булган.

**Г(Гайн)**

20) Габдулла Әбүлгаббас бине Габбас бине Габделмоталлаб. Галим сәхабәләрдән булып, хәдис гыйлемендә, Коръән тәфсирендә, шигырьләр һәм хәбәрләрне хәтердә тотуда гасырының бердәнбер кешесе булган. Иң хөрмәтле Рәсүлебез вафат булганда, 13 яки 15 яшендә булгандыр, Габбасия хәлифәләре — шушы затның нәселеннән. 70 яшендә, һиҗри белән 68, милади белән 687 елда Таиф шәһәрендә вафат булган. Үзеннән риваять ителгән тәфсирләр, тупланып, китап рәвешендә төзелгәннәр. Бу китап «Тәфсире Ибне Габбас» исеме белән билгеледер. Бомбей шәһәрендә һиҗри белән 1280, милади белән 1862 елда, Булакта һиҗри белән 1290, милади белән 1852 елда басылып чыккан.

21) Габдулла Әбу Габдеррахман бине Мәсгудь. Иң әүвәл иманга килгән һәм гыйлем белән танылган сәхабәләрдән. Ике мәртәбә Хәбәш (Эфиопия. — ӘХ.) дәүләтенә күчеп китеп, Бәдәр, Әхәд, Хиндык сугышларында да булган. Үзенә әфәндебез — иң

хөрмәтле Рәсүл (Аңа Аллаһының хәер догасы һәм сәламе булсын!) җәннәт белән сөенеч биргән. 60 яшеннән узып, һиҗри белән 32, милади белән 642 елда Мәдинәдә вафат булып, Бәкыйгъдә җирләнгән.

22) Габдулла Әбу Габдеррахман бине әл-Мөбарәк әл-Мәрвәзи. Хәдис галимнәренең олыларыннан. Әбу Хәнифә хәзрәтләренә дә шәкерт булган. Гыйлем, намуслылык, диндарлык, тугрылык белән мәшһүр булган. Гыйбрәтле сүзләре, нәсыйхәтләрне эченә алган шигырьләре бардыр. 63 яшендә, һиҗри белән 181, милади белән 796 елда вафат булган. Үзе төрек нәселеннән булган.

23) Гали Әбүлхәсән бине Әбу Талиб бине Габделмоталлаб (Аллаһы аннан риза булсын!) иң хөрмәтле Рәсүлнең кызы — хәзрәти Фатыймага никахланып, аның кияве иде. Аңа да җәннәт белән сөенеч бирелгән. Хәзрәти Госман бине Гафан вафат булганнан соң, һиҗри белән 35, милади белән 655 елда хәлифә булды. Аны Габдеррахман бине Мөлҗәм әл-Морадый дигән кеше һиҗри белән 41, милади белән 661 елда, рамазан аеның 17 көнендә, иртәнге намазда кылыч белән яралаган. Ике көн торып вафат булган. Батыр йөрәкле, бөек, мәрхәмәтле, гакыллы, алдан күрүчән, дөрес сүзле, ачык йөзле, шаян сүзле, матур һәм килешле итеп сөйләүче һәм матур кеше булган.

24) Гомәр Әбу Хафис бине әл-Хаттаб бине Нәфил. Җәннәт белән сөенеч бирелгән сәхабәләрдән булып, икенче хәлифә булган. Һиҗри белән 23, милади белән 643 елда, зөлхиҗҗә ае ахырында, иртәнге намазга барган вакытында Әбу Ләәлөә Фирүз исемле явыз тарафыннан хәнҗәр белән кадалып яраланган һәм егерме дүрт сәгатьтән соң вафат булган. Гыйбадәт кылучы, мәрхәмәтле, тыйнак, көчле, кодрәтле, гадел, тырыш кеше булган. Кызы Хафса (Аллаһы аннан риза булсын!) иң хөрмәтле Рәсүлебезнең никахында иде.

**Ф (Фа)**

25) Фәхреддин әл-Казый.

**М (Мим)**

26) Малик бине Әнис бине Малик бине Әбу Гамир әл-Мә-дәни. Хәдис гыйлемендә остаз һәм Малики мәзһәбенең имамы булган. Мәдинә шәһәрендә дөньяга килеп, 85 яшендә, һиҗри белән 179, милади белән 716 елда Мәдинәдә вафат булган. Кабере — Бәкыйгъдә. Мәзһәбе исә — Гарәбстанның көнбатыш тарафында мәшһүрдер. Имам Шафигый, Суфиян Сәүри, Габдулла бине Мөбарәк, Габдеррахман әл-Әүзагый, Ләес бине Сәгыйд, Мөхәммәд бине әл-Хәсән эш-Шәйбанинең остазы һәм Әбу Хәнифәнең дусты булган. Хәдис гыйлемендә элек язылган «Әл-Мәүтаэ» («Аяк эзләре») җыентыгы — бу кешенеке. Һиҗри белән 1291, милади белән 1873 елда Дәһлидә, Һиҗри белән 1280, милади белән 1862 елда Туниста, 1885 елда Һинд-станның Лахор шәһәрендә, һиҗри белән 1280, милади белән 1862 елда Каһирәдә басылып чыккан.

27) Малик бине Динар. Басра шәһәрендә диндар, галим, хәдисләр галиме бер зат булып, аның гыйлеменнән күп файда алырлар иде.

28) Әл-Мәэмүн Әбүлгаббас Габдулла бине Һарун әр-Рәшид. Габбаси хәлифәләрнең галиме һәм гыйлемгә дә мәхәббәтлесе булган. Моның заманасында Багдадка һәр тарафтан

әдипләр һәм галимнәр җыелган. Багдад гыйлем шәһәре булган, янында һәрвакытта гыйлем һәм укымышлы кешеләр булган һәм алар белән бәхәсләшә торган булган. 20 ел дәвамында хәлифә булып, 49 яшендә, һиҗри белән 218, милади белән 833 елда вафат булган. Кабере - Тарсус шәһәрендәдер.

29) Мөҗаһид Әбүлхаҗ әл-Мәкки. Мөхәммәд Пәйгамбәрне яхшы белүче һәм Коръәнне тәфсирләүче галимнәрдән хөрмәтле бер кеше булган. Габдулла бине Габбас хәзрәтләреннән гыйлем өйрәнеп, аның янында Изге Коръәнне егерме мәртәбәдән артык укып чыккан. Изге Коръәндә булган кыенлыкларны да — барысын да сорап һәм белеп үткән. Намаз эчендә, сәҗдәдә вакытында  вафат булган. Яше 80 дә һәм вафаты һиҗри белән 103, милади белән 1594 елда булган.

80) Мөхәммәд Әбу Габдулла бине Исмәгыйль әл-Бохари. Хәдис гыйлемендә галимнәрнең галимедер. Гыйлем өйрәнер өчен Мисыр, Шам (Сүрия), Хорасан, Хиҗаз өлкәләренә сәфәр пткән. Язган  китапларының иң мәшһүре — хәдис гыйлемендә иц ышанычлы һом дөрес «Җамигыс-сахих» («Дөресен җыючы») исемле әсәредер. Язучының үзеннән туксан мең кеше бу китапны укып риваять иткәннәр. Үзе унике ел гомер сарыф итеп, күбесен кадерле, изге җирдә, иң хөрмәтле Рәсүлебезнең кабере янында язган. Һәр заманның галимнәре шушы китап белән олуг шөгыльдә булып, язылган аңлатмалары һәм искәрмәләре хисаптан тыш күп, һәм һәр дәүләтнең галимнәре бу көндә дә шәкертләренә укыту хакында бик күп игътибар итәләр. Чөнки гыйлемлектән мәхрүм кешеләргә бу кадерле китапны уку яки укыту насыйп булмас. Һиҗри белән 1292, милади белән 1874 елда сигез томда Булакта, һиҗри беләм 1313, милади белән 1895 елда тагын сигез томда Булакта, 1868 елда өч томда Европада — Лейден шәһәрендә, һиҗри белән 1279, милади белән 1861 елда ун томда Каһирәдә, һиҗри белән 1316, милади белән 1897 елда сигез томда Зәһни әфәнде нәсыйхәте белән Истанбулда басылган.

31) Мөхәммәд Әбу Габдулла бине әл-Хәсән бине Фәркад әш-Шәйбани. Әбу Хәлифәнең шәкертедер. Хәдис гыйлемен Мәсгар бине Кәдам, Суфиян Сәүри, Малик бине Әнис, Әүзагый, Әбу Йосыф әл-Казыйдан күчереп өйрәнгән. Үзеннән Мөхәммәд бине Идрис әш-Шәфигый һәм башкалар күчереп өйрәнгәннәр. Имам Шафигый хәзрәтләре: «Мөхәммәд бине әл-Хәсәннән гакыллырак кеше күрмәдем»,—дигән. Һиҗри белән 189, милади белән 804 елда Рәй шәһәрендә вафат булган. Хәдистә булган «Әл-мәутаэ» («Аяк эзләре») исемле китабы мәшһүр. Һиндстанда, Лодъянҗ шәһәрендә һиҗри белән 1291, милади белән 1873 елда басылган. Әбу әл-Хәсәнәт Мөхәммәд Габделхәй әл-Ләкнәви дөресләгән нөсхәсе үзенең дә искәрмәләре белән Газыйм абад шәһәрендә һиҗри белән 1298, милади белән 1880 елда һәм соңыннан, һиҗри белән 1306, милади белән 1888 елда ике мәртәбә басылган. Имам Мөхәммәдиең бу әсәре имам Маликтан күчереп алган нөсхә булса да, кайбер урыннарда үз сүзен дә арага керткәнлектән һәм кайбер риваятьләрдә дә башкачарак язганлыгыннан, башка «Мәутаэ»ларга («Аяк эзләре »нә) — барысына да каршылыгы бардыр. Фикъһедә, ягъни ислам дине мәсьәләләре турындагы гыйлемдә булган «Әл-җамигыс-сагыйр» («Кечкенә җыючы») китабы Булакта һиҗри белән 1302, милади белән 1884 елда басылган.

(Бетте)

# Әһле гыяль (Өй җәмәгате)

*Әхлак гыйлеменнән*

## БИСМИЛЛӘҺИР-РАХМӘНИР-РАХИМ

## ЮЛДАШ

Әй балалар! Идел вә диңгез өстендә көймәдә, коры җирдә, тимер юлларда, гарабаларда (автомашиналарда) баручылар җил кебек кызу вә ашыгып йөрерләр. Кызу йөрсәләр дә ашарлар, чәй эчәрләр, ятарлар, торыр вә йокларлар. Уйнарлар, көләрләр, кайгырыр вә еларлар.

Ерак сәфәргә чыкканда, кешеләр үзләренә бер иптәш табарлар. Өйдән чыкканда, кулай иптәш очрамаса, юлда берәр иптәш табарлар, шуның белән бергә барырлар.

Тимер юлларда, пароходларда барганда үзләренең баруларын сизмәсләр. Агачларның, тауларның артта калганлыгын күреп: «Без барабыз икән»,— диярләр. Кырларда, сахраларда ат, арба белән йөргән вакытларда да мондый хәл булыр. Сынап карасагыз — үзегез дә белерсез.

## ДӨНЬЯ СӘФӘРЕ

Дөньяда яшәүче кешеләр дә сәфәр хәлендәдер. Адәмнәр вә хайваннар һәрберсе бер якка карап сәфәр чыгалар вә һичтуктаусыз йөреп торалар. Кирәк — ашап-эчеп утырсыннар, кирәк — уяу вә йокыда булсыннар, алар һаман сәфәрдәдер. Баралар. Барган саен, алларында бик ерак күренгән нәрсәләр сәгать саен якыная торырлар. Яңа гына артта калган әйберләр бик ерак киткән буладыр.

Үзләренең дөнья сәфәрендә икәнлекләрен белмәгән вә ашыгып киткәнлекләрен сизмәгән кешеләр тирә-якларына карасыннар. Шул вакытта туктаусыз йөреп торуларын белерләр. Яшьләр картайганнар, картлар дөньядан киткәннәр. Юклар дөньяга килгәннәр, дөньяга килгәннәр үсеп мәктәпләргә йөри башлаганнар.

Балалар дөньяга килүләрен дә белми, һичбер эшкә көчләре җитми. Соңрак утырырга өйрәнәләр, көлә вә ашыйлар, уйныйлар вә аякларында йөриләр. Теш чыга, мәктәпкә баралар. Укырга-язарга өйрәнәләр. Үсәләр, өйләнәләр, ата вә ана, соңрак әби вә бабай булалар. Чәчләре агара, тешләре төшә, билләре бөкрәя вә көчләре бетә. Чөнки бу нәрсәләр — дөнья сәфәренең хикмәтләредер, вокзаллары, тукталышларыдыр.

## ДӨНЬЯ СӘФӘРЕНДӘ ИПТӘШ КИРӘК

Дөнья сәфәрендә чагында кешеләр бер иптәшкә мохтаҗ булыр. Алар үзләренә бер иптәш табарлар. Бу иптәшкә «тереклек иптәше» диярләр.

Балалар үсеп, башкалар тәрбиясеннән котылып, адәм рәтенә кергәнлекләреннән соң, «тереклек иптәше» сайлау гадәттер, ягъни егетләр — кыз, кызлар егет күзли димәктер. Бу — дөньяның тәртибе. Электән үк шулай килгән. Кыз алу, кияүгә бару дөнья сәфәре өчен «тереклек иптәше сайлау» дип атала.

Тимер юлларда, пароходта очраган иптәш белән «тереклек иптәше» арасында зур аерма. Әүвәлгесе — вакытлы иптәш. Соңгысы — гомерлек иптәш. Кайгылар да, шатлыклар да аның белән бергә вә уртак булыр.

## ТӘРТИПҺӘМ БУЙСЫНУ

Дөньяда тәртипсез бер эш тә юктыр. Кошлар үзләре өчен оя ясарлар. Бу вакытта ата кош ана кошка ярдәм итә. Ана кош утырып бала чыгарганда, ата кош, читтән ризык ташып, аны тукландыра. Балалары чыкканнан соң, бергәләшеп балаларын тәрбиялиләр, очарга өйрәтәләр. Бу исә — бер тәртиптер.

Кырмысканы күрмәгән вә белмәгән бала булмас. Кырмыска — бик кечкенә җан иясе. Кышлык өчен җәй көне азык әзерләп куя. Аның азыгы — һәртөрле орлыклардыр. Кырмыска, кыш буена җитәрлек итеп, оясына орлык җыя. Орлыкларга су тисә — күгәрә, бозыла. Шуның өчен кырмыскалар кышлык азыкны коры сакларга тырышалар. Юешләнсә — коры вә кызу көннәрдә оядан чыгарып, кызу җиргә таратып киптерәләр. Кибеп җиткәннән соң, оя эчендәге амбарларына ташыйлар.

Башактагы орлыкны кырмыска үзе генә суырып чыгара алмаса, ярдәмгә иптәшләрен чакыра. Кырмыскалар, һич карышып тормыйча, ярдәмгә ашыга. Орлыкны җыйнаулашып тартып чыгаралар да ояларына алып китәләр. Кай вакытта берсе башак башына менеп орлык төшерә, ә икенчесе шуны ояга ташый. Кырмыскалар агачтагы вак корткычларны тотып, ояларына алып кайталар. Алардан үзләре өчен бал ясаттырып тоталар. Бу да — тәртип.

Кырмыскаларның тәртипле, күндәм булулары урядник, становой, городовойлардан куркып түгел, ә бәлки тәртипле, бер-берсенә хөрмәтле булуларыннандыр. Гакыллы вә гыйлемле җан ияләре һәрвакыт тәртипле, күндәм булырлар.

## АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘГӘ КОЛЛЫК ИТҮ

Балаларның иң төп вазифалары — кечкенә вакыттан ук Аллаһыны сөю вә Аңа коллык итәргә өйрәнү. Аллаһы кушканнарны җиренә җиткереп үтәү, тыйганнарыннан тыелу коллык итү буладыр. Аллаһыны сөйгән гаиләдә тәртип сакланыр, тормыш төзек торыр, гомерләр бәрәкәтле вә файдалы узар. Коллык итү — бәндәнең бурычы. Һәм ул өстендәге шушы бурычын үтәргә тиеш. Үти икән — файдасын күрер.

## НИ ЧӘЧСӘҢ — ШУНЫ УРЫРСЫҢ

Ата-анага буйсыну, аларга һәрвакытта хөрмәт күрсәтү — олы бер вазифадыр. Ата-ананы хөрмәт итүче кеше дөньяда — бәхетле, ахирәттә саваплы булыр. Килер бер көн, буйсынучан балалар үсеп, үзләре ата вә ана булырлар, һәм аларны балалары хөрмәт итәр. Никадәр бәхетле булсагыз да, бөек мәртәбәләргә ирешсәгез дә, ата-анагызны онытмагыз, нәсыйхәтләрен тыңлап, ризыкларын алыгыз, мохтаҗлыкларын, кайгы-хәсрәтләрен җиңеләйтергә тырышыгыз! Еракта яшәсәләр, хат язып, бүләк җибәреп торыгыз. Вафат булсалар, зиратларына барып, хәер-дога кылыгыз, Коръән укып, ата-анагызның рухына багышлагыз.

Ата вә ананың ярдәмгә мохтаҗ чагы — картлык көннәредер. Бу чорда аларга аеруча хөрмәт күрсәтү тиешледер.

Кардәш-ыруларга, мөгаллим вә тәрбиячеләргә, олылар вә картларга хөрмәт итү кирәк. Хөрмәтле булыйм дисәң, үзең дә хөрмәт ит! Ни чәчсәң — шуны урырсың!

## ИЗГЕЛЕК ИТҮ

Дөньяда бәхетле вә рәхәт яшәүче кеше — башкаларга игелек итүче. Игелек эшләүченең һичкайчан эче пошмас, рәхәтлектә гомер кичерер. Изге күңелле кешеләр Аллаһы Тәгалә каршындагы бурычларын намус белән үтәп килерләр. Шуның өчен күңелләре һичкайчан газапланмас. Тәндәге әгъзаларның берсе генә авыртса да, бөтен гәүдә сызлый. Шуның кебек үк, берәр кеше кайгы вә хәсрәткә төшсә, аны белүче кешеләр һәрберсе кайгырырга, хәсрәтен уртаклашырга тиеш. Чөнки адәмнәр дә — тәндәге әгъзалар рәвешендәдер.

Һәркем бәхетле, сөекле булуны телә. Ләкин сөекле булу өчен бер генә юл бар — башкаларга изгелек итү.

## МӘКТӘП ҺӘМ УКУ

Укый-яза белгән кеше җимеш агачына тиң. Җимеш агачы — җимешләре белән, укый-яза белгән кеше гыйлемле булуы белән файдалы. Үткән гомер аккан су кебек кире кайтмый. Гомер — иң кыйммәтле бер дәүләт. Бу дәүләтнең кадерен белү кирәк. Кеше өчен иң ышанычлы нәрсә — гыйлемдер. Гыйлемнән башка бернәрсә дә ышанычлы түгел. Чөнки алар бүген бар, ә иртәгә югалырга мөмкин.

Укыганны яхшы аңларга, аңлаганны хәтердә сакларга кирәк. Шул вакытта гына укуның файдасын күрерсең. Аңлар-аңламас укуда мәгънә юк.

Белем йорты — мәктәптер. Мәктәптә укырга, язарга, Аллаһы Тәгаләгә коллык итәргә өйрәтәләр. Кешеләр белән аралаша белү, алар белән мөгамәлә кору рәвешләре дә мәктәптә өйрәтеләдер. Мөгаллим вә мөгаллимәләр балаларны укымышлы кеше итәргә тырышалар. Моның өчен мәктәпне, укытучыларны сөяргә һәм күңел куеп укырга кирәк.

## ЧИСТАЛЫК

Үз-үзеңне, кием-салымыңны, китап-дәфтәрләреңне һәм башка һәртөрле нәрсәләрне чиста, пакь тоту чисталык дип атала. Керле, пычрак кешеләрдән адәмнәр нәфрәтләнер, бизәр. Ислам дине дә пакь йөрергә, чиста йөрергә өнди. Шуның өчен кечкенәдән үк үзеңне пакь йөртергә гадәтләнергә кирәк. Бу аеруча кыз балалар өчен кирәк. Чөнки алар зур үскәч йорт хезмәте белән шөгыльләнәчәк, бөтен өй җәмәгате кызлар кулында булачак.

Чисталык — иң мактаулы бер сыйфат. Әшәке, пычрак адәмнәр дә пакьлекне яратырлар.

Никадәр генә гүзәл булсалар да, пычрак кешеләрнең матурлыклары күзгә күренмәс, мондыйларны күреп, халык нәфрәтләнер. Кызлар өчен иң зур байлык — пакьлек. Пакьлек – сәгать саен сабын белән юынып тору түгел, һәр көн керләнгән кием-салымны, идән вә башка йорт нәрсәләрен тоташтан юу да түгел, бәлки һәрнәрсәне вакытында юу, юылган нәрсәләрне пакь тотудыр. Юкса үрдәк рәвешендә бер яктан юып, икенче баштан пычратып тору — мәгънәсезлек.

## СӘЛАМӘТЛЕК

Адәм баласының иң зур байлыгы — тәне вә җаны сәламәт булу. Әмма күп вакыт без бу байлыкның кадерен белмибез. Бөтен дөньяның хуҗасы булсаң да, тәнең сәламәт булмаса, рәхәтлек сизмәссең.

Чирнең сәбәбен белеп, аны китереп чыгаручы нәрсәләрдән сакланырга кирәк. Мәсәлән, тирләп салкынга чыгу, исле (күмер исе, агулы ис) бүлмәдә тору, майлы ризыклар ашау, исерткеч эчемлекләр эчү, әфьюн кабу — болар барысы да чирләүгә китерә.

Тән һәм киемнәрне, урын-җирләрне чиста тоту, тәһарәт алу, госел коену, намаз уку, ураза тоту, өй эчендәге хезмәтләрне башкару — сәламәтлек күнекмәләредер.

Чирле кешене карау, тәрбияләү хуҗабикәгә, ягъни хатын-кыз өстенә төшә. Шуның өчен кыз балага чирнең сәбәпләрен һәм сәламәтләндерү чараларын белергә кирәк.

## ЙОРТ ТӘРБИЯСЕ

Өй тирәсен тәртиптә тоту да хатын-кыз җилкәсенә төшә. Йорт эшләре — зур вә мәшәкатьле хезмәт. Шуның өчен белеп, күнегеп, өйрәнеп үсәргә кирәк. Кечкенәдән эшләп үсмәгән кеше, олыгайгач, никадәр генә тырышса да, өй эшенә өйрәнеп җитә алмас. Пычак, ачкыч, кайчы, шырпы, каләм, кәгазь вә язу карасы кебек әйберләр, ашханә әсбаплары — һәркайсы үз урыннарында, билгеле бер җирдә торырга тиеш.

Самовар вә чынаяк, ашъяулык вә кашык-тәлинкәләр, ашханә вә юыну урыннарының чисталыгы хатын-кызның, бигрәк тә яшь кызларның уңганлыгын күрсәтеп тора.

Йорт тәрбиясен яхшы үзләштерү үзең эшләү өчен генә түгел, ә бәлки эшләтә белү өчен дә кирәктер. Йорт эше гыйлемен белмәгән хатын-кыз никадәр күп хезмәтче вә асрау тотмасын, аның өендә тәртип булмый.

Фарыз (үтәлергә тиешле гамәлләр. — Ә.Х.) вә хәрам һәм мәкруһ (шәригать тарафыннан тыелган. — Ә.Х.) вә сөннәтләрне (гадәтләнгән гамәлләр. — Ә.Х.) өйрәнгәннән соң кызлар менә мондый гыйлемлекләр алырга тиеш: тегү, чигү, бәйләү, кер юа белү, аш-су әзерләү, өй җыештыру... Бу һөнәрләрне белгән кызлар осталыклары, уңганлыклары, булганлыклары белән аерылып торырлар.

Һәрбер кыз үзенә күлмәк кисеп тегәргә, яулык һәм кульяулык кебек әйберләр чигә белергә тиеш. Ир кешенең: «Күлмәк тегеп бирсәнә!» —дип ялваруы гаеп түгел. Ә менә кызларга шулай йөрү килешмәс. Белегез, тегү-чигү эшләрен үзләштермәгән кызларны кешегә санамаслар.

Аш пешерү, чәй әзерләү, өй җыештыру кебек эшләр дә — кызлар өчен бик кирәкле гыйлемнәр. Ал арның һәркайсын кечкенәдән өйрәнергә тырышыгыз. Олыгайгач, үзегез өчен бер һөнәр булыр. Эш эшләү гаеп түгел, сәламәт килеш тик яту гаептер.

Кадерле балалар! Моңа кадәр язганнарыбызның күбесе кызларның бала вә үсмер чаклары хакында иде. Ә үсеп җиткәч, кызлар нинди булырга тиеш? Хәзер шул хакта сөйләшербез.

## ӨЙЛӘНЕШҮ, НИКАХЛАШУ

Тәне сау-сәламәт һәр кеше үзе өчен тереклек иптәше сайларга, ягъни өйләнешергә, никахлашырга тиеш.

Кешеләр базарга барганда да иптәшлеккә яхшы юлдаш эзли. Тереклек иптәше исә — биш-ун чакрым юл барыр өчен сайланган иптәш түгел, бәлки бергәләп көн күрәчәк, гомер кичерәчәк иптәш. Бу кешенең холык-фигылен, яхшы якларын тикшерү белән бергә, үзеңнең дә аңа — тормыш иптәшеңә лаеклымы-юкмы икәнлегеңне белергә кирәк. Һәм, әлбәттә, ярың буласы кеше сиңа киләме-юкмы — монысын да ачыклау тиештер. Гомумән, кем соң ул хатын? Ә ир?

Хатын — ирнең тереклек иптәше. Хатын — иренең йортына хуҗа булучы, аның малларын саклаучы, балаларга тәрбия бирүче. Хатын — иренең күңелсез вә кайгылы чакларында юатучы, кәефен күтәрүче. Хатын — ирен бозык гадәтләрдән арындырыр, хатын — иренең күңелен йомшартучы, бөтен өй җәмәгатен җыеп тотучы.

Хатын курчак түгел, һәрчак уйнап-көлеп тормас. Хатын кием түгел, бүген киеп, иртәгә салынмас. Хатын хайван түгел, ошаса — асралып, ошамаса — базарда сатылмас. Хатын хезмәтче дә түгел, яхшы хезмәт итсә — асралып, хезмәт итә белмәсә — куып җибәрелмәс. Хатын — тормыш юлдашы, гомерлек иптәштер.

## ИР

Изге шәригать буенча, ир — хатынны үзенә иптәшлек өчен кабул итеп алучыдыр. Ата вә анасыннан, кардәш вә кабиләсеннән, туган-үскән җирләреннән аерылып килгән хатынын олылап, хөрмәт итеп торучыдыр. Ир үзенең хатынын мәшәкатьләрдән, төрле зәхмәтләрдән саклар. Хатынының ялгышлык белән эшләнгән эшләрен кичерер, яхшы нәсыйхәтләр бирер вә аны шәфкать канаты астында тәрбия кылыр. Юк-бар сүзләр белән хатынын борчымас, аңа карата ягымлы, мәрхәмәтле булыр, авыр эшләр йөкләмәс. Кая киткәнен, нәрсә эшләгәнен әйтеп, белдереп йөрер. Үзен генә кайгыртып, үзе турында гына уйламас, хатын мәнфәгатьләрен дә исеннән чыгармас.

## ТЕЛӘК, ОМТЫЛЫШ

Ир белән хатынны никах беркетеп торыр. Никах ал арның үзләре вә балалары өчен кирәк булачак. Никахлашу өчен ике яктан да теләк, омтылыш, холык вә табигатьләре туры килү, яшь мөнәсәбәте, тиңдәшлек булу кирәк.

Ир белән хатын өйләнешкәндә никахлаша. Әгәр икесенең берәрсе никахны кирәк тапмаса вә аның хакларын җиренә җиткерә алмаса, никахтан файда күрмәсләр. Бер-береңне яратмыйча өйләнешсәң дә никах ярдәм итмәс. Араларында бер-берсенә омтылыш вә мәхәббәт булмаган кыз белән егетне никах белән берләштерү — дошманлашкан ике кешене бер бүлмәгә ябып кую кебектер. Күгәрчен белән карчыга, эт белән мәче бер читлектә яши алмаган шикелле, бер-берсен яратышмаган кыз белән егет тә бергә тереклек

итә алмаслар. Өйләнешсәләр дә, рәхәт күрмәсләр, гомерләре моң-зар, кайгы-хәсрәт белән үтәр.

Гүзәл вә мөлаем йөзле кешегә күзең, мәхәббәтең вә омтылышың төшсә, кыз вә егет бер-берсенең йөзен, гәүдәсен, чәчен күрергә тиеш. Бу — шәригать таләбе. Күрү мөмкинлеге булмаса, белүчеләрдән, ышанычлы кешеләрдән сорашырга кирәк. Үзе теләмәгән вә мәхәббәте төшмәгән егеткә кыз бирү — зур гөнаһ. Моңа һичкемнең хакы юк. Егет белән кызның бер-беренә туры килмәгәнлекләрен белеп тә, ике арада яучылык итеп, ике араны алдап килештерүчеләр, кызларны көчләп никахлаштыручылар — шәригатьнең иң зур дошманнарыдыр. Алар — җәберләүчеләр вә хыянәтчеләрдер. Шушы гөнаһларының җәзасын ахирәттә — Аллаһы Тәгалә каршында күрәчәкләр. Кызны көчләп кияүгә бирү — аны үтерү белән бер. Үтерү ачысы бер сәгать булыр да бетәр, әмма кызны яратмаган кешесенә көчләп бирү сәбәпле, гомер буена шушы кызның үлем ачысын татып яшәвең мөмкин.

## ТУРЫ КИЛҮЧЕЛЕК

Өйләнешәчәк кыз белән егет бер-берсенә туры килергә тиеш. Холык вә табигатьләре туры килгәндә генә, дөнья сәфәренә чыгарга ярый. Бер мәртәбә очрашып кына бер-берсенең холык-фигылен белеп булмый. Бу хакта кат-кат сорашырга, ярың булачак кеше турында аны белүчеләр белән киңәшергә кирәк. Кыз, егетнең эчке дөньясына игътибар итмичә, малын, кием вә йорт җиһазларын, ата вә анасын тикшерү белән канәгатьләнсә, соңыннан гомере буе үкенеп, үзен-үзе шелтәләр. Мал вә байлыкка, шөһрәт вә дәрәҗәгә кызыгып өйләнешүчеләр яисә кызларын никах итүчеләр — адәм баласы белән сату итүчеләрдер.

Өйләнешүче яшьләрнең яшь аралары да туры килергә тиеш. Бу — табигать таләбе.

Фән әһелләре һәм табиблар никах вакытын болай исәпли: кызлар өчен унсигез яшьтән утызга, ә егетләргә егерме биштән утыз җидегә кадәр өйләнү (кияүгә чыгу) кулай санала. Яше җитмәгән яисә яше үтеп киткән кешеләргә чарасызлыктан өйләнешмәскә киңәш ителә. Тагын шунысы бар: кияүгә чыгучы кыз егетеннән алты яшькә кече булырга мөмкин. Әмма ун яшьтән артык аерма файдалы түгелдер.

## ТИҢ БУЛУ

Ир белән хатын бер-берсенә тиң булса гына, алар арасында берлек һәм дуслык хөкем сөрер. Юкса югары тараф түбән тарафны кимсетеп торыр да, шул сәбәпле ара бозылыр. Байлык, нәсел, гыйлем вә тәрбия мәсьәләсендә егет белән кызның бер үлчәүдәрәк булуы хәерле. Ләкин тәрбияле, гыйлемле, гүзәл холыклы кыз яки егетне тиңсенмәскә һичкемнең хакы юк. Тәрбияле, акыллы кызларга фәхешханәләрдә йөрүче, анда-монда исереп ятучы бай балалары тиңдәш түгел. Байлыкка кызыгып, әдәпле, укымышлы кызларны байга бирү — золымдыр. Дөньяның рәхәте — байлык түгел, ә күңел тынычлыгындадыр.

Яшьлек хатасы белән, кайбер кызларның үзләренә тиң егетләрне тиңсенмәүләре, тиң булмаганнарны тиң санаулары мөмкин. Шуңа күрә тәҗрибәле кешеләрнең сүзләрен тыңларга һәм яхшылап тикшерергә кирәк.

## ШӘХСИ ХӘЛЛӘРДӘ ЕРАКЛЫК

Якын кардәшләр никахлашса, үзләре өчен дә, балалары өчен дә зарарлыдыр. Мондый никахтан зәгыйфь балалар туу ы билгеле. Никах укылачак кыз белән егет кардәшлек, мәмләкәт, климат җәһәтләреннән бер-берсеннән ерак торсын.

## ГАКЫЛЛЫ БЕР ХАТЫННЫҢ НӘСЫЙХӘТЕ

Кызын ярәшкәннән соң, бер гарәп хатыны баласына мондый нәсыйхәт биргән: «Әй кызым! Бүгеннән башлап безнең кулыбыздан китәсең. Син хәзер чит кешегә яр вә юлдаш булдың. Тиз көннән дөнья көтәргә керешәчәксең. Дөнья көткәндә игътибарга алырдай нәрсәләр бар. Иреңнең якыннарын, бигрәк тә каената һәм каенанаңны хөрмәт ит! Аларны үз атаң һәм үз анаң кебек якын күр! Аларның балаларын үз туганнарың хөкемендә сана! Яңа якыннарыңның холык фигыльләрен өйрәнеп, шуларга карап мөгамәлә ит! Алар белән араңны бозма! Юкса ирең читен хәлдә калыр. Синең яклы булса — якыннарының кәефе китәр, алар ягында торса — сине кызганыр.

Кызым! Иреңнән сер яшермә! Иреңнән гайре һичкемгә сер сөйләмә! Кеше янында иреңә сүз әйтмә, сөйләшкәндә тавышыңны күтәрмә, чыраеңны бозма! Ирләр хатыннарының кимчелекләрен ярлыкарлар, гафу итәрләр. Әмма чит кеше алдында аз гына нәрсә дә йота алмаслар.

Кызым! Ирең сөймәгән эшләрдән ерак тор! Көнләштермә! Иреңнең малын сак тот!

Кызым! Өең җыйнак булсын, һәрнәрсә үз урынында торсын! Балалар — ирең не, ирең балаларыңны сөйсен! Шуңа омтылырга тырыш. Балаларын яраткан ата Тәүфикълы, шәфкатьле була, алар белән юанып яши, тиешсез җирләргә күз салмый. Кызым! Дөнья һәрчак нигъмәт белән генә тулып тормый, агулары да, чәнечкеләре дә очраштыра. Ике арагызда каршылык туса — кызма! Ирең никадәр ачуланса да, каршы сүз әйтмә! Ирләр каршында иң яхшы хатын — юл бирүче хатын.

Кызым! Балаларыңны яхшы тәрбиялә! Мәктәп яшенә җиткәнче аларны яхшы холыкларга гадәтләндер!

Кызым! Һәр эштә ышанычың Аллаһы Тәгалә булсын! Һәр өметең Аллаһы Тәгалә хәзрәтендә булсын! Аллаһы Тәгалә — бөектер, һәрнәрсәне белер, рәхимле вә рәхмәтледер».

(Бетте)

# Тәрбияле бала

*Әхлак гыйлеменнән*

# БИСМИЛЛӘҺИР-РАХМӘНИР-РАХИМ

Алтыннан да кыйммәтле, оҗмах нигъмәтләреннән дә кадерле булган нәрсә — тәрбияле баладыр. Ата һәм ана өчен тәрбияле бала кебек олы байлык һич булмас. Тәрбияле бала дөньяда җанга шатлык һәм ахирәттә йөзгә аклык китерер. Тәрбияле бала дөнья байлыгына да бирелмәс һәм бер дәүләт патшалыгы белән дә алмаштырылмас; аны һәркем яратыр һәм мактап телгә алып сөйләр, ни сораса да бирерләр. Тәрбиясез баланы бер кеше дә яратмас, йомыш кушмаслар, бәлки хурларлар вә кимсетерләр генә.

Тәрбияле бала бетмәс-төкәнмәс хәзинә булса да, тәрбияле булу да бик җиңелдер. Тәрбияле бала булырга һәр баланың кулыннан килер, көче дә җитәр. «Атам һәм анам шатлансын, кешеләр дә миңа рәхмәт әйтсен, мине яратсыннар һәм мине үрнәк итеп сөйләсеннәр»,— дигән балаларның барчасы да тәрбияле бала була алырлар.

Тәрбияле бала бик билгеле булыр. Эшләгән эшләре тәрбиясен күрсәтеп, белдереп торыр. Тәрбияле балаларның нинди булганлыкларын сезгә шушы урында белдерәбез, укып аңларсыз һәм рәхәтләнеп, күңелләнеп тәрбияле балаларның гадәтләрен үзләштерерсез. Тәрбияле балаларның гадәтләре һәм холыклары менә шушылай булыр.

Тәрбияле бала иртә белән йокысыннан зурлар белән бервакытта торыр. Ал ар дан элек тормас, соңга да калмас. Чөнки бар кешеләр торып беткәннән соң йоклап яткан балага һөнәрсез, эшлексез, оятсыз, ялкау диләр. Йокысыннан торгач та, һава салкын вакытларда өстенә һәм аягына кияр; чөнки җылы урыннан торып салкын урынга басу зарарлыдыр, тәне кызу килеш суыкка өшегән кеше авырыр. Моннан соң хаҗәтханәгә, ягъни бәдрәфкә барып килер һәм салкынрак су белән тәһарәт алыр, юыныр.

Тәрбияле баланың бит, кул сөртә торган сөлгесе, чәчен тарый торган тарагы үзенә аерым булыр, үз сөлгесенә сөртенер һәм үз тарагы белән генә тарар. Тәрбияле бала үзенә хәзерләп бирелгән чәйне яхшы гына утырып эчәр, икмәкне дә кадерләп кенә ашар. Аяк өстендә ашап йөргән кешенең икмәк валчыклары, җиргә төшеп, аяк белән тапталыр да, гөнаһ булыр. Шуның өчен тәрбияле бала һичбер вакытта аяк өстендә ашап йөрмәс.

Тәрбияле бала үз эшен үзе эшләр. Көндез кия торган киемнәрен урыныннан алып, пычраклары күренсә, үзе чистартыр. Әгәр дә үзенең көче җитмәслек эшләре булса, ул вакытта зурлардан үтенер.

Чәйдән соң вакыт булса, мәктәпкә барганчы, тәрбияле бала бер читкә утырып үзенең дәресләрен карап чыгар, дәресендә булган нәрсәләрне, аңлап, күңеленә салыр.

Балаларның зиһеннәрен ачар өчен кайсы чакта дәресләреннән сүз сорарлар. Тәрбияле балалар, сүз сораучыларны ятатып, сораган сүзләрен яхшы аңлагач, җавабын да бирерләр. Әгәр дә яхшы аңлап җитмәсәләр, ул вакытта сүз сораучыдан икенче мәртәбә кайтарып сорарлар.

Балаларның тәрбиялесе мәктәпкә барганда бик билгеле булыр: тәрбияле бала, мәктәпкә барырга чыкканда әдәпле һәм инсафлы гына итеп, зур кешеләр шикелле үз юлында йөрер. Хөрмәтле кешеләр очраса, сәлам бирер. Тәрбияле балалар як-якка каранмас, кибет яки башка берәр кызыклы тамаша нәрсәләр янында юанмас. Җыелып сөйләшеп торучы кешеләр янында туктамас. Үтеп баручы этләргә таш яки агач атмас һәм

өстереп берсен икенчесе белән сугыштырмас, җыелып торган сулар эченнән чыпырдатып йөрмәс. Күргән кешеләр: «Бу бала бик әдәпле икән»,— дип яратып калырлар. Мәктәпкә кергәннән соң, аяк киемен билгеле җиргә куеп, үз урынына утырыр һәм үз эшендә генә булыр.

Як-ягында булган балалар белән төртешкән һәм аларның китап яки язуларына караган, алар белән сөйләшеп утырган һәм вакытларын буш нәрсәләр белән үткәргән балаларны кешеләр бер дә яратмаслар. Шуның өчен тәрбияле балалар мондый эшләрдән бик сакланырлар. Мәктәптә балалар өчен уйнарга да бераз вакыт булыр. Шул чакта балалар, укытучыларның рөхсәтләре белән генә, тиешле нәрсәләр белән уйнарлар, уйнаган вакытларында да иптәшләрен елатмаслар, үзләре дә еламаслар.

Балаларның тәрбиялесе белән тәрбиясезе уйнаган вакытларында бик ачык беленер. Чөнки уйнаган чакларында, балалар бик ирекле булырлар, зурлардан курку кебек нәрсәләр онытылыр.

Тәрбияле бала иптәшләренә каты һәм яман сүз әйтмәс һәм ал арны һич тә кыйнамас. Тәрбиясез балалар каты сүз әйтеп яки кыйнап, үзен хурласалар да, ал арны ата-анасына җиткермәскә тырышыр.

Тәрбияле баланың уены зарарсыз нәрсәләр белән булыр. Тәрбияле бала кара савыты, каләм кебек нәрсәләр белән уйнамас. Шулай ук шырпы, лампа, ут, пычак, без, кадак, урак, чалгы, пәке, мылтык кебек нәрсәләр, пыяла һәм таш савыт кисәкләре, тузан, туфрак һәм балчык белән һич уйнамас, бакчаларда булган агачларны сындырмас һәм гөлләрне йолкымас, чәчәкләрне өзеп төшермәс.

Тәрбияле бала иптәшләренең каләмнәрен, кәгазьләрен, китапларын актармас, ертмас. Ал арның әйберләрен каралтмас һәм үз әйберләрен дә пычратмас, керләндермәс, югалтмас. Бәлки бар нәрсәсен чиста, пакь итеп тәрбияләп тотар.

Тәрбияле бала мәктәптән кайтканда да әдәпле генә кайтыр. Кайтып кергәч тә, ата-анасы һәм башка олылар белән ике куллап күрешер, дәресләрен шатланып тыңлатыр. Ата һәм анасын рәхәтләндерер, куандырыр һәм алардан хәер-дога, рәхмәт алыр.

Тәрбияле баланың китап, кәгазь һәм каләм куя торган урыны билгеле булып, дәресеннән кайкач, шунда куяр һәм кирәк булганда үзе алыр. Чөнки: «Китапларым кайда, кәгазь һәм каләмнәрем кемдә?» — дип кычкырып эзләп йөрү, кешеләрдән сорап аптырату — гаеп эш.

Дәресләрен укып белгәннән соң, балаларның буш вакытлары да булыр. Бу вакытта, әгәр дә йорт эчендә йомыш һәм эшләр булса, зурлар кушканча эшләрләр. Әгәр дә йомыш һәм эш булмаса, бакча һәм ишегалларында рәхәтләнеп тик йөрерләр яки иптәшләре белән бик дус булып, күркәм холык белән генә уйнарлар. Әмма тәрбияле балалар бу вакытта урамга чыгып, урам балалары белән уйнамаслар. Чөнки урам балалары әдәпсез һәм тәрбиясез булалар. Ал арга иярген бала да тәрбиясез булыр, яман сүзләр ишетер.

Тәрбияле баланың кешегә күренә торган яхшы һөнәре зурлар һәм кечкенәләр белән тереклек итүендә булыр. Мәсәлән, тәрбияле бала үзеннән кечкенәләргә бик шәфкатьле булыр, аларны кызганыр, һәрвакытта «туганым» дип кенә эндәшер, шулай ук үзеннән

зурларга, бигрәк тә ата-анасына, укытучылары һәм остазларына, үзен тәрбияләүче тәрбиячеләргә, хәтта ки үзеннән олы яшьтәгеләрнең барысына да һәрвакыт хөрмәт күрсәтер. Аларның хәтерләрен бик саклар. Аларны бик яратыр һәм һәрвакытта алар теләгәнчә булырга тырышыр.

Тәрбияле бала ата-анасының күңелләрен калдырырлык нәрсәләрне һич эшләмәс. Ата һәм анасы: «Ул эшне мин яратмыйм»,— дисәләр, тәрбияле бала ул эшне эшләү түгел, күңеленә дә китермәс. Йомышы булган чакта, торган җиреннән кычкырмыйча, яннарына барып, ачык итеп әйтер. Аларның кушкан йомышларын күңел белән башкарыр. Әгәр дә үзеннән берәр нәрсә сорасалар, ачык йөз белән җавап бирер. Йорт эчендә кунак булса, ата-аналары кушканча кунакка хезмәт һәм хөрмәт итәргә тырышыр, йорт эчендә кунак балалары булса, тәрбияле бала алар янында булыр. Аларның мәктәпләрен һәм дәресләрен сорашыр, алар белән шаулашмыйча, кычкырмыйча, бәлки туган шикелле уйнар һәм бергә йөрер.

Баланың тәрбияле булуы ашарга утырганда беленер. Тәрбияле бала зурлар күрсәткән урынга туры итеп утырыр. Терсәкләре белән таянмас, ашарга бирүләрен көтәр һәм бүлеп бирсәләр, шуны ашар. Кирәк булса, тагын яхшы гына итеп сорар, кирәк булмаса, комсызланып бүлдереп, салдырып куймас. Аз гына кабып, яхшылап чәйнәп ашар. Зурларның сүзләрен тыңлар, ләкин үзлегеннән сүзгә катышмас.

Тәрбияле бала ашаганда һич ашыкмас, икмәк валчыкларын читкә төшермәс, ашны ашъяулыкка һәм үзенең киемнәренә түкмәс. Әгәр дә кешеләр белән бер табактан ашарга кирәк булса, ул вакытта кулын үз алдына гына сузар, кеше алдына үрелмәс, акрын гына ашар. Мондый балаларны һәркем яратыр һәм мактап сөйләр.

Тәрбияле бала, аш яныннан торгач, майлы кулы белән әйбер тотмас, кулын киемнәренә сөртмәс, бәлки яхшылап сабын белән юар. Авызын чайкар, зурлар бар вакытта, алар юынып бетергәнне көтәр, үзенә чират җиткәч юар.

Аш ашагач, тәрбияле бала зурлар янында утырмас һәм бик тиз дә йокламас, чөнки ашаганнан соң тиз йоклау файдалы түгелдер, бәлки бераз дәресләрен карар яки әдәпле генә уйнар.

Балаларның йокылары алданрак килә, шуның өчен аларга иртәрәк ятарга рөхсәт ителәдер. Ятарга рөхсәт бирелгәч тә, тәрбияле бала йокыга әзерләнер. Хаҗәтханәгә барып килер, көндезге киемнәрен салып, барысын да бик яхшы итеп төрер дә билгеле урынга куяр. Әгәр дә киемнәре арасында юеш һәм пычранганнары булса, аларны башка нәрсәләр арасына ташламас. Чөнки юеш һәм пычрак кием бергә куелса, башкалары да кадерсезләнер. Бәлки кибәр өчен юешләрен элеп куяр һәм тузаннарын селкеп чистартыр. Соңыннан урынына ятар һәм шушы доганы укыр: «Йа Раббым, ата һәм анамның күңелен хуш ит, укытучыларга һәм безне тәрбияләүчеләргә, яхшы мөселманнарга савап бир, минем зиһенемне ачык һәм үземне сәламәт кыл, һәм Үзең риза булырдай ышануда һәм гамәлдә ныклы ит!»

Бер баланың ата һәм анасы фәкыйрь булу гаеп түгел. Бу дөньяда Аллаһы Тәгалә кайсы кешеләрне бай һәм кайсы кешеләрне ярлы, фәкыйрь иткән. Һәркем үзенең өлешен күреп уздырадыр.

Тәрбиясез баланың, ата һәм анасы никадәр бай яки мәртәбәле булсалар да, кешеләр каршында игътибары булмас, бәлки бала тәрбиясез булса, ата һәм ананың хөрмәте китүгә сәбәп булыр. Тәрбияле баланың атасы һәм анасы, никадәр фәкыйрь булсалар да, кеше арасында кадерле булыр. Бәлки моның сәбәбеннән ата һәм аналары да кеше арасына керерләр һәм хөрмәтле була башларлар.

Тәрбияле бала, ялгышлык белән тиешсез бер эш эшләгән булса, аның ярам агайлыгын кешеләрнең күз каравыннан ук белер, аңлар, шунда ук оялыр һәм кызарыр, әгәр дә берәрсе үзенә киңәш бирсә, аңа һич тә карышмас, каршы әйтмәс, бәлки киңәш бирүчегә: «Бу эшем тиешсез икәнен үзем дә белдем, моннан соң икенче мәртәбә эшләмәм, әйткәнең өчен сиңа рәхмәт, синнән Аллаһы Тәгалә риза булсын!» —дип әйтер.

Тәрбиясез бала хаталарын аңлау түгел, әйткәндә дә белмәс, үзенең кимчелекләрен төзәтү исәбендә булмас. Киңәш бирүчегә яман сүзләр белән җавап бирер.

Тәрбия һәм әдәп кадәр кешеләрне сөекле күрсәткән нәрсә дөньяда юктыр, шулай ук тәрбиясезлек, әдәпсезлек кадәр дошман күрсәткән нәрсә дә юктыр. Әмма тәрбиясез бала никадәр матур һәм гүзәл булса да, аны бер кеше дә яратмас, матурлыгы яки киеме белән генә игътибарга керә алмас. Тәрбияле бала никадәр зур үссә, шулкадәр игътибары үсәр һәм хөрмәте артыр. Дөньяда моннан да артык бәхет булмас. Тәрбиясез бала никадәр зур үссә, шулкадәр хөрмәте кимер һәм игътибар югалыр. Бәхетсезлеге көннән-көн артыр.

Тәрбия һәм әдәп ир балалар өчен никадәр кирәк булса, кыз балалар өчен бигрәк тә тиештер. Шуның өчен тәрбияле кызлар, әдәпле һәм инсафлы булып, ошамаган гадәтләрдән бик сакланырлар. Кайсыбер кимчелекле гадәтләр, ирләрдә булганда бик зур күренмәсәләр дә, кыз балалар өчен бигрәк тә гаептер. Чөнки пакьлек, сафлык һәм чисталык — кызлар өчен бик тиешле, кирәкле нәрсәдер. Үз өс-башларын карамаган кызлар һәркем каршында тәрбиясез исәпләнерләр. Уен уйнау турысында кыз балаларның ир балалардан аермалары бар. Мәсәлән, сикерешеп уйнау, ир балалар өчен яхшы булса да, кыз балалар өчен беркадәр гаеп күреләдер.

Кыз балаларның үзләренә хас уеннары бар: курчак, йорт, бакчалар ясап уйнау, шулай ук аш-су әзерләү кебек уеннар. Әниләре үзләренең кызларына энә, җеп һәм ситса кисәкләре хәзерләп бирәләр. Булдыклы һәм эшчән, тәрбияле кызлар да үзләренең курчакларына күлмәкләр тегеп кидерәләр. Калфаклар куеп, шәлләр белән бөркәндереп бизәндерәләр.

Тәрбияле балалар оятсыз, әдәпсез сүзләрне һич тә сөйләмәсләр. Әмма кыз балалар оятсыз, әдәпсез сүзләрне үзләре сөйләү түгел, хәтта тәрбиясез балалардан ишетсәләр дә оялырлар һәм ишетмәс өчен бер читкә китәрләр.

Кайсы вакытта кыз балалар үзләренең аналарына ияреп кунакка һәм мәҗлесләргә баралар. Кыз баланың тәрбиялесе һәм тәрбиясезе шушында бик беленер. Тәрбияле кызларның аналары бу чакта рәхәтләнеп, шатланып торырлар. Әмма тәрбиясез кызларның аналары кызлары өчен оялырлар.

Зур кешеләрнең кайсыбер сүзләре балаларга ишеттермәскә тиешле буладыр. Шуның өчен мәҗлесләрдә тәрбияле кызлар һәрвакытта аналары янында утырмаслар,

бәлки аналары ишарә иткәнне аңлап бер читкә китеп утырырлар яки тышка чыгып уйнарлар. Әгәр дә кызыклы нәрсәләрне карап, гыйбрәт алып йөрсәләр, бигрәк күркәм булыр.

Тәрбияле кызлар мәҗлесләрдә аналарыннан күмәч, май, ит, бал, җимеш, чәкчәк, төш һәм башка нәрсәләрне һич тә сорамаслар. Чөнки болай сорау — гаеп эштер. Әгәр дә аналары үзләре бирсәләр, ул чакта рәхмәт әйтеп алырлар. Майлы нәрсәләр булса, үз киемнәренә дә, кеше киемнәренә дә сөртмичә, кулларын сабын белән юарлар.

Ир балалар белән уйнау, сүз әйтешү, йөгерешеп, куышып йөрү — кыз балалар өчен бик зур гаеп эш. Тәрбияле кызлар бу эштән бик сакланырлар. Тәрбияле балалар әдәп белән тәрбияне, олыларның сүзләреннән бигрәк аларның фигыльләреннән, эшләреннән өйрәнерләр, һәр хәлләрендә һәм һәр чакларында, әдәпле һәм зур кешеләрдән гыйбрәт алып, алар кебек булырга тырышырлар.

Тәрбияле балалар, яхшы белән яманны аеру хакында игътибарлы булырлар. Чөнки бүген сигез-ун яшендә булган бер бала, җиде-сигез елдан соң зур кеше булыр. Балачакта алган тәрбия чәч агарганчы бергә булыр. Балачакта алынган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы үзгәртә алмас.

Балалар! Бу язганнарым сезгә бер үгет-нәсыйхәт булып тора. Һәм минем үзлегемнән сөйләгән нәрсәләр — файдалы нәсыйхәтләрдер. Әгәр дә бу нәсыйхәтләрне кабул итсәгез — файдасы да үзегезгә, кабул итмәсәгез зарары да үзегезгә булыр. Яхшы нәсыйхәтләрне кабул итмәгән балалар соңыннан үкенерләр, ләкин эш үткәч, үкенүдә файда булмас.

Балалар! Дөньяның иң рәхәт көннәрендә сез моны хәтерләгез. Сабак вә дәресләрдә беркадәр мәшәкатьләр булса да, һич авырсынмагыз, бәлки яхшы укыгыз һәм тәрбияле булыгыз! Алдыгызда олы бәхет белән озын гомерле рәхәт сезне каршылап көтеп тора. Гыйлем һәм тәрбия авырлыкларын хәзерге вакытта ихлас һәм мәхәббәт белән чәчсәгез, киләчәктә файдалы җимешләрен дә үзегез җыярсыз. «Ни чәчсәң — шуны урырсың»,— дип бабаларыбыз дөрес әйткәннәр.

(Бетте)

**ГЫЙБРӘТЛЕ СҮЗЛӘР**

* Бәрәкәтле адәм шул кешедер: сүзенә караганда эше күп вә тышына караганда әче яхшы.

* Дөньяда иң авыр нәрсә — ризык аз вә гакыл күп булып, икесе бергә җыелудыр.

* Җиңел саналган эшләрнең ахырлары күп вакытта — авыр вә авыр күрелгән эшләрнең соңлары күп вакытта җиңел буладыр.

* Хаҗәт вакытында дәваны истигмаль итү шифа бирә, хаҗәт булмаганда истигмаль итү авыру тудыра.

* Якын карендәшләреңне бозык кешеләрдән саклавың кебек, китапларыңны да тиешле булмаган кешеләрдән сакла.

* Ачу килү изгелекләрне оныттыра.

* Тиешле булмаган кешене мактау вә яманлау — сазлыкка өй салу мисалында.

* Күп фикерлә, аз сөйлә.

* Күңелне үзенә тартучы нәрсә — кешенең яхшы холкы белән яхшы гадәтләредер.

* Сүзләрнең кыйммәтлесе — заман үтү белән онытылмый торганы.

* Никадәр авыр булса да, адәм баласының дөньяда торасы килә.

* Дөнья бер театр булып, адәм балалары — шунда уйнаучылар.

* Һәр кичәнең — көне, һәр кайгының шатлыгы була.

* Кеше үзенең хатасын заманага йөкләтә.

* Ялган дус чын дошманнан зарарлырак.

* Күп наданга иярүгә караганда аз галимгә ияру яхшырак.

* Дуслык дәвам иткән вакытында ныгый бара.

* Дуслык — кайгыны, шатлыкны уртаклашудыр.

* Хәзерлекләре булган кешеләр куркынычлы эшләргә дә каршы торалар.

* Төшүе авыр булырлык югары урынга менәргә кызыкма.

* Дошман белән чуалу вә булышу — аны кыздырудыр.

* Өмет бетү куркакны да батырландыра.

* Дошманны җиңү өчен иң көчле корал — аңа изгелек итү.

* Син үз вазифаңны үтә дә аннан аргысын тикшермә.

* Исерү — үз ихтыярың белән дивана булудыр.

* Һәр ике кеше дә ирле-хатынлы булмый.

* Надан бай — галимнәр мәҗлесендә телсездер.

* Балаларга калдыра торган мирасларның иң кыйммәтлесе — дин өйрәтеп калдыру.

* Исерү — адәмлектән чыгып, хайванлыкка керүдер.

* Кешеләрне шатландыруың — үзеңне шатландыруыңдыр.

* Гакыллы дус — арыган вакытта утырып бара торган арба.

* Гакыллы кешенең йөге — башында, ахмак кешенең йөге — аркасында.

* Эшләп аруга караганда тик торып ару авыр.

* Әйткән сүз, үткән гомер — агып киткән су мисалында.

* Тугрылык — максатка бара торган юлларның һәм кыскасы, һәм яхшысы.

* Бәгъзе бер кешеләр тешләре белән чәйниләр, бәгъзе берәүләр телләре белән чәйниләр.

* Бу дөньядагы кайгылар, авырлыклар — адәм балаларының имтихан бирүе.

* Сәламәтлегеңне саклыйсың килсә, һәр эшеңдә сак бул.

* Өмете беткән кешенең өмете — үлем генә.

* Атаң-анаңны кабергә салган дөньядан ни мәрхәмәт өмет итмәк кирәк!

* Дөньядагы яшәгән вакытларында адәм балаларының ике төрле максатлары бар: берсе — байлык, икенчесе дә — байлык.

* Күрү өчен йөрүче хатыннарга караганда, күрелү өчен йөрүче хатыннар күбрәк була.

* Гакыллы кеше ялгызы гына калудан курыкмас.